Безнең Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

04

апрель 2022

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР



РАФАЭЛЬ СӘХӘБИЕВ

Алтын Урдада терлекчелек

4 бит

Габдулла Тукай һәм Джей Дагыстанлы

61 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

04
(340)
апрель 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Габдулла Тукай

ТАРИХИ МИРАС

4 Алтын Урдада терлекчелек. *Л.Гобәйдуллин*
8 Дөнья тарихында шанлы татар-төрки эзләре. *А.Чанышев*
12 Казан татарлары. *А.Сперанский*
17 Истанбул мәктүбләре. *Ф.Кәрими*
22 Сәнәкчеләр сугышы. *А.Хәмзин*
26 Ачның ачуы яман. *А.Хәмзин*
32 «Шуның кебек хатының булса икән!» *М.Фәйзи*
39 Игелекле Хәлфиннәр. *М.Гаитов*

ТАТАР ГАМЕ

46 Рамил Муллин: «Түбән Каманың киләчәге матур булыр»
50 Түбән Кама – гүзәл кала

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

56 Ләис Зөлкарнәй шигырьләре
60 «Безнең мирас» котлый!

ӘДӘБИ МИРАС

61 Габдулла Тукай һәм Джей Дагыстанлы. *Л.Мортазина*
66 «Манас» – халык ядкяре. *Ф.Галимуллин*

ДИНИ МИРАС

68 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
74 Ислам. Дини сүзлек
75 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*
76 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

78 Шахмайның йөзек кашы. *И.Диндаров*
82 Дилүс Ильясов. *Ә.Зарипов*
91 Тукайның олуг юбилее илә әдипләребезнең хатлары. *Л.Лерон*
96 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
98 Конгресс: тәүге адымнар, изге максатлар. *Л.Лерон*
100 Без бар бит әле! *А.Хәмзин*
104 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

106 Рәссам Әхсән Фәтхетдинов музее
108 «Минем таныш өянкеләр» җыры

ТАБИГЫЙ ЯДКЯРЛӘР

110 Алмагач

СИХӘТЛЕ МИРАС

111 Алма

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Апрель*

Заказ №О-0948. Тираж – 2275 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 28.03.2022. Чыгу көне: 04.04.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
ТАССРның атказанган артисты (1980), ТАССРның халык артисты (1987) Рафаэль Сәхәбиев Ж.Бизеның «Кармен» операсында Моралес ролендә

Артка бакма, данием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табыла табылса — Алла ул!

Габдулла Тукай



Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Фәхрелислам Агиев. Казан. 1908 ел



ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

(26.04.1886-15.04.1913)

ХАСИЯТ

Сөйләшсәк төрле милләтләр хакында,
Ерактамы алар яисә якында,
Сөйлибез төрле сүзләр хакларында
Вә кайсысында ни хасләт – барын да.

Итеп иснад аларга милек вә малны:
«Фәлән милләт фәләнле һәм фәләнле».
Дибез госманлылар тугърында: «Шанлы».
Немец халкы хосусында: «Кораллы».

Яһүд халкы хосусында сөйләшсәк,
Дибез: «Гаять җитез һәм дә җайлы».
Кытайлар тугърысында сүз ачылса:
«Алар, – дибез, – гүзәл һәм яхшы чәйле».

Әгәр телгә төшә калса фырансуз,
Дибез: «Гаять һөнәрмәнд һәм дә җанлы».
Арабызда сөйләнсә ингелизләр,
Дибез: «Бик иҗтиһадлы һәм дә маллы».

Ни диярсең, сүз татар тугърында булса?
Табалмый сүз, диярсең: «Ул – сакаллы».

1910 ■

Алтын Урдада терлекчелек

Алтын Урдада, гомумән, халкы күчмә тормыш алып барган дәүләтләрдә кешенең дан-дәрәҗәсе көтүлегендәге елкы, терлек саны белән дә билгеләнгән. Татар йорт хайванын элек-электән «мал» дип атаган һәм ул аның төп байлыгын, мөлкәтен тәшкил иткән. Елкы саны – гаскәрнең, ә гаскәр исә дәүләтнең көчен күрсәткән.

Әхмәд ибне Хатика әл-Әздинең «Китабел-бәйтара»сыннан (ветеринария буенча китап) атларның яхшы сыйфатларын тасвирлаган иллюстрация. XIII гасыр

Һәр татар күчеп киләчәк җирнең флорасын, климатын, коры һәм дымлы һава торышының циклларын яхшы белгән. Ул географик фикерләү сәләтенә ия булган, терлекне кискен табигать шартларында күпләп кырылуыннан сакланган.

Горизонталь һәм вертикаль күченү булган. Горизонталь күченү Төньяк Евразия киңлекләрендә яшәүче татарлар өчен хас. Яз узып, коры һава циклы килеп, сулыклар кипкәннән соң, терлекне алар зур елга үзәнлекләре буенча төньякка таба – «җәйләү»ләргә куган. Печәнлек җирләр эзләп, Днепр буе, Урта Идел, Идел аръягы, Кама, Көньяк Урал һәм Себердәге Иртыш буйларына кадәр барып чыкканнар. Нәтиҗәдә, терлек утлап йөргән җирләрдә күчмәннәрнең яшәү урыннары – утарлар барлыкка килгән.

Көзен исә, шул ук юл белән, киресенчә, җылы якларлардагы «кышлау»га – Кырым һәм Төньяк Кавказдагы далаларга, Мангышлак, Арал һәм Балхаш күлләренә таба киткәннәр. Кайберләре кар юка булган урыннарда, Актүбә һәм Әстерхан тирәләрендә, хәзерге казакъ далаларында туктап калган. Мәгълүм ки, мондый җирләрдә терлек, тибенеп, кар астыннан азык тапкан һәм кар суын эчеп, сусавын баскан. Бу урыннарда яз бик иртә, февраль-март айларында ук килеп, тирә-як тиз арада яшеллеккә күмелгән.

Вертикаль күченү исә таулы урыннарда яшәүче татар-төркиләр өчен хас. Кышын алар түбәндәрәк – тау итәкләрендә мал көтсәләр, җәен исә, киресенчә, терлек өчен азык эзләп, тау битләрендәге көтүлек җирләргә менгәннәр, шунда икенче язны каршылаганнар.

Күчмәнлек, гади халык яки хәрбиләр өчен генә түгел, дәүләт җитәкчеләре өчен дә хас булган. Немец сәяхәтчесе Иоганн Шильтбергер: *«Мин дә Алтын Татариядә булдым. Әйтергә кирәк, бу илдә король (хан) һәм аның яраннары җәен-кышын хатыннары, балалар һәм мал-туар белән күченеп йөриләр, үзләре белән бөтен мал-мөлкәтне алып, тигезлек буенча бер көтүлектән икенчесенә күченәләр»,* – дип язып калдырган. Әл-Гомәри язуынча, ханнар кышны Сарай шәһәрендә уздырсалар, җәен исә далага һәм Урал тавы итәкләренә китә торган булганнар.

Ярымчүл, дала, урман-дала зонасы буенча күченеп йөрүнең катгый тәртипләре булган. Әйтик, сәяхәтче Гильом Рубрук: *«Һәр җитәкче үзенең көтүлекләренең чиген, шулай ук кышын, язын, җәен һәм көзен көтүне кайда көтәргә тиешлеген яхшы белә»,* – дип язып калдырган. Ханның рөхсәтеннән башка күченеп йөрү катгый тыелган.

Күчмә хуҗалык итү экосистемага уңай тәэсир иткән. Мал тоягы бер урынны озак таптамаган, көтү икенче циклда кире әйләнеп кайтканда анда инде куе һәм озын үлән үскән. Терлек үсемлек орлыкларының таралуына, туфракка иңүенә ярдәм иткән һәм туфракны үсемлек шытып чыгар өчен кирәкле органик ашлама белән баеткан. Күчмә терлекчелектән урман һәм сулыкларга бернинди зыян килмәгән.

Күчмә татар-төркиләр мөгезле эре терлек һәм сарык-кәҗә көтүләрен беркайчан да берләштермәгәннәр. Чөнки кәҗә белән сарык үләнне төптән кыркып ашый һәм сыер өчен яхшы азык калдырмый. Шунлыктан, сарык-кәҗәне калкулыкларга җибәреп, мөгезле эре терлек өчен елга буендагы көтүлекләрне файдаланганнар. Ә инде аларның мәйданы кечерәк булганда, сарык һәм кәҗәләрне мөгезле эре терлектән калган җирдә көткәннәр.

Алтын Урдада татарлар күчмә тормыш өчен иң кулай малларны – ат, сыер, сарык, кәҗә һәм дөя асраганнар. Мобиль тормыш ил-йорт, нәсел-нәсәп һәм мал-мөлкәт иминлеге өчен дә кулай булган. Һөҗүм итүчеләрнең ат тоягы тавышы ишетелү белән, аларның балалары, хатын-кызлары тиз арада качып өлгергән. Хәвеф-хәтәр тынганнан соң, алар үз биләмәләренә кире кайтканнар яки тынычрак урында төпләнеп калганнар.

Татарның аты үлән азыгын тоягы белән тибенеп, карны казып табарга сәләтле булган. Бу җирләрне тибен җирләр (табун һәм табын сүзләре шуннан килеп чыккан) дип йөрткәннәр. Әлеге күренеш урта гасыр сәяхәтчеләренең дә игътибарын җәлеп иткән. Әйтик, М.Поло: *«Татар бер айга бернинди азык-төлек алмыйча чыгып китәргә мөмкин, ул үзе тапкан киек кош-корт белән туклана, бия сөте эчә, ә аты болында утлап йөри, аның өчен арпа да, салам да алырга кирәкми»,* – ди. Ибне әл-Әсир дә: *«Татарлар утырып йөри торган атлар җиргә тояк белән тибенеп, үсемлек тамырлары ашыйлар, аларга арпа кирәкми»,* – дип язып калдырган.

Татарларда ат сәүдәсе дә зур уңыш казанган. Иосафат Барбаро әлеге хакта менә ниләр яза: *«Бу халык арасында ат сәүдәгәрләре бар: алар атларны урдаларыннан куып, төрле җирләргә чыгаралар. Фарсыга килгән бер кәрванда дүрт мең баш ат иде. Урдага килеп, бер көн эчендә мең, хәтта ике мең ат сатып аласыз икән, бер дә гаҗәп түгел, чөнки анда атлар көтүләре белән утлап йөриләр».* Атларны Греция, Кытай, Рим, Һиндстан кебек илләргә сатканнар.

Һәр сугышчының бердән алып бишкә чаклы аты булган. Армиядә 250 мең хәрби булган дип санасак, атларның саны 750 меңгә җиткән яки аннан да артып киткән дип уйларга мөмкин. Яугир, атларын алыштырып, ял итмичә йөзләрчә чакрым юл уза алган.

Моннан тыш, атларны ям – почта хезмәтендә дә уңышлы файдаланганнар. Марко Поло язуынча, моның өчен 300 мең ат тотылган: ун меңнән артык почта бинасы булган, зур стансаларда 400әр ат әзер торган, ә гадиләрендә 50дән алып 200гә чаклы ат асралган. Алмашка яңа ат әзер торсын өчен, еректан ук хәбәр белдерү максаты белән, җигүле ат дугасына кыңгырау такканнар.

Безнең көннәргә борынгы татар-төркиләрдән мирас булып «татар», «казакъ», «монгол», «якут» токымлы атлар калган.

Сыер һәм үгезләр сан ягыннан ат һәм сарыктан гына калышкан. Сыер – печәнгә, суга мулрак җирләрне таләп итүче, ерак араларга күченеп йөрер өчен уңайсызрак, чатнама суыкларга да чыдамсыз, үзенә күбрәк игътибар сорый торган мал. Шуңа ул ярымкүчмә һәм утрак тормыш өчен күпкә кулайрак булган. Иосафат Барбаро: *«Бу халыкта булган хайваннарның икенче төре – бик яхшы эре үгезләр. Алар хәтта итальяннар өчен сугымга да җибәрелә. Атларны Польшага куалар, ә бер өлешен Валахия аша Трансильваниягә, аннан Германиягә җибәрәләр, шуннан соң Италиягә алып баралар...»* – дип язып калдырган.

Үгез көчен йөк арбаларын, тәгәрмәчкә утыртылган юртларны күчерер өчен дә файдаланганнар. Плано Карпини: *«Кечкенә арбаларга бер үгез җитсә, зурысына өчдүрт, хәтта аннан да күбрәк үгез кирәк. Үгезләрнең саны олау зурлыгына бәйле. Шулай итеп сугышка барганнар яки башка урынга күченгәннәр»,* – дип яза. Г.Рубрук исә юртлы бер арбаны 22 үгез тартып баруын күрә.

Безнең көннәргә борынгы татар-төркиләрдән мирас булып сыерның «калмык», «казакъ» һәм «украин» токымнары калган.

Сарык һәм кәҗә. Гадәттә ярымчүл, таулы зоналарда кәҗәләр өстенлек алган, ә сарыкларның саны 5-10 баштан артмаган. Ә менә дала һәм урман-дала зоналарында аларның саны меңнәрчә башка җиткән. Географ әл-Гомәри, һәр яугир сугышка үзе белән утыз баш сарык алырга тиеш, дип яза. Димәк, 250 мең хәрбигә 7,5 млн. баш сарык туры килгән. И.Барбаро: *«Озын аяклы, озын йонлы һәм шундый ук койрыклы тәкәләрнең авырлыгы 50 фунт* тора»,* – ди. Безнең көннәргә борынгы татар-төркиләрдән мирас булып сарыкның «нугай», «каракүл», «татар», «карачай» токымлылары калган. Көньяк районнарда «курдюк» (татарча – койрык) токымлы сарыкларны яратып үрчеткәннәр. Аларның арт мае аеруча югары бәяләнә.

Озак вакытлар: «Кәҗә – ярлылар хайваны», – дип саналган. Үләт яки башка табигый хәвеф-хәтәрләр нәтиҗәсендә, эре терлек күпләп кырылып, матди хәл бик мөшкелләнгәч, кәҗә татарның җанын саклап калган: аңа сөт, ит һәм йон биргән. Вакытлар узу белән, йоныннан шәл бәйли торган «татар-нугай» (Оренбург) токымлы затлы кәҗәләр Россиянең символына әйләнә, ә сөте иң яхшы диетик ризыклардан санала башлый.

Ике өркәчле дөяләрне, гадәттә, Урта Азиянең чүл һәм ярымчүл районнарында күпләп үрчеткәннәр. Сәүдә кәрваннары белән алар Идел буеның барлык шәһәрләренә дә килеп җиткән. Бабаларыбыз үрчеткән дөя салкынга чыдам, калын йонлы булган.

* 1 фунт = 0,5 кг

Дуңгызчылык. Плано Карпини, татарлар дуңгызны бөтенләй асрамый, дип яза. Моңа ислам диненең тыюы түгел (ислам Алтын Урдада Үзбәк хан заманында гына дәүләт дине статусын алуын онытмыйк), ә дала шартларында дуңгыз белән күченеп йөрү мөмкин булмау төп сәбәп булган. Әмма Идел буе шәһәрләрендәге археологик казу эшләре вакытында дуңгыз сөякләре дә табылган. Аларны татар калаларындагы рус яки фин-угыр кварталларыннан калган дип уйларга мөмкин. Татарлар дуңгыз белән бик борынгыдан таныш булсалар да (Мәхмүт Кашгарыйда – тоңуз), аңа һәрвакыт тискәре мөнәсәбәт күзәтелгән: «Дуңгыз шакшы җир эзли», «Дуңгыз тизәк ашамыйча тора алмый». Итен азык буларак бөтенләй кулланмаганнар: «Дуңгыз бик симез дә – ашауга ярамый».

Мал суюның тәртипләре Чыңгыз ханның кануннар җыентыгы – «Яса»да теркәлгән. *«Мал итен ашыйсы килгәндә аның аякларын бәйләп, корсагын ярырга һәм йөрәген кул белән кысарга кирәк. Җаны чыккач кына, мал итен ашарга мөмкин»,* – диелә анда. Әмма ислам дине таралгач, бу гадәт бетерелә, ул фәкать калмыкларда гына сакланып кала.

Археологик мәгълүматларга караганда, мөгезле вак терлек 2 ай-3,5 яшь; мөгезле эре терлек 5 ай-6 яшь аралыгында; атлар 1-12 яшь; дуңгыз 1-2 яшьтә чалынган. Атларның, гадәттә, картларын, ерак сәфәрләргә яраксызларын гына суйганнар һәм итеннән казылык ясаганнар. Дөяне исә 40-50 ел асраганнар, аларны имгәнгән яки йөк ташырга яраксыз яшькә җиткәннән соң чалганнар.

Археолог В.И.Цалкин тикшерүләренә караганда, татарларның дала, урман-дала шартларында яшәгән мөгезле эре терлеге, Русь кенәзлекләренекенә караганда, уртача 10 см.га, ә атлар исә 3 см.га зуррак булган.

Ветеринария. Күчмәннәр, терлек карау белән бергә, аны дәвалау серләрен дә белгәннәр. Алар гасырлар дәвамында сынган сөякне дәваларга, акушерлык эшенә, үлгән яралгыны алырга өйрәнгәннәр, паразитларны кудыра торган үләннәрдән дару ясый белгәннәр. Агулы үсемлекләрнең согын май итеп файдаланып, җәрәхәтләрне эшкәрткәннәр, шулай итеп, терлек ярасындагы чебен личинкаларын үтергәннәр. Әмма себер язвасы, үләт, чума, тилчә, котыру кебек авыруларны дәвалый алмаганнар. (Телебездәге «мур кыргыры» дигән гыйбарә шул чорларның ядкяре.)

Шулай итеп, Алтын Урдада, аеруча Мәмлүкләр Мисырында ветеринария фәне чәчәк аткан. Бу юнәлештә гарәп һәм төрки телләрдә махсус китаплар язылган. Ә менә Россиядә, *https://dog-life.com/* сайтындагы мәгълүматка караганда, ветеринария фәне шактый соң – XVI-XVII гасырларда гына барлыкка килгән.

Терлекче, мал тотучы бабаларыбыздан калган күчмәнлек традициясе һәр татарның канына сеңгән. Ял көннәрендә шәһәр урамнарына гына игътибар итегез әле: татарлар күпләп туган авылларына агылу сәбәпле, урамнар бушап кала. Ферма малларын да җәйләүгә куу гадәте хәзерге көнгә кадәр саклана диярлек.

Бөек шагыйребез Габдулла Тукай да:

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!

– дип, тикмәгә генә язмаган.

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2022

Дөнья тарихында шанлы татар-төрки эзләре

Айрат Чанышев

Татар-төрки дәүләте ничек Руська, Россиягә әйләнгән?

IX гасыр азагында татар-төрки Киев каһанлыгын Скандинавиядән – Даниядән килгән варягларның (викинглар, норманнар) росс (рос) дип аталган кабиләсе басып ала. Киев Русе, Россия дигән вакытта, без бу илнең үз тарихи атамасын түгел, ә аны яулап алган росслар этнонимын кулланабыз. Гомумән, хәзер Россия дип аталучы бу ил элек, Алтын Урданың олысы буларак, Московия дип исемләнгән, ә халкына московитлар дигәннәр. Бары тик 1721 елда гына Московия исемен Петр I Россиягә үзгәрткән. Ә «русский» дип аталучы халык элек гомумән булмаган, аның урынына великоросс, малоросс, белоросс этнонимнары кулланылган. 1926 елгы халык санын алу вакытында гына, великоросс урынына, «русский» этнонимы кертелгән.

«Made in China» татарның ашинасыннан яки татар-кытай мөнәсәбәтләре

Хәер, мондый исем алмашу тарихта сирәк күренеш түгел. Мисал өчен, Кытай дәүләтен алыйк. Урта гасырда Үзәк Азиядә Кидань дип аталучы мәшһүр татар-төрки дәүләте булган. Кытайда төрле болганышлар-чуалышлар башлануыннан файдаланып, киданьнәр X гасырда бу илдәге Тан династиясен бәреп төшерәләр һәм яңа татар-төрки Ляо династиясенә нигез салалар. Танлылар Кидань халкын катайлар (хатайлар, кытайлар, хытайлар, хитайлар) дип атап йөрткәннәр. Ә дәүләтләрен Каракытай дип исемләгәннәр. Татар-төркиләрдә борыннан ук халыклар ак һәм карага бүленгән. Мәсәлән, ак татарлар һәм кара татарлар. Татарның катай/кытай кабиләсеннән бу ил үз атамасын алган да инде.

> «Лев Гумилев фикеренчә, татарның ашинасыннан кытайлылар үз илләрен Чина дип атый башлаганнар да инде. Гомумән, Кытай белән татар-төркиләр күп идарә иткән.

Сүз уңаеннан, Тан династиясенә дә тукталып китик. Таннар да татар-төрки кавеме икән бит! Борынгы бабаларыбызның бу династиясе Кытай белән 7 нче йөздән X гасыр башына кадәр идарә иткән. Кытай дәүләтенең рәсми тарих концепциясе буенча, Тан династиясе вакытында Кытай дәүләтенең чикләре

Тын океаннан алып Каспий диңгезенә кадәр килеп җиткән икән. Шул чордагы күпсанлы мөстәкыйль төрки каһанлыклар, династиясе татар-төрки булганга, бу дәүләтне үзләренеке дип исәпләгәннәр, Тан империясе белән ныклы сәяси һәм хәрби союзда торганнар. Мәсәлән, Тан чоры Кытаеның күп хәрби бәрелешләрендә төп рольне татар-төрки гаскәрләре уйный торган булган. Кытайга янәшә булган каһанлык, чжурчжен/монгол халыклары үзләрен Кытай вассаллары дип исәпләгәннәр. Әмма кытайлар бу фактка күз йомалар, урта гасырлардагы бар төрки каһанлыкларны да Кытай империясенең бер өлеше дип игълан итәләр.

Кытайлылар үзләренең илләрен Чина дип атыйлар. Кытайда җитештерелгән барлык товарларга да «Made in China» тамгасы сугылган. Илнең бу атамасы да – татар-төркиләрдән. Алда искә алынган Тан династиясенә татар-төркиләрнең VI-VIII гасырда яшәгән затлы ашина кабиләсе нигез салган. Лев Гумилев фикеренчә, татарның ашинасыннан кытайлылар үз илләрен Чина дип атый башлаганнар да инде. Гомумән, Кытай белән татар-төркиләр күп идарә иткән. Алда саналган Ляо һәм Таннан тыш, Кытайдагы Цинь, Төньяк Вэй, Си Ся, Юаньнәр дә – саф татар-төрки династияләре.

Әлбәттә инде, бу вакытта Кытайның алтын чорын тәшкил иткән Юань династиясенә аерым тукталырга кирәк. Ул – Чыңгыз балалары династиясе. Чыңгызның оныгы Хубилай хан заманында әлеге илнең чикләре Балканнан алып Океаниягә кадәр җиткән. Алтын Урда дәүләте, шул исәптән Рәсәй/Московия дә әлеге империянең бер олысы гына булып исәпләнгән. Бу хәл 1266 елга кадәр дәвам иткән. Кытайлылар мәктәп дәреслекләрендә үз дәүләтләренең тарихи җирләре дип Тан династиясе чорындагы Кытай картасын урнаштыргач, Кыргызстан һәм Казакъстан дәүләтләре протест белдергән иде. Ә менә Россиядән протест белдерүче булмады. Чөнки Кытай – Россиянең стратегик союзнигы. Кытайлылар исә: *«Тан династиясе заманында Кытайның чикләре Иделгә кадәр булган. Ә менә Юань династиясе чорларында Кытайның көнбатыштагы ге-*

Каракытай яугире

ографик чикләре хәзерге Италиягә кадәр барып җиткән. Сез Чыңгыз һәм аның балаларын баскынчылар, безне золымда тотучылар дип исәплисез, ә бездә исә алар – милли геройлар. Без Чыңгыз балалары идарә иткән чорны илнең иң алдынгы, алтын чоры дип исәплибез, Чыңгыз ханга һәйкәл куйдык, аның зур музеен төзедек, аны шанлап 30 серияле фильм төшердек. Шуңа да Чыңгыз балаларының ат тоягы аяк баскан бар җирләр дә – Кытай җирләре», – дип җавап бирделәр. Юань иероглифы – байлыкны, бәрәкәтне, алтынны, акча дигәнне аңлата. Әлеге символ Кытайдагы чыңгызый Юань династиясе хакимлек иткән вакытта бу илнең алтын чоры дигән мәгънәне белдерә.

Чыңгыз ханның оныгы Хубилай Чыңгыз империясенең башкаласын Каракорымнан Яньцзинга (хәзерге Пекин) күчерә. Аның исемен Ханбалугка (хәзерге әйтелеше – Ханбалык) үзгәртә. Шәһәр атамасы саф татарча – Ханбалуг, ягъни хан шәһәре Балуг – иске татар телендә шәһәр дигәнне аңлаткан. Шуңа да кытайлылар үзләре бу шәһәрне татар шәһәре – Даду дип атаганнар. Да иероглифы – берлек санда, татарны аңлата, ду – шәһәр. Хубилай үзен татар дип исәпләгән, бернинди дә монгол дип түгел, ә Балканнан алып Океаниягә кадәр сузылган үз дәүләтен Татария дип атаган. Тарихтагы Бөек Татария (Великая Татария яки Тартария) нәкъ менә Хубилай һәм аның дәвамчылары чорындагы Татария дә инде. Хубилайдан соң идарә иткән бар императорларның исем-шәрәфләре дә саф татарча: Тимур, Хайсан, Шидебала, Ясән-Тимур, Туг-Тимур, Туган-Тимур һ.б. Димәк, Кытайдагы 200 елга якын дәвам иткән татар-төрки династиясе ике гасыр буе үзенең татарлыгын саклаган. Династиянең соңгы императорының исеме дә саф татарча – Туган-Тимур.

Хубилай чорындагы татар империясенә бәйле кызыклы фактлар бар. Алтын Урда, бу дәүләтнең бер олысы буларак, империя алып барган бар сугышларда да үз гаскәрләре белән катнашырга тиеш булган. Московия дә, Алтын Урданың бер өлеше буларак, шулай ук яугирләр җибәргән. Хубилай заманында Юань, төньяк Кытайны империягә кушу өчен, андагы Сун дәүләте белән сугыш алып барган. Менә шул сугыш вакытында Московиядән килгән яугирләр аеруча каһарманлык үрнәкләре күрсәткәннәр һәм Хубилай ханның күңелен яулап алганнар. Шуннан инде Хубилай московитлардан үз гвардиясен төзегән. Хан сараен, башкала Ханбалыкны Московиядән килгән яугирләр саклаган. Кытайда аларны «урусутлар» дип атап йөрткәннәр. Башкаланы һәм хан сараен саклаучы 10 меңлек урусутлар гаскәрен Суздаль кенәзе Григорий җитәкләгән. Урусутлар, бар походларында да, шулай ук ауга, күңел ачарга чыккан вакытларда да ханны саклап барганнар. Хубилай һәм аннан соң идарә иткән башка императорлар фәкать шул урусутларга гына ышана торган булганнар. Элитар, гвардия гаскәрләре буларак, урусутлар күпсанлы өстенлекләрдән, ташламалардан файдаланганнар, бик зур хезмәт хакы алганнар. Һәм дә инде, бу кадәр яхшы тормыштан баш тартырга теләмичә, җирле халык белән гаилә корып, Кытайда яшәргә торып калганнар. Туг-Тимур хан аларга Ханбалыкның төньягында зур җир кишәрлекләре бүлеп биргән. Хәзерге Пекинның төньягында урнашкан җирләрдә бүгенге көнгә кадәр шул урусутларның нәсел дәвамчылары яши дә инде.

Германия белән Франциягә татар-төркиләр нигез салган!

Франция иле дә элек Галлия дип йөртелгән. Тик аларны франклар дип аталучы герман кабиләләре берләшмәсе яулап алган. Җирле халыкны меңәрләп кырып-үтереп, исән калганнарын золымда, коллыкта тотып, алар бу илдә үз хакимлекләрен урнаштырган. Германнарны Германиядән килгән кабиләләр дип исәплиләр. Тик борынгы «Франклар тарихы» китабының авторы Григорий Турский фикеренчә, алар Германия дигән илгә Паннониядән (Венгриядән) килгәннәр. Германиядәге җирле халыкны кысрыклап, шулай ук турап-үтереп, анда үз илләрен булдырганнар. Венгриядән килгән булгач, бу франклар, әлбәттә, һотлар (готлар) инде. Нигездә, остһотлар – көнчыгыш һотлар.

Һотларга аерым тукталырга кирәк. Алар Көнчыгыш Аурупа тигезлегендә яшәгән, аннан һуннар белән Аурупага чыгып, нигездә, Венгрия җирендә торып калганнар. Бер өлеше Рим, Галлиягә барып чыккан, шактый өлеше хәзерге Германия җирләрендә төпләнгән. Тарихчылар аларны герман кабиләләре итеп күрсәтәләр, гәрчә моңа бер генә тарихи дәлил дә юк. Бу фәкать һотларның хәзергеләре герман телендә сөйләшкәннән генә чыгып әйтелә. Безнең галимнәргә һотларның да татар-төрки булулары хакындагы мәсьәләне күтәрергә вакыттыр, бәлки. Б.э.ның башында Кырым, Дон һәм Днепр буйларында нинди герман кабиләләре булырга мөмкин?!.

Ә менә һотларның германлашкан татар-төркиләр булуына дәлил җитәрлек. Германиянең үзендә үк германлашкан татар-төрки баварлар (Бавария), түреңнәр (Тюренгия) турындагы тарихи хезмәтләр аз түгел. Тагын бер тарихи эпизод: Тәре походлары чорында германлылар фәкать беренче походта гына катнашкан. Анысында да, Якын Көнчыгышка барып җиткәч, кире борылып кайтып киткәннәр. Калган походларда, гомумән, катнашмаганнар. Ни өчен? Чөнки тәре походы вакытында Якын Көнчыгышта (хәзерге Мисыр һәм Һиндстанда) татар-төрки Мәмлүк мәмләкәте-дәүләте булган. Мисырлыларның үз армияләрен, гадәттә, күчмә халыклардан, нигездә, кыпчаклардан төзегәнлеге мәгълүм. Кыпчаклардан булган, әсирлеккә эләккән Бәйбарыс атлы бер яугир, илдә восстание оештырып, үзен ил башы итеп игълан итә. Ике гасыр буе Мисырны һәм Якын Көнчыгышны татар-төркиләрнең Мәмлүк дәүләте тота. Тәре йөртүчеләргә каршы алар төп көчне тәшкил итә дә инде. Мәмлүкләр, яу белән килгән германлыларны күргәч: «Без – бер халык, бер үк телдә сөйләшәбез, безгә ни өчен сугышырга?» – дигәннәр. Нәтиҗәдә, германлылар тәре походын ташлап кире кайтып киткәннәр һәм башка катнашмаганнар.

Нигездә, һотлардан булган франклар үз илләрен «Франкия», «Франкланд» дип аурупача түгел, ә «Франко-Эль» дип атаганнар. Француз галимнәре бу гыйбарәне «Франклар иле» дигәнне аңлата дип язалар. Күренә ки, франкларның шул вакыттагы ил атамасы да саф татарча яңгырый.

Германлыларның татар-төрки тамырлары турында күренекле тарихчы, язучы Морат Аджи да күп фактлар китерә. Мәсәлән, алардагы Йол дип аталучы бәйрәм татар-төркиләрдән алынган. Немецларда борынгы татар-төркиләрдәге кебек үк биек таулар культы бар. Герман нацистлары Альп, Кавказ (андагы Илбарыс тавын, русча – Эльбрус), Тибетның биек тауларын изге дип исәпләгәннәр. ■

Казан татарлары*

(Тарихи- этнографик очерк)

Аристарх Сперанский

1913-1914 нче елларда Парижда басылып чыккан «Азбука»да (авторы – Е.Бем) татар баласының рәсеме урын алган. Шунда ук милли музыка һәм эш коралларын да күрә аласыз.

* Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2022) санында.

Татар хатыннары кунакка барганда бөтен саннарын юалар

Татарлар тышкы кыяфәтләренә зур игътибар бирәләр. Һәр шимбә сакалларын тигезләп кыркалар, ике атна саен башларын чистартып кыралар, җомга көнне иртән мунча керәләр.

Татар хатыннары бик чиста йөриләр, киенү-ясану, бизәнүне яраталар. Кунакка барганда башта бөтен саннарын юалар, чиста эчке күлмәкләр кияләр, битләренә күп итеп кершән, кытай иннекләре сөртәләр, күзләрен зурайтыр өчен каш-керфекләрен – карага, тырнакларын кызгылт-сары төскә буйыйлар, тешләренә кара буяу сөртәләр[1]. Шуннан соң гына матур бәйрәм күлмәкләрен, балдак-беләзекләрен кияләр, алкаларын, муенсаларын тагалар, хушбуйлар сөртәләр, күкрәкләренә берничә тамчы роза мае тамызалар. Шулай киенеп, алар кунакка баралар. Тик кая? Бер ир-ат булмаган бүлмәгә, хатын-кызлар янына... Аларга якын туган ир-атка да күренергә ярамый[2]. Кунакка килү белән, алар башта абыстайны сәламли, аннан соң азанчы хатыны белән күрешә, сәүдәгәр хатыны белән исәнләшә, алардан соң гына мещан хатыннары янына килә. Баш иеп, кочып, үбешеп исәнләшү гадәте юк: ике кул биреп күрешәләр. Әгәр дә ялгыш беренче рәттә сәүдәгәр хатыны янына килеп исәнләшсә, абыстай инде аның белән кул биреп күрешми, ике кулын ачып, буш уч төпләрен генә күрсәтә, шул рәвештә үпкәсен белдерә.

> **«Татарларның өйләрендә хатын-кызлар күп булуга карамастан (уннан да артык булулары ихтимал), алар арасында тынычлык саклануы сокландыра.**

Татарларның тынычлык саклаулары сокландыра

Татарларның өйләрендә хатын-кызлар күп булуга карамастан (уннан да артык булулары ихтимал), алар арасында тынычлык саклануы сокландыра. Шәрык кануннары буенча, иренә ярамаган җәнҗаллы хатын бик тиз аерылып җибәрелергә мөмкин. Бу очракта ире ул хатынга өйләнгәндә алган калымның яртысын кире кайтарып бирә. Хатын да, аерылырга карар кылса, иренә аннан алынган калымның яртысын кире бирә һәм бу турыда муллага әйтә, мулла аларга аерылышу шәһадәтнамәсе бирә, шуннан алар икесе дә яңа гаилә корырга хаклы була.

Татарлар икмәк пешерергә бик оста булалар

Татарлар бик пөхтә яшиләр: өйләре чиста, иске йортларда да мичләрен елга берничә мәртәбә чистартып агарталар. Хатыннар йортта тәртип, чисталык саклый, икмәк пешерергә бик оста булалар. Алар ясаган каймак бик куе, тәмле була. Сыер сауганда чиста алъяпкыч бәйлиләр, сыерның җилемен җылы су белән юалар, сөт савытын чиста бистәр белән каплап ябалар. Авылларда катыкны (кайна-

---

[1] Сүз корым белән агарту хакында барырга тиеш. – *Ред.*
[2] Автор монда арттырып җибәрә, бертуган абыеңа һәм энеңә күренергә ярый.– *Ред.*

Казан татары. ***П.Б.Ламбин рәсеме.*** **1889 ел**

тып пешерелгән сөт) көздән зур кисмәкләргә салып, бозлатып катыралар, кирәк булганда алып, җылытып эретеп ашыйлар…

Татарлар биш мәртәбә намаз укыйлар

Аллага табынуларының да үзенчәлекләре күп. Халыкның Аллаһка табыну урыны – бохара үрнәгендә Мәккәгә каратып салган мәчет. Мәчетләр – ике катлы зур йорт, аның уртасына биек манара корылган, манара башында – тимердән ясалган ярымай. Манара тәрәзеннән азанчы көн саен татарларны намазга чакыра.

Мәчет бинасы икегә бүленә. Алгы якта намазга килүчеләр аяк киемнәрен салып калдыралар. Үзләрен түргә керергә лаеклы дип санамаучылар да шул бүлмәдә кала. Икенче бүлмәгә керергә өч ишек бар. Уртадагысы – зур, аның янындагылары кечерәк. Көньяк стенада михраб дип аталган уем ясалган. Андагы такта өстендә Коръән китабы ята. Бу – мәчетнең иң изге урыны. Мулла, гадәттә, шул уем янында утыра, намазчылар аның артында рәткә тезелеп басып тора яисә утыра, мулла белән бергә аңа ияреп намаз укый. Уң якта агачтан ясалган дүрт баскычлы готик кафедра – мөнбәр. Бу урында мулла, кулына каен агачыннан ясалган озын таяк тотып, яттан Коръән сүрәсе укый. Уемга каршы яктагы ишек алдында баганалар өстенә малайлар өчен балкон куелган. Уемның ике ягына, кайвакытта, матур итеп язылган гарәп телендәге Коръән сүрәләре текстлары куялар. Түшәмгә зур кәндил эленгән, стеналарга шәмдәлләр куелган. Идәндә һәрвакыт келәмнәр. Мәчетнең тирә-ягында – буяулы рәшәткә, янында су коесы бар.

Татарлар, барлык мөселманнар кебек, Коръәндә каралганча көнгә биш мәртәбә намаз укыйлар. Мәчеттә гыйбадәт шулай уздырыла: азанчы манарадан азан әйтә, халык 15 минут дәвамында мәчеткә җыела. Һәркем үз урынына килеп тезләнеп утыра. Михраб алдында җыелган халыкка карап утырган мулла, торып, михрабка борылып баса. Намазчылар да аякларына баса, догага әзерләнә – ике кулларын күтәреп, баш бармаклары белән колак яфракларына кагылып акрын гына «Аллаһу әкбәр» (Аллаһ бөек) дип әйтәләр, аннан соң кулларын корсакларына куялар да Коръәннең беренче сүрәсен һәм тагын кайберсен укыйлар, билдән баш ияләр, җиргә баш орып табыналар, тезгә басалар, яңадан җиргә баш оралар, шул ук вакытта догалар укыйлар. Шул ук гамәлләр яңадан кабатлана. Ахырда гыйбадәтчеләр уңга, сулга борылып сәлам бирәләр. Калган 4 гыйбадәт тә шул тәртиптә башкарыла. Аермалы буларак, өйлә намазында рус патшасына, патша йортына, гаскәрләренә хөтбә укыла. Хөтбә укырга мулла кулына озын каен таяк тотып, бик эре кыяфәт белән мөнбәргә (авторда – кафедра) менә; икенче баскычына менгәч, арыган кеше кебек утырып тора да яңадан менеп баса. Шулвакыт азанчы аның янына килеп, азан әйтә, манарадан әйткән сүзләрен кабатлый. Мулла, таягына таянып, моңлы тавыш белән хөтбә әйтә, Коръәннең беренче сүрәсен укый.

Татарлар төне буе вакытны гыйбадәттә уздыра

Казан татарларының бәйрәмнәре – биш. Өчесе дини – Җомга көн, Ураза һәм Корбан гаете, икесе халык бәйрәме – Сабан туе һәм җыен.

Рамазан – мөселманнарның 29-30 көнлек уразалары. Мөхәммәд (с.г.в) Коръәндә аларга (мөселманнарга), Аллаһы Тәгаләгә якынаю өчен, ел саен бер ай ураза тотарга боерган. Казан татарлары Рамазан вакытында мәчеткә ешрак йөриләр, бер ай дәвамында таңнан алып караңгы төшкәнче ашау-эчүдән тыелып торалар. Ак җепне кара җептән аерып булмый башларлык булып караңгы төшкәч, аларга таң атканчы ашарга-эчәргә рөхсәт ителә. Ураза ел саен 11 көнгә алданрак башлана, шунлыктан ул ел дәвамында төрле фасылга туры килә, җәй көннәрендә бик комачау, авыр була. Җәйге 17 сәгать озынлыктагы көннәрне ашамый-эчми уздыру тик утырган кешегә дә җиңел түгел. Көне буе басуда, эссе кояш астында, авызга йотым су да алырга ярамаган шартларда эшләргә мәҗбүр булган авыл халкы өчен нинди авырлык икәнен әйтеп тә торасы юктыр. Татарлар, караңгы төшкәч, төне буе вакытны гыйбадәттә уздыра. «Әл-Кадер» дип аталган кичә (төгәл билгеле түгел, так көннәрдә. – Ред.) изге санала. Ул төнне беркем дә йокламаска тиеш, мәчетләр халык белән тулы була. Бу төндә, Аллаһ әмере буенча, фәрештә, җиргә төшеп, Мөхәммәдкә (с.г.в.) Коръән иңдергән.

Рамазанда һәр мөселман фитр сәдакасы бирергә һәм байлыгы булганнар милегенең уннан бер өлешен ярлыларга, мохтаҗларга зәкят итеп өләшергә тиеш. Казан татарлары кулдагы һәм тауарга түләгән акчаны гына бүләсе милек санына куялар. Төп милек – йорт-җир, хәзерләнгән кирәк-яраклар бу исәпкә кертелми.

Рамазан кайсы вакытта ачык һавада оештырылган гомуми гыйбадәт белән тәмамлана. Ул көнне Гает дип йөртәләр, бәйрәм ашы итеп майга салып пәрәмәчләр, бөккәннәр пешерәләр, аларны бал ягып ашыйлар. Өч көн дәвамында кунакка йөрешәләр, бер-берсен сыйлыйлар, тәбриклиләр.

Рамазаннан соң ике айлап вакыт узгач, мөселманнарда Корбан бәйрәме була. Бу бәйрәм корбан чалып, сүзсез буйсынуларын онытмас өчен, Ибраһим пәйгамбәрдән (г.в.) Аллаһка эчкерсез, тайпылышсыз бирелгәнлек үрнәге итеп куелган. Кичтән башлап икенче бәйрәм көн уртасына кадәр, корбан ите әзерләнгәнче башка ризык ашамыйлар. Кайберләре яңа айда 6 көн дәвамында, төнлә белән туйганчы ашап, көндез ашау-эчүдән тыелып, янә ураза тоталар.

Корбан бәйрәме көнне Гает намазыннан соң өйләренә кайтып, әзерләп куйган мал-туарны корбанга чалалар. Корбан хайваннары санын татарлар йорттагы җәмәгать исәбеннән чыгып, ярлы-мохтаҗларны, бигрәк тә муллаларны да өстәп билгелиләр. Гадәттә, бер кешегә – бер сарык яки тәкә, сыер яисә дөя – җиде кешегә.

Йорт хуҗасы, кем булуына карамастан (кенәз морза, мещан), корбан хайванының берсен үзе чалырга тиеш. Корбанның башын Мәккәгә каратып, Аллаһ исемен әйтеп чалалар. Корбан итен шунда ук казанга салып пешерәләр дә Аллаһ исеменә багышлап ашыйлар.

*Русчадан **Николай Петров-Текин** тәрҗемәсе*

Ахыры киләсе санда ■

Безнен мирас №4 апрель 2022

Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2022) санында.

Истанбул мәктүбләре

Фатих Кәрими

Бәкләр Бәге сарае

Безнең мирас №4 апрель 2022

22 нче мәктүб

Истанбул тәэссораты

Истанбулга җитеп бугаз эченә кергәч тә, пароходның бер ягыннан икенче ягына йөгерә-йөгерә ике як сахилне *(диңгез ярын)* карарга башладык. Бер генә җирне дә күрмәенчә калдырасы килми. Сахил шулкадәр гүзәл вә шулкадәр латыйфтыр *(матур)*. Иптәшләрем Гөлсем, Рокыя вә Мәрьям ханымнар Истанбулга беренче мәртәбә киләләр, бугаз эчен беренче мәртәбә күрәләр. Шул сәбәпле бугаз эченең ләтафәте *(матурлыгы)* вә сахилләрнең гүзәллеге аларның бигрәк тә хушларына китте.

«Гүзәллек вә ләтафәт монын кай җирендә, кай җире моның бу кадәр күңелләрне җәлеп итә?» – дип сорадым. «Бөтен природасы гүзәл, әнә шуның өстендәге биналары, һәйбәт сарайлары вә шулар илә бергә үк тора торган җимерек өйләре, хәтта тәрәзәләреннән чыгарып кибәргә элгән керләре дә гүзәл, бөтен җире гүзәл», – дип җавап бирделәр. Аларның бу җаваплары бик дөрест вә бик хаклы иде. Природасы гүзәл вә өстендәге һәйбәт сарайлары һәм шулар янындагы җимерек өйләре дә гүзәл.

Ләкин бу гүзәллек моннан унбиш ел элек мин Истанбулны беренче мәртәбә вә 12 ел элек икенче мәртәбә күргәндә дә бар иде. Бунлар ул вакытта да шулай иде. Инде мин Истанбулны өченче мәртәбә күргәндә һәм дә бишьеллык хөррият дәвереннән соң күргәндә, ул җирләрнең табигый ләтафәтләре өстенә, әллә никадәр сәнәгый вә гомрани *(мәдәни)* ләтафәтләр артканлыгын күрергә тели идем. Ләкин мәгаттәәссеф *(кызганыч)*, үзгәреш юк иде. Бугаз эченең чәчкәләре

Долма Бакча сарае капкасы

булган Бәкләр Бәге, Долма Бакча сарайлары әүвәлгечә үк сүнек кенә зыя нәшер итеп *(нур таратып)* торалар. Янган Чыраган стеналары җимерек, түбәсе ачык, тәрәзәләре юк. Бу да ислам дөньясы кеби үзен ихья итүчеләрне *(тергезүчеләрен)* көтә…

Истанбул элек мин күргәндәгегә караганда байтак үзгәргән. Бабы Гали җаддәсенең *(урамының)* ике ягында тротуарлар бар. Урамга түшәлгән таш тигез вә йөрергә уңайлы гына. Урамның ике ягында фонарьләр бар. Кычкырта-кычкырта автомобильләр үтеп китә. Урамнарның кайсылары бераз киңәйгән. Зур биналар арткан. Бабы Гали җаддәсендәге дүрт-биш катлы, гүзәл биналы «Мәсәррәт» отеле урынында элек кечкенә бер бәкъкаль *(бакалея)* кибете бар, аның иясе грек иде. Мәктәптән чыкканда кайвакытларда без аның кибетенә кереп 10 паралык пәйнир *(сыр)* илә 10 паралык икмәк ашый торган идек. Хәзер бу бинаны шамлы мөселман сәүдәгәрләреннән Әхмәд Гобуд әфәнде вә берадәрләре *(ир туганнары)* салдырганнар. 60 мең лираларга *(ярты миллион сумга)* төшкәнен, Гобуд әфәнделәрнең дәхи дә шуның шикелле берничә зур биналар салдырганлыкларын, айлык әллә ничә мең лиралар доходлары барлыгын сөйлиләр.

Бабы Гали җаддәсеннән Мәхмүд паша җаддәсенә чыгар өчен ошбу «Мәсәррәт» отеле тугрысында элек бик тар гына бер тыкрык булып, аннан арба йөри алмый иде. Менә хәзер шул тыкрык бик һәйбәт, киң бер урам булган. Моның түбән ягында Истанбулның мәркәз почтаханәсе бар. Буның бинасы шулкадәр гүзәлдер ки, Яурупаның кайсы гына пайтәхетенә илтеп куйсаң да, иң беренче зиннәт булачактыр. Яныннан үткән саен, ирекле-ирексез борылып үзенә карап кальбән *(чын күңелдән)* бер сәлам биреп китәсең. Шул ук тыкрыкта бишәр-алтышар катлы яңа яки яңартылган биналар тезелеп киткән. Буларның байтагысы мөселманнарныкы вә берсе – хәзерге шәйхелислам Җәмаледдин әфәнденеке, берсе Гази Мохтар пашаныкы икән. Шәйхелислам Җәмаледдин әфәнденең бу бинасыннан гына доходы айга 15 мең лира кадәр икәнлеген, дәхи дә башка җирләрдә дә мал, милекләре күп булганлыгын сөйлиләр. Димәк ки, шәйхелислам хәзрәтләре фәкыйрь вә мәскәнәт *(мескен)* тарафдары вә дөньядан бизгән бер зат түгелдер.

Бабы Гали җаддәсендә биналар төзәлгән, арткан, яңадан салынган. Менә «Мәсәррәт» отеленың түбән ягында гына Истанбулның мәшһүр газеталарыннан «Сабах» матбагасының үз бинасы. Миһран әфәнде матбагага махсус дүрт катлы итеп гүзәл бина салдырган. Тәрәзәләре зур, эче һава газы берлән яктыртылган. Безнең «Мәсәррәт» отеленең астындагы каһвәханә дә әүвәлге төрек каһвәханәләренә беңзәми *(охшамый)*. Зур, биек тәрәзәләре берәр генә кисәк зур пыялалардан куелган. Эче якты. Кич берлән урамнан караганда кып-кызыл фәсләр илә бергә катнаш ап-ак чалмалар вә соры гаскәр бүрекләре – барсы бергә кушылып, бер вазага тутырып куйган чәчәк төсле гүзәл күренеп тора.

Әнә минем номерның тәрәзәсеннән күренеп тора: Париж тегүчелек мәктәбеннән шәһадәтнамәле Госман Зәки, доктор Бәхри Гыйсмәт әфәнденең зур вывескалары, шундый ук рәттән тезелеп киткән «Тәфиз», «Канәгать», «Гайрәт», «Шәфәкъ», «Заман» җәмгыять китапханәләре, Ибраһим Назыйф, Гали Хәйдәр аптекалары. «Икъдам» газетасының үзенә махсус салдырган алты-җиде катлы «Икъдам юрду» да бик матур. Биеклек ягыннан Бабы Галине һәм аның күршесендәге искергән бер мәсҗед манарасыны байтак артта калдырып киткән. Бабы Гали каршындагы «Рәснә» фотографханәсе дә бик гүзәл бинадыр. Бабы Галинең күршесендә генә бер әрмәнинең парикмахерские да зарарсыз гына пакьтер.

Чыраган сараеның хәзерге күренеше

Менә шулай итеп, байтак кына үзгәрешләр бар. Бер Бабы Гали бистәсендә генә түгел, башка җирләрдә дә шулай. Ләкин заһирдә *(тыштан)* күргән бу үзгәрешләрнең эчке якларына кереп таныша башласаң, тагын ук күңел төшә, тагын ук: «Нинди генә бер бәддога төште икән бу төрек башына, нинди генә бер начар тамыр бар икән бу мөселманнарда?» – дип сорыйсың килә.

Минем отельнең назыйре Мостафа әфәнде атлы бер төректер. Отель Истанбул ягындагы номерларның иң беренчесеннән санала. Эчендә мич юк, ашарга ресторан юк, чәй эчәргә самавыр юк, ванна юк, телефон юк, подъемный машина юк. Ләкин бунларның юклыгы өчен бернәрсә дә әйтеп булмый, чөнки Истанбул ягындагы отельләрнең берсендә дә бунлар юктыр. Чәйне монда бездәге кеби самавырдан эчмиләр. Каһвә эчәләр. Чәй эчсәләр дә, суык вакытта җылыныр өчен бер генә стакан эчәләр. Ашханәләр урам тулы. Номерда ресторан булмаса да ярый. Мич урынына мангал ягып, шуның тирәсендә җылынып утыралар. Ул мангалдан чыккан күмер исе «Вакыт» мөхбиренең башын авырттыра, миен зәһәрли икән, алар аны дикъкатькә алырга мәҗбүр түгелләр. Теләгән кеше Бәк Углындагы христиан номерларына барып торырга мөмкин. Анда һәммә әсбап-истирахәт хәзер.

Әмма менә бүлмә эчендә язу язарга өстәл юк, юынырга умывальник юк. Коридорга чыгып Җәмали харчевнигындагы шикелле общий кранттан юынырга кирәк. Бу да бер әйбер түгел. Ләкин минем коридордагы крант бозылган. Су тамып кына ага. Юыну читен. Төзәттерергә үтенеп хезмәтчеләр аркылы әллә ничә рәт конторга әйттердем. Юк, төзәлми. Ниһаять, үзем Мостафа әфәндегә шуны төзәттерергә ике-өч мәртәбә әйттем. «Бакарыз, әфәндем, пәки», – ди дә, кала. Крант төзәлми… Инде әйтә: «Әфәндем, икенче коридорга барып юынсаңыз булмасмы?» – ди. Йа Рабби, әйтерсең, аның кранты минем өчен генә кирәк. Номерларда әллә никадәр кеше бар. Аларның рәхәтләрен дә күзәтергә кирәк иде бит. Фәкать алар кранттан су килсә – юыналар, килмәсә – юынмыйлар яки башка коридорга барып юыналар.

Бер дә эчләре пошмый. Язу язарга өстәл сорадым: «Юк, әфәндем, нә япалым», – ди. «Алдыртып куй», – дидем. Ниһаять: «Простой бер өстәл алдырт, акчасын үзем бирермен», – дидем. Булмады. Язуны берничә көннәр мәдрәсәдәге шикелле тез өстенә куеп язарга тугры килде. Ахырында грек хезмәтче малае үзлегеннән бер такта өстәл табып китереп юып бирде. Өстенә аннан-моннан кягыдлар *(кәгазьләр)* каплап, мине сөендереп, үзенә күп кенә чәйлек алып китте.

Бунлар бик вак, әһәмиятсез нәрсәләр. Ләкин Мостафа әфәнделәрнең әхвәле рухияләрен, хәяттә истигъдад *(булдыклылык)* дәрәҗәләрен күрсәтә торган галәмәтләрдер. Отельнең хезмәтчеләре барысы да греклар. Мостафа әфәнде монда үзен мөсафир вә мөвәкъкать *(вакытлы)* кеше кебек кенә хис итә. Хезмәтче грекларның рухларында хуҗалык хисе бар. Менә төрекләр өчен тәәссефле *(кызганыч)* хәл шулдыр.

«Тәфиз», «Шәфәкъ», «Заман», «Гайрәт» кеби ялтыравыклы исемле китапханәләрнең хуҗаларыннан күбесе вә төрек мәктәпләренә дәрес китаплары җитештереп бирүчеләр – әрмәни вә яһүдиләрдер.

«Рәснә» фотографханәсе бик гүзәл куелган. Иясе Бәһаэддин бәк Рәхмизадә ачык фикерле сәүдәгәр вә нәзек табигатьле адәмдер. Кем улдыгыны сораштым. Гридле бер мөселман булып чыкты. Монда килүенә ике-өч кенә ел икән: «Эш бик яхшы бара, ләкин фотографиядә хезмәт итәргә мөселманнан адәм табып булмый, менә шуңа аптырадым. Христианнар бер дә күңелдән эшләмиләр, аз гына тамаклары туйды исә, чыгып китәләр. Әгәр мөселманнан яхшы хезмәт итүче булса, жалованиедән тормас идем, чөнки оправдать итә, хәтта файда уртагыннан алыр идем, әгәр табылмаса, ахырында фотографиямне ябарга мәҗбүр булачакмын, Сезнең мәмләкәттән хезмәткә килүче татар егетләре булмасмы икән?» – ди. *(Әлбәттә, фотография эшен белгән кеше кирәктер.)*

Бу да кечкенә нәрсә, ләкин бу да бер әхвәле рухияне күрсәтә. Шуның өчен моны да дикъкать алмаенча булмый. Урамда автомобильләр йөри. Шунлар арасында ук моннан 15 ел элек мин күргәндәге шикелле, ике ягына корзинка асылган, вә шул корзинкаларга туфрак, ком, таш тутырган ишәкләр дә көтү-көтү булып баралар. Көянтәгә эчәкләр, бавырлар, үпкәләр аскан «сәүдәгәрләр» дә шул ук Бабы Гали җаддәсендә кычкыра-кычкыра үзләренең «тауарларын» сатып йөриләр. Анларның пычраклары тама, өсткә тия, ләкин берәүнең дә буңа эче пошмый, ул килгәндә читтәнрәк үтеп китәргә карыйлар. Куй түшен көянтә берлән күтәреп урамнарда кискәләп сатып йөриләр. Бу да бер дә гаҗәп тоелмый.

Урамнар тар, төзетергә булып ташларын сүтеп ташлаганнар. Туфрак өелгән, чокыр казылган, көннәрчә шулай тора, йөрергә ифрат дәрәҗәдә уңайсыз, ләкин буңа да берәүнең дә исе китми, бары икенче яктан үтеп йөри башлыйлар. Әгәр икенче ягы да шулай ителеп куелса, бүтән урамнан йөри башлыйлар. Тәмамыйлә минем отельдагы крант мәсьәләсе! Бу да бер әхвәле рухиядер. Ләкин яхшы галәмәт түгелдер.

*Текстны басмага КФУдагы Халыкара мөнәсәбәтләр институтының 3 нче курс студенты **Азат Якупов** әзерләде.* ■

Сәнәкчеләр сугышы

Айдар Хәмзин

1921 елда Кушай авылында сәнәкчеләр тарафыннан үтерелгән 4 коммунистка 1960 нчы елларда куелган һәйкәл. Сулдан уңга: билгесез кеше, Мулланур Мөлеков, Наил Хәмзин

Татарстанда Гражданнар сугышының соңгы чаткысы – Сәнәкчеләр баш күтәрүе (Сәнәкчеләр фетнәсе). Ул Минзәлә өязенең Ташлык авылыннан 56 чакрым ераклыкта урнашкан Яңа Елань дигән урыс авылында (хәзер авыл Әлмәт районының Ерсубайкино авыл җирлегенә керә) башлана. «Сәнәкчеләр сугышы»ның исеме баш күтәрүчеләрнең төп коралы сәнәк, көрәк, чалгы, чабагач һәм балта булуга бәйле.

«Салкын амбарга ябарга!»

1920 елның 4 февралендә Яңа Елань авылына Пудов җитәкчелегендәге утыз биш солдатлы продотряд килә. Көн бик салкын булуга карамастан, Пудов халыкка җыелырга фәрман бирә. Җыенда ул крестьяннардан 5535 пот икмәк тапшыруны таләп итә. Ачлы-туклы яшәгән крестьяннар: «Икмәк симәнәлек кенә калды», – диләр. Бу хәбәр Пудовның ачуын чыгара, ул унсигез кешене (алар арасында ике хатын-кыз да була) салкын амбарга ябарга, кирәк кадәр икмәкне җыйганчы шунда тотарга боера. Кызылармиячеләр, өйдән-өйгә йөреп, крестьяннарның икмәкләрен тартып алалар да идарә каршына аударалар. Кар өстенә арышы да, бодае да, арпасы да бушатыла. Продотрядчыларның мондый гамәле крестьяннарны кузгата. 7 февральдә балта һәм сәнәк белән коралланган халык амбар янына җыела, дүрт сакчыны үтереп, авылдашларын ирекккә чыгара, ун кызылармиячене, чишендереп, амбарга яба. Пудов үзенең берничә сакчысы белән Чистайга чыгып кача. Алга китеп булса да, шунысын әйтергә кирәк: большевиклар соңыннан Пудов кылган гамәлләренең провокацион характерда булуын таныйлар һәм аны ун елга төрмәгә утырталар. Яңа Еланьдагы вакыйгалар турында ишеткәч, Бута һәм Кузайкино авылы крестьяннары да баш күтәрә. 9 февральдә фетнәне туктатыр өчен отряд җибәрелә. Баш күтәрүчеләр Минзәлә өязенең гадәттән тыш хәлләр начальнигы Головинны, Зәй милиция җитәкчесе Корниловны һәм берничә кызылармиячене үтерәләр. Фетнәгә Колчак армиясенең урманнарда качып яткан офицерлары һәм солдатлары да килеп кушыла. Шуларның берсе – Алексей Милованов 10 февральдән котырынган халык белән идарә итә башлый. Тиздән баш күтәрүчеләрнең саны өч меңнән арта. Алар Зәй каласын алалар, качып өлгермәгән комиссарларны, солдатларны үтерәләр. Фетнә тиз арада Бөгелмәнең – 22, Чистайның – 12, Минзәләнең – 25, Чаллының 18 вулысына тарала, башкорт җирләренә – Бәләбәй, Уфа һәм Бирск өязләренә күчә. Баш күтәрүчеләрнең саны 60 меңгә җитә (кайбер чыганакларда 30 мең чамасы).

Ташлык һәм Кушай бәрелешләре

Тоба, Каенлы ягыннан агылган ачулы халык төркеме февраль урталарында Ташлык авылы аша үтә. Бер атка икешәр-өчәр кеше атланып, атлы чаналарга унар-унбишәр кеше төялеп хәрәкәт итәләр. Араларында җәяүлеләре дә чутсыз. Кулларына балта, сәнәк, чабагач, чалгы һәм агач күсәкләр тоткан фетнәчеләр төркеменең бер очы Ташлыкта булса, икенчесе Каенлы авылына кадәр сузыла. Авылга килеп керү белән, коммунистларны, активистларны эзәрлекли башлыйлар. Ярлылар комитеты (комбед) җитәкчесе Сабирҗан Нуруллин, комбед әгъзасы Сөләйман Урманаев качып өлгерәләр. Активист Зиннур Хәмзин үзенең Сарсаз авылы янында булган бер дисәтинә җирендә яшеренә. Сәнәкчеләр Шәңгәлче авылына юнәләләр, үзләре белән ташлыклыларны да, шул исәптән Утын пристанендә каравылда торучы Гатиятулла Гайнуллинны да үзләренә кушылырга мәҗбүр итәләр. (Ул чордагы вакыйгалар хакында Мотыйгулла Гатиятулла улы сөйләде.) Шәңгәлчедә дә коммунистларны таба алмыйлар. Фетнәчеләр «Кушай авылында коммунистлар бар» дигән хәбәрне ишетеп, шунда юнәләләр. Шәңгәлче ир-атларын үзләре белән барырга мәҗбүр итәләр. Сәнәкчеләр менә шулай авыл саен үзләренең сафларын тулыландыра баралар, кемнедер кур-



«Сәнәкчеләр сугышы»н яхшы хәтерләүче Мотыйгулла Гатиев

Активист Зиннур Хәмзин

кытып алып китәләр, кемдер аларга үзе теләп кушыла. Авылга сәнәкчеләрнең икенче төркеме Әтәс ягыннан килеп керә. Кушайда дүрт комсомолец сәнәк белән чәнчеп үтерелә. Өчесенең фамилияләрен ачыклап булды: Григорьев, Макаров, Рыбаков. Григорьев лапас түбәсенә менеп яшеренә, кемдер аның анда качып ятуын хәбәр итә. Григорьев качарга мәҗбүр була, әмма аны куып җитеп, сәнәк белән чәнчеп үтерәләр. Совет яклыларның берсен хәзерге Пелагея Егоровна Большакова йорты тирәсендә чәнчиләр, башына балта белән сугалар. Аның каны, миләре капка-коймаларга чәчри. Соңыннан хатын-кызлар, елый-елый, капка-коймадагы канны юалар. Активист Иван Кузмич Макаровны (1904) Шаңгәлченең таза, батыр Сәлахетдин Әхмәтов саклап кала. Ул Кушайга тарантаслы аты белән бара. Танышы Иванны очратып, аны тарантасның алгы өлешенә яшерә, үзе кулына – мылтык, икенче кулына кылычын тоткан килеш, фетнәчеләрне каршылый. Гражданнар сугышында Чапаев дивизиясендә хезмәт иткән Сәлахетдинне сәнәкчеләр үз тарафдары дип уйлыйлар. Кайбер башкүтәрүчеләр, сәнәк белән кадап үтерелгәннәрнең киемнәрен, итекләрен салдырып алып, үзләре кияләр. Кушайда канлы эшләрен тәмамлаганнан соң, сәнәкчеләр Афанас авылына юнәләләр. Анда алар Кызыл Армиянең регуляр частьләре белән бәрелешә. Фетнәне бастыру өчен, Совет хөкүмәте 6372 штыклы, 816 кылычлы, 79 пулеметлы, 2 бомбометлы һәм 6 пушкалы Запас армияне һәм Төрекмәнстан гаскәрләрен җибәрә. Көчле һөҗүмнәрдән соң, башкүтәрүчеләр качып-таралып бетәләр. Өч меңләп крестьян үтерелә, фетнәдә катнашучы меңләгән кеше кулга алына. 800ләп кызылармияче, совет активисты һәлак була, җитәкчеләрен 1929 елга кадәр эзәрлеклиләр. Сәнәкчеләр сугышы март урталарында бастырыла.

Кушай авылында Сәнәкчеләр сугышында үтерелгән комсомолецлар истәлегенә соңрак һәйкәл куела. Бу эштә Шаңгәлче Авыл Советы рәисе Наил Хәмзин (1924) башлап йөри. Һәйкәл ачу тантанасы зурлап үткәрелә.

Сөнгатулла Төхфәтов

Дүрт яшьлек Сөнгатулла хәйләсе

Сәнәкчеләр сугышы хатирәләренә кагылышлы тагын бер истәлек. Аны Рафаил Габизов сөйләде. Әнисе Мөкаттәрә Төхфәтулла кызы Түбән Олыҗы авылыныкы. Түбән Олыҗы авылына сәнәкчеләр бәреп керә. Берсе Төхфәтулла картның тәрәзәсен шакып, коммунистлар турында белешә. Өйдә тиф белән авырып ятучы карчык барлыгын ишетеп, ул тизрәк китү ягын карый. Алга китеп булса да шунысын әйтик: ул әби авырудан савыга алмыйча вафат була. Бераздан берничә фетнәче килеп, Төхфәтулла картка үзләрен ат белән күрше авылга илтеп куярга боералар. Анымоны уйламаган карт җигелгән атына дүрт яшьлек улы Сөнгатулланы (1915 елның 21 ноябрендә туган) утыртып җибәрә. Дүрт яшьлек Сөнгатулланың маҗаралары бик күп сораулар тудырса да, вакыйганы ул елларның бер ядкяре итеп бәян итәсем килә. Күрше авылдан соң икенче авылга, аннан өченчесенә, дүртенчесенә, шулай итеп кечкенә Сөнгатулланы Ык буе авылларына кадәр алып китәләр. Үзе яшь булса да, малайның башы эшли: зур кибән янына ял итәргә туктагач, сәнәкчеләрнең бер авылга бәреп кереп сугыша башлауларыннан файдаланып, ат арбасының ике алгы тәгәрмәчен салдырып (ничек салдыргандыр?!) печән астына яшерә һәм тугарылган аты белән урманга кереп кача. Бераздан фетнәчеләр килеп малайны, атны эзлиләр, арбаның тәгәрмәчләре юклыгын күреп, ашыгып китеп баралар. Сөнгатулла, тәгәрмәчләрне урынына урнаштыра да, атын җигеп, арбасына печән салып, кайтыр юлга чыга. Юлны белмәгән малай атына ышана, ә ат әкрен генә элек килгән юлы буйлап кайта. Бер авыл аша үткәндә, малай җирдә аунап яткан бик матур ефәк шарф таба. (Ул шарф, сәнәкчеләр чорының кадерле ядкяре булып, бик күп еллар саклана, соңыннан Сөнгатулла шарфны туганы Рафаилгә бүләк итеп бирә. Бер җылысы да булмаган бу ефәк шарф үзенең матурлыгы белән кешеләрне җәлеп итә.) Атна-ун көннән соң Сөнгатулла аты белән туган йортына кайтып җитә, малаен күрүдән өметен өзгән Төхфәтулла карт шатлыгыннан елап җибәрә.

Берничә ел үткәч, ат торган сарайны яшен суга, имән багана урталай ярыла, ат үлә. Сөнгатулла Төхфәтов Бөек Ватан сугышында катнаша, 100 яшен тутырып, Түбән Кама каласында вафат була. ■

КОТОЧКЫЧ АЧЛЫК

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКТАН ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

Ачның ачуы яман

Айдар Хәмзин



Ачлык елындагы плакат

Ачлыкның сәбәпләре

1921 елгы ачлыкның сәбәпләре күп була. Әүвәлгесе – 1914 елда башланган Беренче бөтендөнья сугышы, аннан 1917 елдагы ике революция, 1918 елда илдә кабынып киткән Гражданнар (Ватандашлар) сугышы һәм хөкүмәтнең халыктан икмәк җыя башлау сәясәте – продразверстка. Монысы исә авыл халкының хәлен тагын да аянычлырак итә, келәтләрдәге барлык ашлыкны, шул

исәптән орлыкка калдырылганы да кырып-себереп тартып алына. Басу-кырларны эшкәртү өчен ир-ат көче җитми, чәчәр өчен орлык булмый, нәтиҗәдә, күп җирләр буш кала. Сугыш тәмамланганнан соң, тормышлар яхшырыр, дигән өмет акланмый. 1920 ел белән 1921 ел арасындагы салкын кышка халык икмәксез керә. Яңа төзелгән Татарстан Совет Социалистик Автономияле Республикасына 10 миллион 120 мең пот ашлык тапшыру бурычы куела. Икмәк җыю ТАССР Хөкүмәтенең җитәкчесе Сәхибгәрәй Сәетгалиевкә йөкләнә. Аңа ярдәмгә латыш укчыларын, украин отрядларын җибәрәләр. 1920 елның 1 декабренә продразверстка планы 102 процентка үтәлә. Ашлыктан тыш, декабрь ахырларына, крестьяннардан талап, тагын 380 000 поттан артык ит, 1 652 000 пот бәрәңге, 17 000 000 данә йомырка, 11 000 пот май, 8880 пот бал, 227 344 данә тире, 13 276 пот йон, 4838 пот җитен, 4639 пот киндер сүсе тапшырыла. Шулай итеп, крестьяннар киемсез дә кала, чөнки ул өс киемнәрен мал тиресеннән, йоннан, киндер һәм җитеннән тегә.

Җитмәсә, халыктан, «чәчүлек орлыгын җыеп, җәмәгать амбарларына салабыз», дигән мәкерле сылтау белән, тагын 2 500 000 пот икмәк тартып алына. 1921 елга халык чәчүлек орлыксыз килеп керә. Кыш бик салкын килә. Ашарга эзләп чыгучыларның күбесе юлда катып үлә. Салкын кыштан соң, коточкыч корылык башлана, май һәм июнь айларында тамчы да яңгыр яумый, җирләр яргалана, елгалар, чишмә-инешләр кибә. Ашарга яраклы үләннәр корып бетә. Йорт хайваннарының саны бик нык кими. Кешеләр эт-мәчеләрне ашарга мәҗбүр булалар. Идел һәм Чулман буйларында чын мәгънәсендә ачлык-ялангачлык котырына.

«На наших руках умирают дети»

Кантоннарда ачтан үлүчеләр хакында җан әрнеткеч хәбәрләр тарала. 1921 елның җәендә урыннардан алынган мәгълүматларга караганда, республикада соң дәрәҗәдә ачыгучылар итеп барысы – 2 462 599 кеше, үлүчеләр саны якынча 400 000 кеше дип исәпләнә. Чаллы кантонында 1921 елның февраль аенда гына да 10 155 кеше ачлыктан, 1344 кеше тифтан үлә. 44 507 кеше төрле авырулардан интегә. Крестьян хуҗалыкларының 67 проценты таркала. Бу әле төгәл саннар түгел, чөнки Татарстанны бу чорда 232 000нән артык кеше ташлап китә. 15 000нән артык бала икмәкле өлкәләргә озатыла. Бик күпләре юлларда кырыла, ә аларны беркем дә исәпкә алмый. Тифтан үлүчеләрнең саны 1920 елда ук 218 000нән артып китә.

«В телеграмме в Москву участники 1-го съезда советов Челнинского кантона сообщили: «Мы голодаем. На наших руках умирают дети, старики, молодежь. Но мы надеемся, что брат-крестьянин урожайных мест и рабочие городов в помощи нам не откажут, и советская власть эту помощь организует. Мы Европе заявляем, что холодные, голодные, но завоеванное Октябрем никогда и никому не отдадим!». В газете «Правда» за 24 июля 1923 года в корреспонденции «Челнинский кантон Татреспублики» приводится рассказ крестьянина: «Голод многому научил: крестьяне не знали огородничества, а теперь в каждой деревне огород и бахчи». Государство выделило крестьянам Поволжья семена на озимый и яровой сев, а также продовольствие – 27,5 тысячи пудов кукурузы. Было открыто 532 бесплатных столовых, из них несколько – непосредственно в Челнах. Новый 1922 год оказался урожайным, и это помогло жителям справиться с тяжелейшей ситуацией». [Ляля Гайфетдинова, chelny-izvest.ru, 11.09.2015.]

1921-1922 нче елларда РСФСРның Милләтләр эше буенча Халык комиссариатында ТАССРның вәкаләтле вәкиле Али Ганиевнең Үзәккә җибәргән хәбәренә караганда, халыкның 70 проценты ачлыктан үлү дәрәҗәсенә җитә.

Бу вакытта крестьяннарны тәмам бөлгенлеккә төшергән бәлаләрнең тагын берсе – янгыннар. Корылыктан гынамы бу, әллә башка сәбәпләре дә булганмы – әйтүе кыен. Янгыннар коточкыч дәрәҗәгә җитә. Бу афәт барлык кантоннарда да күзәтелә. Кайбер авыллар тулысынча янып юкка чыга.

Ташлык фаҗигасе: «Терeләй күмәргә!»

1921 елгы ачлыкта Ташлык авылында бик күп кеше үлә, гаиләләре белән кырылалар. Язын, Ташлык-Шәңгәлче юлында кар астыннан әллә ничә туңып үлгән кеше табыла. Бу турыда Мәһифәрвәз Ризатдин кызы еш искә алган. Вакыты шундый булган, ахры, метрикә кенәгәсендә 15 апрельдә туган бер Нурдидә генә күрсәтелә. Атасы – Хисаметдин Бәһаутдин улы. Анасы – Мәгърифә. Вафат булганнар турында бөтенләй мәгълүмат бирелмәгән.

Ачлык елларын башыннан кичергән Зәйтүнә Исламова

Тирә-юньдә юа, кукы, сәрдә, кычыткан, алабута, агач кайрысы һәм бөресе калмый. Авыл халкы соңгы мал-туарын суеп ашый, этләр, мәчеләр, тычканнар, бакалар белән туклана. Зәй елгасы буе бака кабырчыклары (учакта тоткач ачыла икән) белән тула, сыер бозаулаган чакта салган чүбенә кадәр ашыйлар. Исламова Зәйтүнә (1910) белән әнисе Мәгъсүмә (1878), туганнары Мәһитапның сыеры бозаулагач, чүбен пешереп ашауларын еш искә төшерә иде. Ачның ачуы яман, дигәндәй: Ташлыктагы зур фаҗига – сигез кешене төрле караклыкта гаепләп терeләй күмү – моның ачык мисалы. Авылның ул вакыттагы старостасы һәм берничә авыл куштаны (исемнәрен язмыйм, ул вакыттагы вакыйгалар бүгенге көндә яшәүче туганнарына зыян салмасын) әлеге сигез кешене судсыз-нисез генә үлемгә хөкем итә. Ач халык коткыга тиз бирелә. Гаепләнүчеләрне Аръяк урамындагы идәне су белән тулган таш амбарга ябалар. Ярсыган халык төркеме, әлеге кешеләрне, кулларын артка каерып бәйләп, муеннарына «карак» дип язылган такта асып, урам буйлап йөрткән, аларны бик нык кыйнаганнар, йөзләренә төкергәннәр... Ул вакыттагы мәхшәрне язып кына аңлатып булмый.

Авыл халкыннан зират читенә зур чокыр казыталар һәм шунда гаепле сигез кешене төртеп төшерәләр. Чы-

> «Зәй елгасы буе бака кабырчыклары (учакта тоткач ачыла икән) белән тула, сыер бозаулаган чакта салган чүбенә кадәр ашыйлар.

гарга теләгәннәрнең, алъяпкыч белән йөзләрен каплаганнарның башларына көрәк белән сугалар. Гаепләнүчеләрнең берсе яшь бала белән була. Ул сабыеның башын күкрәгенә кысып, алъяпкыч белән яба. Авыл куштаннары һәр авыл кешесен ике-өч көрәк балчык атарга мәҗбүр итә. Бу фаҗига турында мәгълүмат җитмәве, авылдашларның әлеге вакыйгага катнашы булудан килә, ахры. Кем инде анда булганын сөйләп йөрсен. Бары тик берничә кеше генә, мондый мәшхәрдә үзләренең катнашмавын ачык рәвештә белдерә. Шундыйларның берсе, көч-гайрәте белән дан тоткан Сәлимгәрәй улы Мөхәммәтҗан (1884): «Мондый эшкә кулым бармый!» – дип кистереп әйтә.

Зыятдин фаҗигасе: югалган сыер кайта, әмма гафу үтенүче булмый

Хезмәт сөючәнлеге белән дан тоткан Хисаметдин улы Зыятдин 1921 елны басудагы җиренә һәм бакчасына күп итеп бәрәңге утырта. Җәй бик коры килгәнлектән, бөтен гаиләсе белән бәрәңгегә су сибә. Алар суны урамдагы коедан һәм инештән ташыйлар. Арбасына куелган агач кисмәк белән су ташучы Зыятдиннан, көянтә-чиләк белән көн саен су алып кайтучы җәмәгате Таифәдән, кызларыннан авыл ир-атлары болай дип көлгәннәр, имеш: «Зыятдин Аллаһы Тәгаләдән узып йөри, аны алдарга тели, әллә кайдан уңыш алыр инде, әгәр дә алай гына уңыш алып булса, бөтен кеше дә су сибеп кенә үстерер иде». Ә Зыятдин, чагыштырмача мул уңыш алып, гаиләсенең тамагын туйдыра, башкаларга да өлеш чыгара. Ашарына булмаган авыл кешеләре, Зыятдиннан соңгы сөлгеләрен, ашъяулыкларын бәрәңгегә алыштыралар. Аның тук тормышы күпләрнең ачуын китерә. Кайберәүләр үч алырга җай эзләп йөри. Берәүләрнең сыеры көтүдән өенә кайтмый. Сыер хуҗасы, сыерымны Зыятдин суйган, дип, тавыш чыгара. Зыятдинның энесе Ризатдин, бу турыда ишетеп алып, абыйсына авылдан чыгып качарга тәкъдим итә. Зыятдин шулай эшли дә. Ярсыган халык төркеме, терелəй күмәргә хөкем ителгәннәрне авыл буйлап йөртә торгач, чатка (чат – авылның үзәге, урамнар кисешкән урын) килеп җитә. Тавышлары әллә кайларга ишетелә. Берничә кеше, Зыятдинны да алып чыгарга кирәк, дип, аның йортына юнәлә. Шунда кайсыдыр аның авылдан чыгып качканлыгын хәбәр итә. Куштаннарның берсе: «Хатынын терелəй күмәргә кирәк!» – ди. Тын алырга да куркып торган кызлар, тиз генә әниләрен мич эченә яшереп, алдына утын өеп куялар. Фетнәчеләр өйнең астын өскә китерәләр, тик таба алмыйлар. Шулай да: «Гаеплеләрне күмешерсең», – дип, олы кызы Маһирәне үзләре белән алып чыгып китәләр. Акылдан шашкан кешеләр төркемендә аек фикерлеләр дә була.

Зыятдин фаҗигасенең шаһите Маһирә Хисамова

Күршеләре Маһирәгә: «Кызым, син әкренрәк бар, арткарак кал, качарга тырыш», – дип киңәш бирә. Кыз, җайлап кына бара торгач, кача. Ә югалган сыер икенче көнне үзе кайтып килә. Зыятдин берничә көннән соң өенә кайта. Берәү дә килеп гафу үтенми, хаталануын да танымый.

Башка хатирәләр: «Если хочешь жить, не подходи!»

Хәмзә улы Зиннур, ул вакытларны искә төшереп, болай дип сөйли: *«Сарсаз авылы тирәсендә бер дисәтинә җирем бар иде. Аллаһының рәхмәте белән, шуннан бер полоса яңгыр явып үтте, шул сәбәпле уңыш булды, ашарлык икмәк алдык. Шул икмәк безне үлемнән алып калды»*.

Хәлсезләнгән Миннәхмәт исемле кеше Мөхәммәтхафиз муллага ашарга сорап керә. Аннан аш белән икмәк ашап чыгып киткәннән соң, күпер төбендә үлә.

Әшрәфулла Хәлиуллин белән Әүхәди Шәрәфиев атлары белән Бөгелмәгә орлык артыннан баралар. Ташлыкка кайтып җиткәч, Әшрәфулланың аты зират каршында хәлдән таеп егыла. Атны тәрбияләү озакка сузыла. Ашатырга юк, бары 1922 нче елда уҗымга чыгаргач гына, атына хәл керә.

Фазлыйәхмәт Гыйбадулла улының атын урлыйлар. Эзләр Байгол авылына илтә. Фазлыйәхмәт шунда юнәлә. Угрыларның йортын да таба, аты, хуҗасы килүне сизеп, кешнәп тә җибәрә, тик кулларына сәнәк тоткан кешеләр: «Если хочешь жить, не подходи!» – дип, куып җибәрәләр. Фазлыйәхмәт атсыз кайтып китәргә мәҗбүр була.

Авылның өлкән буын кешеләре Америкадан кайткан ит тушенкалары ашаганнарын хәтерлиләр.

Ачлык-ялангачлык Каенлы авылында да зур фаҗига китереп чыгара. Анда да, хөкемсез-нисез, 5 кешене сарайда бикләп яндыралар. Шаңгәлчедә, бер йомарлам май урлауда гаепләп, берәүнең кызын үзеннән астыралар.

1921 елда Иштирәк авылында алты кешене тере килеш күмәләр, каз урлауда гаепләнгән кызны кыйнап үтерәләр. Бу вәхшилекне карап торсыннар өчен ярты авылны көчләп куып менгезгәннәр. [Вагыйзь Сәйфуллин. Туган авылым Иштирәк.]

Федот Иваны фаҗигасе: сыер хуҗасының капка төбенә кайта, әмма 11 җан кыела

Кушай авылында 11 кешелек Федот Иваны гаиләсен терелэй күмәләр. Нык тормышлы әлеге гаиләдән авылда бик күпләр көнләшә. Кемнәргәдер аларның кешелекле булуы ошамый, гаилә ачлыктан интегүчеләргә ярдәм итә. Җитмәсә, авылда, Федотныкылар караклык белән шөгыльләнүче төркем белән бәйле, дигән сүзләр йөри, янәсе, урланган тауарларны болар бер урыннан икенче урынга күчерәләр, ягъни эзне югалталар. Бәйләнерлек сәбәп тапмагач, авыл куштаннары хәйләгә керешә. Федотныкыларның каршы ягында яшәүченең сыерына дүрт чабата кигертеп, урманга алып барып яшерәләр. Авылда сыерны урладылар дигән хәбәр тараталар, бурлыкта күршеләрен гаеплиләр. Иванның (бәлки, Федотның, төгәл белүче табылмады) таза гәүдәле ике малаен аерым-аерым кыйнап, Түбән очтагы амбарга кертеп аталар. Бераздан алып чыгып, Иванның өенә юнәләләр. Аны-моны уйламаган гаилә яшеренергә өлгерми, чарасызлыктан, кечкенә кызларын олы мич юллыгына кертеп җибәрәләр. Өйгә килеп кергән авыл старостасы һәм аның куштаннары йортның астын-өскә

китерәләр, ит эзлиләр, кечкенә кызны да табып алалар. Ярсыган халык төркеме гаилә башлыгын, аның хатынын, ике малаен, ике киленен, биш баласын урам буйлап алып китә. Юл буе кыйныйлар, типкәлиләр. Кемдер шунда Иванның кызы Дария юклыгын искә төшерә. Дария берничә көн элек кенә Малафеевка кияүгә чыга, шунлыктан кияү йортында кала. Берничә кеше Дария артыннан китә. Хәлнең бик катлаулы булуын аңлаган Малафеевлар ишекне биклиләр һәм, кыз артыннан керүче булса, ут ачачакларын әйтәләр. Тегеләр борылып китәргә мәҗбүр булалар. Зиратта алдан казылган чокырга 11 кешене төртеп төшерәләр. Тырмашып чыгарга теләүчеләрнең башларына көрәк белән сугалар...

Икенче көнне сыер хуҗасының капка төбенә кайта.

Берничә ел үткәннән соң, әлеге фаҗига турында ишетеп, Дария янына милиционерлар килә. Тик ул аларга бернәрсә сөйләми. Еллар үткәч кенә, ул ант иткәнен, беркемгә дә сөйләмәскә вәгъдә биргәнен, шуның нәтиҗәсендә исән калуын әйтә.

Татарстанга ярдәм

Ачлык афәте көннән-көн көчәя барып, масштаблары киңәйгәч, 1921 елның августында Совет хөкүмәте халыкара хәйрия оешмаларына мөрәҗәгать белән чыгарга мәҗбүр була. Илнең дөньякүләм танылган шәхесләре, җәмәгать эшлеклеләре чит илләрнең мәшһүр зыялыларына хатлар язалар. 1921 елның 18 июлендә БҮБК рәисе М.И.Калинин җитәкчелегендә «Ачларга ярдәм оештыру» (Помгол) буенча Үзәк Комиссия (ҮК) төзелә. Мондый комиссияләр тиз арада ачлыктан интеккән барлык төбәкләрдә дә оештырыла. Татарстанда 28 июльдә төзелгән комиссияне Башкарма комитет рәисе Рәүф Сабиров җитәкли. Комиссия үз эшен ачларның төгәл санын исәпләп, нинди һәм ничек ярдәм оештыру турында төгәл мәгълүмат булдырудан башлый. Помгол Үзәк Комиссиясе эшкә тотыну белән, Россиянең хәвеф-хәтәрсез, уңышлырак губерналарына ачлыктан һәм корылыктан аеруча интеккән өлкәләргә ярдәм итүне йөкли. Татарстан Петроград һәм Владимир губерналарына беркетелә. Моннан тыш, Смоленск, Витебск, Кострома, Тверь, Псков, Ярославль, Пенза һ.б. — барысы 11 губерна үзләрендә булган икмәктән Татарстанга өлеш чыгарырга тиеш була. Украина белән Белоруссия дә бу эштә шактый ярдәм күрсәтә. Республикага барысы 3 000 000 пот ашлык килә. Азәрбайҗан, чит илләрдән Финляндия, Германия һәм Швеция дә ярдәм итә. Ниһаять, 1921 елның 3 сентябрендә Казанга Американың «Ачларга ярдәм комиссиясе» (АРА) вәкилләре килә. Болардан тыш, РСФСР Азык хәзерләү халык комиссариаты 60 000 баланы тукландыруны үз өстенә ала. Аның акчалата ярдәменә 13 100 пот икмәк, 5000 пот он, 7450 пот ит, 14 800 пот бәрәңге, 740 пот тоз алалар. Татарстаннан разверстка белән тартып алынган азык-төлек күләме белән чагыштырып карасак, ачлыкка дучар булган 2 462 599 кеше өчен, әлбәттә, бу ярдәм бик тә аз була. Республикага килгән ашлыкның күп өлешен 1922 елның язына кирәкле симәнәлек итеп тә салып куярга туры килә. Татарстанга Россия төбәкләреннән – барлыгы 4 414 000 пот, чит илләрдән 160 000 пот чәчүгә яраклы орлык китерелә. ■

«Шуның кебек хатының булса икән!*»

Мирхәйдәр Фәйзи

Гурзуфның гомуми күренеше

Ялта-Севастополь-Украина. 1926 ел, май.

24ендә. Без Гурзуфка киттек. Бу тирәдәге виноград басуларын санап та, язып та бетерерлек түгел. Гурзуф тирәсендә тәмәке басулары да бик күп. Гурзуфка төшә торган юл бу виноградниклар арасыннан борылып-борылып барып төшә.

Гурзуф – читтән бик матур күренешле татар авылы. Ул бик муафыйк урынга утырган. Шимальдән Яйла тавы, гарептән – Ай-Даниль, шәрыктан – Аю-Даг аны төрле җилләрдән саклый. Шунлыктан һавасы һәрвакыт җылы.

Гурзуф – типичный татар авылы. Йортлар матур, ләкин урамнар тәртипсез. Мәчетен карадык. Кырымда беренче мәчет, ди. Бик матур эшләнгән.

Борынгыдан калган бер крепость хәрабәсен карадык. Бер скалага мендек. Моннан борынгы Чехов йорты һәм Пушкин йорты, Пушкин гроты, Адалар[1] күренәләр. Бу скаланың диңгезгә барып чыга торган бер кызык туннеле бар.

Гурзуфта 12 дисәтинә урын били торган паркта курортлар бар. Парк бик шәп. Анда бөтен нәрсә бар. Төрле фонтаннар күп. Ләкин хәзер берсе дә су атмый, карамаганнар. «Ночь» дигән фонтан бик матур, ул 60 җиреннән су чыгарып торган.

[1] Адалар – Кара диңгездәге ике кечкенә кыя-утрау.

* Көндәлекләрдән кыскартып бирелә. – *Ред.*

Тагы «Беренче мәхәббәт», «Рахиль», «Нимфа» дигән матур фонтаннар бар. Алар да бозык.

Паркта диңгез буенда обедать иттек. Пушкин өен карадык, ягъни Раевскийларда Пушкин кунак булып яткан йорт. Бу 1820 елда булган. Пушкин платаны, Пушкин кипарисы дигән агачлар бар. Боларны карый-карый без байтак җәяү бардык. Җиргә ятып үсә торган алма агачы, груша бакчасы күрдек.

Гурзуфның җир тетрәү вакытында да исән калып, 1930 елда большевиклар тарафыннан җимертелгән мәчете

Гурзуф авылында диңгез буенда уйнап йөрүче татар балалары



Гурзуфтагы татар хатын-кызлары

Безнең 3 нче тукталыш мәшһүр Никитский бакчада булды. Кырым ярыматавының бөтен флорасын җыйган бу кыйммәтле сад 1811 елда төзелә башлаган. Ришелье[2] дигән герцог башлаткан. Монда хәзер Наркомзем хөкеме. Янында Магарач исемле вино склады бар.

[2] Ришелье – русча язылган.

Бакча Кырымда гаҗәеп шәп урыннардан санала. Һәр Ялтага килүче аны күрүне беренче планда тота. Монда Кырымның бөтен агачын, чәчәген күрәсең. Менә төз, тигез, купшы кипарис аллеясы, менә пальма аллеясы, менә башкалар. Монда виноград кына 420 сорт санала. Чәчәкләрдән розаның гына 3000 төрлесе бар. Матурлык, хушлык җирендә. Хәзер әле ул элекке шәплеген җуеп, яңарып җитә алмаган.



Пушкин платаны

Агачның гаҗәепләре бар. Аксыл гына яшькелт яфраклы серебристый кленмы, ботакларын аркылыга җәеп берүзе әллә никадәр урын алган агачлармы, меңьеллык, биш йөз еллык агачлармы, һичбер кабыксыз яп-ялангач көе үсеп утырган агачлармы, кып-кызыл гәүдәлеләрме, чәчәге бер акка, бер кызылга әйләнә торган агачлармы – бөтенесе бар. Лимон, банан, бамбук агачларын карадык. Меңьеллык агач астында хәл җыйдык. Һич язып бетәрлек түгел. Ак, кызыл, ал, сары, саргылт, күк, кызгылт чәчәкле агачлар тулып ята. Гаҗәп матур пальма аллеясы янында рәсем алдырдык. Мин ялгызым, японский роза кочаклап, чәчәкләр, пальмалар арасында рәсем алдырдым.

Моннан кайтышлый «Сәлам» дигән винный складка туктадык. Төрле винолар алдык. Халык күңеллеләнде. Доктор хатыны бөтенләй ямьләнде, бөтенләй көлде. Булгач-булгач, шуның кебек хатының булса икән!

27сендә китү хәзерлеге башланды. Обедтан соң Җәгъфәр килде. Ул миңа кырым татарларының җырларын язып алып килгән. Җырлап карадык. Озак утырды, вино эчтек. Аңа бер рәсемемне бирдем. Соңынтын диңгез буена бардык, скверда йөрдек. Ул мине татар кызлары, татар җегетләре белән таныштырды. Аннан картинага кердек. Монда киноларның җәйге махсус ачык заллары бар. Кинодан соң кафеда мороженый ашадык. Ай яктысы белән диңгез өсте шулкадәр матур иде – прелесть!

28ендә иртә торып бакчага чыктым. Барып үлчәндем. 3 пот 3 ½ кадак, шәп булган. 3 пот 5 ¼ кадакка җиткән идем 15 көн элек. Хәзер 3 кадак. Арту белән Кырымнан китәм. Кайтып җиткәнче ул да бетәр. Белмим, ничек итеп яңадан хәл җыярга юл табармын. Авыруым яхшы булды, анысында сүз юк. Тик артмау күңелле үк түгел.

29ында. Иртүк торып җуындым, киендем, җыендым. Матур бакчага чыгып Кырымдагы актык көнемне дәфтәргә язып утырдым. Хуш Кырым, Ялта! Мин тагы килергә йөрәксенеп китәм. Килергә тырышырмын. Мин синнән туймадым.

Пансионның зур балконында диңгезгә карап тирбәнмәле урында тирбәнеп утырып Кырым хакындагы җырларымны җырладым. Әллә ничә ел торган бер җирдән аерылган кебек тәэсир итә бу китү.

Сәгать 10да автомобиль килде. Мине ямьле, җаныма ягымлы Ялтадан аерырга килгән ул. Бакчадан бер ак роза чәчәге өзеп күкрәгемә кададым да, хушлашып, кипарислар арасыннан үткән биек таш баскычтан төштем. Автомобиль, дулап, алга үрләде.

Хәзер бөтен җир таныш. Пансион калды. Садовая калды. Виноградный калды. Боткинская калды. Фәүҗан күпере, әнә «Сәлам» рестораны, әнә диңгез буендагы сквер, әнә пляж, менә Бохара әмире сарае, менә чокырлар... Бар да берәм-берәм калалар. Без автомобильдә 8 кеше. Бар да курорттан кайтучы авырулар.

Юлда пассажирлы автомобильләр күп. Тау үрле, түбәне дип тә тормыйлар, гакылдан шашып очалар гына. Бу якның сиксән бормалы юлларында аслы-өсле булып автомобильләр тезмәсе күренә.

Ялта калды. Ливадияне, Гаспра, Караиз, Мисхор, Алупкаларны үттек. Ул гел диңгез буеннан бара. Ай-Петри сихерле күренеше белән күзләрне үзенә тарта-тарта җыраклый. Автомобильнең барган юлын уйлап карасаң, коточкыч. Ул биек таулар битеннән, һич уйламаган җирләрдән юл ярып бормалана-сыргалана бара. Уңда – биек таш-тау, сулда түбәндүк – диңгез. Таштауларның өскә аварга торган әллә нинди кот чыгарлык хәлдәгеләре бар. Асларыннан үткәндә ихтыярсыз куркасың. Диңгез, бердән, күп аста. Диңгез өстенә яткан күпереп-күпереп торган ак болытлар да бездән түбән торалар. Диңгез буенда гел агачлык һәм дачалар. Шунлыктан күренеш карап туймаслык матур. Менә шул матурлык дөньясыннан без аерылабыз инде.



Бакчасарайдагы Хан сарае

Байдар исемле авылга туктадык, аш ашадык. Авыл татарныкы. Кырым татарлары арасында актык булышлар.

Автомобиль 90 чакрымлык Севастопольгә 4 сәгать барды. Туры вокзалга алып барып төшерде.

Мин вагонда. Кырымнан алып качачак поездның үземә билгеләнгән 11 номерлы койкасында. Вагон чиста. Иптәшләр бар да Ялтадан килүчеләр. Теге Гурзуф экскурсиясендә бергә булган ямьле кыз малоруска Валентина Ивановна Глебович та бер вагонда. Аның белән якын дуслар кебек күрештек.

Поезд Севастопольдән кич сәгать 9да кузгалды. Бакчасарайга кадәр йокламый карап барырга булдым. Иртә белән торганда без Украинада булачакбыз. Шуңа күрә йоклыйсы, Кырым күренешләреннән, һавасыннан аерыласы килми. Севастопольдән беренче станция Билбәк булды. Ай яктысында тәрәзәдән карап бардым. Бу ике арада бер-бер артлы дүрт тоннель үтелә. Иң озыны 284 сежень. Төн булгач, кызыгын күреп булмады.

Тәрәзәдән бу тирәнең озынлыгы белән шөһрәтле кипарисларын карап бардым. Бакчасарайга җиттек.

Бакчасарай күңелгә байтак тәэсир ясый. Иң беренче «Тәрҗеман» гәзите белән Исмәгыйль Гаспринский күңелгә килә. Бер вакытлар Бөтенрусия татарларына бердәнбер гәзитне таратып, фикерләрен ачып торган бер шәһәр. Икенчедән, татар ханнарының пайтәхете. Монда хан сарайлары бар.

Актык кат татар җегетләрен күреп, сөйләшүләрен ишетеп, вагонга кердем. Поезд кузгалып китү белән: «Хуш, Кырым!» – дип, йокларга яттым. Поезд җуатып тирбәтте, йоклатты.

30ында. Мин торганда Украинада идек инде. Бик ямансу тоелып, җылыйсыларым килде. Кырымны нык сагындым. Аны сагынып җырладым. Җәгъфәр дә исемә төште. Тагы төнлә үтеп, Кырым ярыматавының башланган җирен күрә алмадым. Юлның бөтенләй су эченнән бара торган җирләре бар, ди.

Украинада да яз инде. Агачлар яфрак ярып беткән. Арыш баш кыскан. Җаңгырлар бар һәм без дә җаңгырга очрадык. Майның матур җәе хәзер. Карап бару күңелле. Кругом яшеллек. Бу якның да үзенә күрә матурлыгы бар.

Май көннәре. Юл буйлары агачлык. Алар саф рәвештә яшелләр. Үләннәр ямьяшел. Матур. Шатлыклы. Карап бару зәвыклы. Кырым ягы үзенең бөтен җиргә аерым матурлыгы белән җанны рәхәтләндерсә, безнең бу як күптән күреп иярләшкән, үзләшкән матурлыгы белән күңелле, ямьле. Күзләрне рәхәтләндереп гиздерерлек тигезлекләр. Җыраклардан күренгән авыллар, урманнар, сулар, күлләр, майга махсус матурлыклары белән күңелдән үзен алалар. Поезд юлы буйлап утыртылган агачлар, матур-матур күренешләр күп монда, ягъни Украинада да. Шат, яшь, күңелле кешеләр карап калалар. Май бәйрәм итә.

> **Ютазы дигән станциядә күп татар хатын-кыз, ир-җегет поезд каршылады. Һәммәсе нәкъ казан татарларынча киенгәннәр. Гармун-скрипка парлап татар көен әйттерә. Нәкъ татар бәйрәме. Нәкъ Татарстан.**

Лазовая станциясендә безнең юл азрак борылды. Моңарчы койкамда артыма таба бара идем, инде каршыга бара башладым. Кырымның кай якта калганын да белеп булмый инде.

Харьковта Валентинам төшеп калды. Дусларча хушлаштык. Вокзалда аш ашадым. Бу якта полный җәй. Яшеллек, матурлык. Тәрәзәдән карап арып, туеп булмый. Безнең якта ничектер.

Курски шәһәреннән үттек. Зур шәһәр. Орелдан үткәнче йокламый бардым. Жуликларыннан сакландым, йоклаганда нәрсә алдырулар була.

31ендә. Йокыдан торганда Тула шәһәрен үткән идек. Мәскәү 2 сәгатьлек җирдә тора. Кырым җыракта-җыракта калды. Бу якларда да җәй. Агачлык, яшеллек, яшьлек күзләрне бәйрәм иттерә. Вагон тулы Кырымнан, Ялтадан кайтучыларда бер җуаныч иде. Инде алар белән дә таралышабыз. Поезд бик шәп бара. Сәгатькә 35 чакрым чамаладык, 40 чак-рым диючеләр дә булды. Берәү 48 чакрым дип дәгъва итте.

Мәскәү күренде. Тамаша итеп бардым. Мәскәүгә килү бер көн килгәндәге кебек йөрәгемне селкетмәде.

1 июнь. Сембердә Волганы чыктык, күпер озын. Уйламаганнан Волганы да күрергә туры килде. Бу якка чыккач, татарлар күбәйде. Станцияләрдә дә аларны күп күрәсең. Кырым иде – татарын аңлап булмыйдыр иде; Мәскәү тирәсе иде – гел урыс иде; ә монда – нәкъ безнеңчә сөйләгән татарлар инде.

Мәләкәсне үттек. Аның тирәсе урманлык. Матур. Бөгелмәне үттек. Ул Татарстанда. Бу тирәләрдә әле эреп бетмәгән карлар бар. Халык чәчү эшеннән бушап бетмәгән.

Бу тирәләрдә гел мәчетле татар авыллары, гел татарлар. Ютазы дигән станциядә күп татар хатын-кыз, ир-җегет поезд каршылады. Һәммәсе нәкъ казан татарларынча киенгәннәр. Гармун-скрипка парлап татар көен әйттерә. Нәкъ татар бәйрәме. Нәкъ Татарстан.

Кандыра станциясендә дә күп татарлар каршылады. Ләкин монда бар да сата. Аларның тортлар пешереп чыгарулары урысларны аптыратты. Мин монда татар җегетләре белән күп сөйләшеп тордым. Алар кием-салым да искене ташлаганнар. Авылларында 7 комсомол бар, ди. Шуның 4есе – җегет, 3есе кыз икән. Шулар ук театрлар да куеп алалар икән. Һәммәсенең комсомолланырга дәрте зур. «Картлар эзе белән барып булмый инде», – диләр. «Тик яхшы руководитель юк. Шунысы читен, шунысы гына безне аптырата», – дип зарланалар. Болар, яхшы юлбашчысы булганда, бөтен авыл яшьләренең агылып керергә хәзерлекләрен сөйлиләр. Намазга бармыйбыз, дин тотмыйбыз, диләр. Үзләре гәзит укыйлар икән. Мин аларга байтак нәрсә сөйләдем. Курыкмый, тартынмый яратып тыңладылар.

Бүздәк авылын карап үттем. Поездда әллә нинди марҗалар белән дуслашып беттем. Уфага нәкъ 3 сутка дигәндә җиттек.

8 июньдә. Уфада 5 көн яттым. Уфадан, Златоуст тимер юлы белән Златоуст шәһәре һәм Урал таулары аша Миасска килдем; Миасстан трест атлары белән 350 чакрым җир кайттым. Баймакка июнь 16сында кайтып җиттем. Сәяхәтем нәкъ 2 ай да 10 көнлек булды. 700 сумлап акча бетердем.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Игелекле Хәлфиннәр

Марс Гаитов

Атаклы Хәлфиннәр нәселендә 375 ир-ат һәм хатын-кыз булып, алар арасында зыялы мәгърифәтчеләр, эре сәүдәгәрләр, ил тарихында якты эз, мәдәни һәм матди мирас калдырган шәхесләр шактый.

Мәгърифәтче Хәлфиннәр

Әлеге нәселнең башында **Айтуган улы Хәсән** исемле бик тә булдыклы кеше тора. Заманында ул Казан шәһәренең бургомистры (мэры) булган. Аның дүрт улы арасында иң танылганы – **Сәгыйть Хәлфин** (1732-1785). Сез аны күренекле мәгърифәтче, мөгаллим буларак яхшы беләсез дип уйлыйм. Ул – урыс балалары өчен беренче татар әлифбасы, грамматика һәм ике томлы сүзлек авторы. Сәгыйть гимназиядә татар теле укыта, Казан адмиралтействосында тылмач вазыйфасын башкара.

Сәгыйтьнең улларыннан берсе – **Исхак Хәлфин**не «Әби патша» – Екатерина II Казан губернасы буенча сәркатибе итеп билгели, указларын татар теленә тәрҗемә иткән өчен, аңа мең сум акча бирә. Ул чакта татар теле көнчыгыш дәүләтләре белән аралашу теле булган. Соңрак Исхак Хәлфин Казан гимназиясендә татар теле укыта. Аның уллары Ибраһим, Габдрахман һәм Садыйк та белемле, булдыклы, хезмәт сөючән булып үсәләр. Милләт тарихында иң танылганы – галим, татарлардан беренче профессор **Ибраһим Хәлфин** (1778-1829) була. Ул Казан университетында татар һәм көнчыгыш телләрен укыта, сигез телдә, шул исәптән Европа телләрендә дә иркен сөйләшә. Татар теле дәреслекләре, төрле кулланмалар язып нәшер итә, «Дастане Чыңгыз вә Аксак Тимер» исемле затлы китапның авторы була. Хакимият кушуы белән төрле кануннарны, указларны татарчага тәрҗемә итә, университет

Теләнче Тамак авылы күренеше

типографиясенә нигез сала. Ибраһимның улы **Шаһингәрәй Хәлфин** типографиядә хәреф җыючы булып эшли, гимназиядә татар теле укыта һәм оста тәрҗемәче булып таныла. Әмма аны Россия армиясенә алалар, ул анда офицер булып хезмәт итә.

Теләнче Тамак авылында туган **Нәҗип Латыйп улы Хәлфин** (1886-1937) 1916 елда Казан университетының хокук бүлеген тәмамлый, Баку шәһәрендәге педагогия институтында география фәнен укыта, декан вазыйфасын башкара. Ул – Сталин репрессиясе корбаны, нәселнең башка әгъзалары кебек, бер гаепсезгә башта төрмәгә ябыла, аннары атып үтерелә.

Эшне нидән башларга? Бай кызларын алырга!

Хәлфиннәр нәселенең ишле бер тармагы Уфа һәм Казан губерналарында, гомумән, Россиядә күренекле сәүдәгәр, эшмәкәр, юмарт хәйриячеләр буларак дан казана. Эшмәкәр-сәүдәгәр Хәлфиннәр династиясе башында хуҗалык эшен оста оештыручы, булдыклы **Садыйк Исхак улы Хәлфин** тора. Бертуганы **Габдрахман Хәлфин** белән алар Минзәлә ярминкәсен күреп сокланалар, уңай тәэсир алып, үз сәүдәләрен булдырырга уйлыйлар. Чыннан да, Минзәлә ярминкәсенең даны еракларга тарала. Илнең төрле төбәкләреннән, хәтта чит илләрдән килгән сәүдәгәрләр биредә күптөрле тауарлар белән сәүдә иткән. Ярминкә бигрәк тә ат сәүдәсе белән дан тоткан, анда елына 1400ләп ат сатылган. Шәһәр уртасындагы шактый зур «Ат мәйданы»нда нәселле атларны йөртеп, сайлап алганнар. Ул мәйдан XX гасыр ахырына кадәр буш торды, хәзер анда торак йортлар төзелде. Садыйк һәм Габдрахман шушы төбәккә – Минзәлә өязенең Теләнче Тамак авылына килеп урнашалар, җир сатып алалар. Биредә яшәүчеләр башкорт, дәүләт крестьяннары, типтәр катламына кергәннәр. Хәлфиннәр дә, типтәр булып язылып, эшне игенчелектән башлыйлар, арендага күп җир алалар. Языково авылында аларның 360 дисәтинә сөрүлек җирләре була. Садыйкның алты улы – Зариф, Әхмәт, Салих, Сабир, Гариф, Шакир һәм тагын алты кыз баласы дөньяга килә. Габдрахманның Латыйп һәм Садыйк исемле уллары була.

Хәлфиннәр хыялындагы сәүдә эшен башлау өчен, билгеле, күп акча таләп ителә. Әлбәттә, тора-бара аның да җае чыга. Садыйкның ике улы өязнең Биклән авылы бае, сәүдәгәр Хәмәтшаның мул бирнәле (33әр мең сум) кызларына өйләнеп, кинәт баеп китәләр. Садыйкның кызлары да бай гаиләдән булган егетләргә кияүгә чыга. Аңа башлангыч капитал туплауга кодаларның да ярдәме тия.

Мая малны тиз таба: татар авылында сәүдә ширкәте

Тату гаилә төбәктә ашлык сәүдәсен җайга сала. Алар игенчеләрдән сатып алынган икмәкне киптерү, чистарту һәм амбарларда саклауны оештыралар; күпләп еракка, илнең башка өлкәләренә илтеп саталар; тегермәннәр, ярма җитештерү өчен махсус яргычлар төзиләр.

Хәлфиннәр ашлыкны крестьяннардан совет власте кебек талап бушка алмый, тиешле базар бәясен куеп, шунда ук исәп-хисап ясап, сатып алалар. Шуңа күрә сәүдә уңышлы бара, чөнки ике якка да – сатучыга да, алучыга да табыш килә. Сәүдә киңәйгәннән-киңәя. Хәлфиннәр гадел сәүдә итәләр, җитезлек белән файда да алалар.

Садыйкның өлкән улы **Зариф Хәлфин** 1902 елда «Борадәран Хәлфиннәр» ширкәтен оештыра. «Борадәран» – фарсы теленнән «ир туганнар» дигән сүз.

Хәлфиннәр яшәгән йортларның берсе

Ширкәтнең үзәк идарә офисы һәм торак йорты Чаллы авылында урнаша, ул әле дә исән. 17 нче йөз уртасында нигез салынган бу авылга 1930 елда шәһәр статусы бирелә. Хәлфиннәрнең биредәге сәүдә үзәгендә пар көче белән эшли торган 7 ташлы зур тегермәне, берничә ашлык киптергече, 5 ашлык амбары була. Алар Чаллыда сентябрь, декабрь һәм май айларында гөрләп уза торган Никольская ярминкәләрендә аеруча актив сәүдә иткән.

Хәлфиннәрнең 1902 елда Минзәлә шәһәрендә дә сәүдә йорты булдырыла. Алар ашлык, чимал, чәй, шикәр, мануфактура һ.б. бик кирәкле тауарлар белән Минзәлә һәм Бәләбәй өязләрендә уңышлы сәүдә итәләр, халыктан тире-яры, йон җыюны оештыралар һәм аларны Германиягә озаталар. 1913 елда 125 мең сумлык тире җыелган була.

Чит илләргә – татар икмәге

Булдыклы эшмәкәр Хәлфиннәр илдә ашлык сәүдәсе белән дан яулый, зур абруй казана. Иген уңышы мул булган елларда алар 1 миллион сумлык ашлык сатып алып, аны эшкәртеп, Чаллының Чулман елгасындагы пристань һәм причаллары аша Рәсәйнең төрле өлкәләренә озаталар. Бу эштә Хәлфиннәр компаниясе унлап иң эре сәүдәгәр арасында атаклы Стахеевлардан (1,5-2,2 млн. сум) гына калыша. Бертуган Хәлфиннәрнең пароходлары һәм баржалары була. Ә үзләренеке җитешмәсә, А.Ф.Тимохов, А.А.Пешехонов һәм Я.П.Рукавешниковлардан арендага алып, йөкне җиңел пароходларга төяп тә озаталар. Ашлык сәүдәсенең алга китүенә төбәктәге уңай шартлар да ярдәм итә. Беренчедән, игенчеләрнең сатарга куелган ашлыгы күп, икенчедән, сатып алынган икмәкне уңайлы су юлы – Чулман, Нократ, Агыйдел һәм Идел елгалары буйлап аз чыгымнар белән еракка ташу мөмкинлеге бар.

Ашлык һәм башка тауарлар төялгән баржалар һәм суднолар, Чаллыдан кузгалып, Идел елгасы буйлап Казан, Түбән Новгород, Рыбинск, Ярославль һәм Әстерханга юл тота, Чулман буйлап югарыга – Пермь һәм Уфа губерналарына да бара.

Икмәкнең бер өлеше, Балтыйк диңгезе портлары аша, чит илләргә дә чыгарыла. Башка төбәкләр белән чагыштырганда ашлык бәясенең арзанрак булуы, су юлын-

нан файдалану Рәсәй һәм чит илләр базарларындагы көндәшләр арасында Хәлфиннәр тауарына өстенлекне бермә-бер арттыра.

Корылык аркасында иген уңышы аз булган елларда (1891, 1901, 1906, 1911) ашлык сәүдәсе дә нык кими. Гомуми күзәтү ясасак, Хәлфиннәрнең ашлык сәүдәсе ел саен алга барганын күрәбез. Мәсәлән, Чаллы пристане аша XIX гасырда бер елда уртача 2 млн. пот ашлык озатылган булса, 1910 елда ул – 8,4; 1913 елда исә 11,2 млн. потка җитә. Моннан тыш, алар 8 причалны да файдалана. Ул чакта Чаллы пристане Чулман елгасы буендагы иң зур ашлык ташу урыны була. Төбәктә ашлык сатып алу һәр елны август аеннан башлап, яңа елның март аена кадәр дәвам итә. Икмәкне төрле базарларда, Чаллыга үзләре китергән крестьяннардан, шулай ук Зәй, Сарман, Нөркәй, Карамалы һәм Туйгөлде кебек зур авыллардан күпләп сатып алу юлы белән туплыйлар. Ашлыкның бер өлеше күрше Алабуга, Чистай һәм Бәләбәй өязләреннән дә китерелә. Тупланган икмәк Чаллыдагы амбарларда саклана. Бередә Стахеевларның – 22, Хәлфиннәрнең – 5, башка 14 сәүдәгәрнең 42 ашлык амбары була. Амбарларның күбесе удел ведомствосына карап, саклануга алынган ашлыкның һәр поты өчен 3 тиен түләтә. Көзен һәм кышкы чорда ашлыкны чистарталар, киптерәләр, бер өлешен, тегермәннәрдә тарттырып, он һәм ярмага әйләндерәләр. Гадәттә, хәзерләнгән ашлыкның өчтән бер өлеше Чаллы пристане аша он, ярма рәвешендә озатыла һәм сәүдәгәрләргә яхшы табыш китерә.

Хәлфиннәр төзетеп, Рөстәм Фәйзрахман улы төзекләндергән мәчет

Ашлык сәүдәсендә мул табышны игенчеләрдән сатып алу һәм ерак төбәкләрдә сату бәяләре аермасы китерә. Соңыннан бу акчалар сәүдәне киңәйтү, кучемсез милек булдыру һәм химаячелек өчен тотыла. Хәлфиннәр компаниясенең башлангыч төп капиталы 1902 елда 150 мең сум булса, соңрак, 1913 елда ул 262,6 мең сум тәшкил итә.

Бертуган Хәлфиннәрнең сәүдә җәмгыяте 1900-1917 нче елларда Уфа һәм Казан губерналарында аеруча нәтиҗәле эшчәнлек алып бара. Россия патшасы да моңа игътибар итә һәм Мөхәммәтшакир Хәлфинне, фидакяр хезмәте өчен, бриллиантлы медаль белән бүләкли.

Чаллы элеваторы Хәлфиннәр тырышлыгы белән төзелә

Ашлык сәүдәсе нык алга китү нәтиҗәсендә, Чаллыда 1904 елда Дәүләт финанс казначылыгы булдырыла. 1914 елда, Хәлфиннәр тырышлыгы һәм башка

сәүдәгәрләр гозере белән, Дәүләт банкы финанслый торган программа нигезендә, Чаллыда ашлык элеваторы төзелә башлый. Аның 1,6 млн. сумлык чыгымын Россия финанс министры раслый. Шул елның язында башланган төзелеш 1917 елның сентябрендә генә тәмамлана. Элеваторга АКШ һәм Англиядә җитештерелгән механизмнар да куела.

Ике миллион пот бөртекле ашлык кабул итеп эшкәртә ала торган бу куәтле элеватор Рәсәйдә иң эреләрдән санала. Сыйдырышы ягыннан ул, Новороссийск һәм Самаранықыннан кала, өченче урында була. Ә иң мөһиме – Хәлфиннәр төзеткән элеватор хәзер дә сафта. Гражданнар сугышы вакытында аның белән көтелмәгән хәл килеп чыга. Көнчыгыштан Мәскәүгә хәрәкәт итүче Колчак гаскәре 1919 елда Чаллыны да басып ала. Әмма, шул ук елда Кызыл Армиянең көчле һөҗүме нәтиҗәсендә, чигенергә мәҗбүр була. Стратегик әһәмиятле Чаллы элеваторын совет хакимияте файдаланмасын өчен, аклар, аның җиһазларын сүтеп, үзләре белән алып китәләр. Әмма тора-бара хәлләре мөшкелләнеп, юлда ташлап калдыралар. 1920 елда элеватор җитәкчесе итеп билгеләнгән М.В.Дивавин талап алынган җиһазларны эзләп таба һәм аларны кайтартып, үз урыннарына куйдырта. Шулай итеп, предприятие яңадан бар куәтенә эшли башлый.

Хәлфиннәргә штраф салынмый

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, ашлык дәүләтнең стратегик запасына әйләнә. Россия Хөкүмәте икмәк сәүдәсен дәүләткә буйсындыра һәм аның белән идарә итүне үз кулына алып, сәүдәгәрләрнең хокукларын чикли. Чаллыга да хәрби вәкилләр килеп төшә. Алар тарафыннан икмәк запаслары төгәл рәвештә исәпкә алына, аны чит илләргә сату тыела, даими тикшерүләр үткәрелә. Сәүдәгәрләр ашлык запасы турында төгәл мәгълүмат биреп торырга тиеш була. Мәгълүмат вакытында бирелмәсә, зур суммада штраф салына. Архив документларында Хәлфиннәргә бәйле бернинди штраф яки кисәтү документлары да юк. Алар хөкүмәт таләпләрен төгәл үтәгәндер, мөгаен.

Сыйфатлы ашлык запасы беренче чиратта армиягә озатыла. Һәр пот икмәк өчен, базар бәясенә өстәп, 3 тиен акча түләнә. Бу исә гади халыкның икмәккә булган ихтыяҗын арттыра. Базарда, кибетләрдә икмәккә бәяләр нык үсә. Мәсәлән, 1915-1916 нчы еллар кышында бер капчык икенче сорт ак он бәясе Казанда 16 сум булса, Чистайда 24 сумга җитә.

Хәлфиннәрдән бер вәкил Минзәлә өязенең Земское собраниесенә депутат итеп сайлана торган булган. Бу җыенның эшмәкәрлек салымы мәсьәләләре белән шөгыльләнүче бүлеге Чаллыда да була. Аның әгъзалары, күренекле ашлык сәүдәгәрләре Г.Хәлфин, Д.Бушмакин, Ш.Зәйнашев, Г.Зәйнетдинов, М.Сәетбатталов үзләре дә күпләп салым түләүчеләрдән санала.

Берне биргәнгә Аллаһ унны бирер: мәгарифкә матди ярдәм

Бертуган Хәлфиннәр, ашлык сәүдәсе корылмаларыннан тыш, үзләре яшәгән Теләнче Тамак авылындагы утарларында, барокко элементларын кертеп, мәһабәт таш пулатлар салдыра. Ак таштан, ике катлы өч торак йорт, контора, амбарлар, ат абзарлары, кухнялар урнашкан бу утар биек таш дивар белән әйләндереп алына, аңа

Мирас мәчете

ике яктагы матур капкалар аша кереп-чыгып йөриләр. Гомуми мәйданы 1500 кв. метр тәшкил итеп, вак таш түшәп, тротуарлар салына.

XX гасыр башында Хәлфиннәр төзеткән ике мәчет, ике мәдрәсә, өч су тегермәне, ике тимерче алачыгы, Игәнә елгасы буенда алар утырткан алма һәм башка җиләк-җимеш бакчасы авылга сокланырлык ямь бирә. Кирәк-яракны монда яшәүчеләр биредәге кибетләрдән сатып ала.

Хәлфиннәр төзеткән мәчетләр, башка биналар әле дә халыкка хезмәт итә. 1935 елда Ворошилов исемендәге район төзелгәч, таш пулатларда партия һәм совет органнары, НКВД урнаша. 1984 елда авыл Тукай районына күчкәч, биналарны коррекция мәктәбенә, картлар һәм инвалидлар интернат-йортына бирәләр.

Булдыклы сәүдәгәр һәм эшмәкәр Хәлфиннәр, диндар, хәерхаһ затлар, юмарт хәйрияче буларак, төбәк халкының зур ихтирамын казана. Бертуган Хәлфиннәр еллык керемнең кырыктан бер өлешен зәкят итеп мохтаҗларга тарата, һәр бәйрәмдә ярлыларга бүләк өләшә. Алар авыл халкы белән дустанә яшиләр, хезмәтләре өчен әйбәт түлиләр, колхоздагы кебек бушка эшләтмиләр. Моннан тыш, үзләрендә эшләгән кешеләрнең балаларын мәдрәсәләрдә бушлай укыталар. Бертуган Хәлфиннәр милли мәгарифкә саллы матди ярдәм күрсәтеп киләләр. Алар үзләре яшәгән Теләнче Тамак авылында башта кызыл кирпечтән ике катлы мәдрәсә салдыралар, аны үз акчаларына тәэмин итеп торалар. Биредә ир балалар белем ала. Соңрак кыз балалар өчен дә агачтан мәдрәсә төзетәләр.

Бу мәдрәсәдә 1860 елда 250 шәкерт укыса, 1910-1912 нче елларда аларның саны 500гә җитә, укыту 1917 елга кадәр дәвам итә. Бирегә Чаллы, Минзәлә, Сарман, Әлмәт, Азнакай һәм Чистай якларыннан килеп укыйлар. Белем бирү дәрәҗәсе шактый югары булып, данлыклы Иж-Бубый мәдрәсәсеннән аз гына калыша.

1890 елдан башлап әлеге мәдрәсәләрдә, дини гыйлем белән бергә, тарих, география, ботаника, математика кебек дөньяви фәннәрне дә укыта һәм имтиханнар оештыра башлыйлар. Бирегә иң укымышлы мөгаллимнәр чакырып китерелә, аларга әйбәт хезмәт хакы түләнә: елына – 50-70 сум! Күпме бу акча, азмы? Чагыштыру өчен: ул чорда 400 грамм ит – 1 тиен, 400 грамм шикәр – 17 тиен, бер пот он – 40-50 тиен, бер метр ситса – 12-13 тиен, сатин – 15-16 тиен, сыер – 5-6 сум, ат – 11-12 сум бәяләнгән. Хәлфиннәр аеруча талантлы укытучыларны чит илләргә җибәреп тә укытып кайтарганнар.

Теләнче Тамак мәдрәсәсендә берара Кәрим Тинчурин да укый. 1907 елда Хәлфиннәрдә классик язучы Гаяз Исхакый кунак була. Ул, Нәҗип Хәлфин язмышы нигезендә, «Алдым-бирдем» исемле пьеса-комедия яза. Әсәрдә бертуган сәүдәгәрләрнең шушы авыл утарындагы тормышы сурәтләнгән. Төрле елларда бу җирлектә Ризаэддин Фәхреддин, Таҗи Гыйззәт тә булып китә.

1910 нчы елларда Хәлфиннәр мәдрәсә бинасы янына таш мәчет салдыра, шәкертләр дә намазны шунда укый. Совет чорында аның манарасы сүтелә, бу бина мәктәп итеп файдаланыла. Нигездән төзекләндереп, элекке рәвешенә кайтартылгач, мәчет 1999 елдан яңадан эшли башлый, шунда ук мәдрәсә дә оештырыла. Авыл халкы мәчетне аякка бастырган авылдашларына, бигрәк тә булдыклы эшмәкәр Рөстәм Фәйзерахман улы Закировка бик рәхмәтле.

Теләнче Тамак авылында Хәлфиннәр агачтан төзеткән икенче мәчетнең дә манарасы киселә. Ул озак еллар мәдәният йорты, китапханә булып файдаланыла. Хәзерге вакытта тарихи мәчеттә яңадан моңлы азан тавышы яңгырый, мөселманнар гыйбадәт кыла.

Хәйрияче Хәлфиннәр Чаллыда да мәчет, Ятим балалар йорты, Мөслим төбәгендәге Олы Чакмак авылында таштан мәчет төзетәләр. Эшмәкәр, инженер Шакир Садыйк улы Хәлфин 1916 елда Чаллы-Бөгелмә арасында тимер юл проектын эшли, патшадан рөхсәт тә ала, әмма 1917 елгы октябрь инкыйлабы башлану аның әлеге хыялын тормышка ашырырга мөмкинлек бирми.

Хәлфиннәрнең исән калганнары Төркиягә китмәкче була

Октябрь инкыйлабыннан соң, күп байларның, алпавытларның җирләрен тартып алып, утарларын, мал-мөлкәтләрен ут төртеп яндыралар. Мәсәлән, Теләнче Тамак авылыннан 3-4 чакрым ераклыктагы иген кырлары алпавыт Михаил Останковның үз крестьяннары тарафыннан харап ителә. Хәерхаһ Хәлфиннәр милкенә авыл халкы кагылмый, әмма совет власте, большевиклар явызларча каныга. 1918 елда алардан зур суммада контрибуция түләтәләр. Соңрак, халык дошманы дигән нахак ярлык тагып, репрессиягә дучар итәләр. Хәлфиннәрне яшәгән йортларыннан куып чыгаралар, мал-мөлкәтләрен талап алалар, төрмәгә ябалар, Архангель өлкәсенә, Соловкига сөргенгә озаталар. Хәлфиннәрнең исән калганнары Баку аша Төркиягә китмәкче була, әмма ноябрь ахырында Уфадан кузгалып киткән пароход бозда катып кала. Пассажирлар — 160лап татар таралып-качып бетә. Хәлфиннәрнең нәсел-нәсәбенә, оныкларына да көн калмый. Алар Сталин репрессияләреннән күп зыян күрә, күбесе һәлак була, атып үтерелә.

Хәлфиннәр нәселеннән булган замандашларыбыз шактый

1972 елда Казанда яшәүче Хәдичә Хәлфина (Йосыпова) сәүдәгәр Хәлфиннәрнең нәсел шәҗәрәсен төзи. Бу данлыклы нәселгә тоташкан, халкыбызга, милләтебезгә фидакяр хезмәт иткән замандашларыбыз шактый. Менә аларның кайберләре: **Диләвәр Мирзагабдулла улы Зөбәеров** (1931) – биохимик, ТФА академигы, РФ дәүләт бүләге лауреаты, ТРның атказанган фән эшлеклесе; **Кушай Хәмид Зөбәер** (1897-1978) – тарихчы, археолог, профессор; **Харис Зариф улы Фәйзуллин** (1871-1933) – мөгаллим, дәреслекләр авторы, нашир; **Җәүдәт Фәйзи** (1910-1943) – композитор, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның халык артисты, ТАССРның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе; **Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева** (1928-2005) – шагыйрә, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе; **Әүфәр Зәки улы Зәкиев** (1938-1994) – инженер-төзүче, Татарстанның атказанган төзүчесе, ТРның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе; **Азат Вәсим улы Зәкиев** – «Иншаат» төзелеш фирмасының генераль директоры. ■

Безнең мирас №4 апрель 2022

Рамил Муллин: «Түбән Каманың киләчәге матур булыр»

*(Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Рамил Хәмзә улы Муллин** белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон** әңгәмәсе)*

– Мөслим җирлегендә Бөтенроссия авыл Сабан туе үткәреп, чит төбәкләрдән килгән кунакларны шаккатырган идегез. Алар монда: «Шулай да яшәп була икән бит!» – дигән фикергә килделәр. Хәзер яңадан Түбән Камада эшлисез. Тәэсирләрегез ничегрәк?

– Унбер елдан соң, яңадан Түбән Камага әйләнеп кайттым. Мин килгәнче үк, җөмһүриятебез Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов программалары шәһәрне уңай якка үзгәрткән иде. Икътисади яктан да тотрыклылык сизелә. «Түбән Кама Нефтехим», «ТАНЭКО», «Татнефть» кебек зур предприятиеләр булуы һәм аларның даими ярдәме шәһәр үсешенә уңай йогынты ясый. «СИБУР» да районыбызга яңа үзгәрешләр алып килде. Әмма камиллеккә чикләр юк, башкарасы эшләр күп, чөнки тормышыбыз гел алга бара, үзгәреп тора…

– Мөслимдә туган телне кайгырту буенча мактанырлык эшләр калдырып киттегез. Түбән Кама бу мәсьәләдә ничек?

– Биредә тулаем нинди милләтләр яшәвеннән чыгып фикер йөртергә кирәк, чөнки район халкының яртысы татарлар булса, рус, чуаш милләтеннән булганнар да шактый. Түбән Камада 50гә якын милләт кешесе гомер кичерә. Шулардан 15е – Халыклар дуслыгы йортының иң актив вәкилләре. Аларның үз оешмалары, милли ансамбльләре, якшәмбе мәктәпләре бар. Татар, рус һәм чуаш җәмгыятьләренә йөрүчеләр саны аеруча күп. Районда бер чуаш мәктәбе дә эшләп килә.

Түбән Кама шәһәрендәге дәүләт оешмаларында татарча алай күп сөйләшәләр димәс идем. Шулай да урамда татар телен еш ишетәм. Әмма максат бер: Татарстан Җөмһүриятенең дәүләт телләрен тиешле дәрәҗәдә өйрәтү. Театр, сәнгать түгәрәкләре, төрле кичәләр, махсус очрашулар оештыруга, дәресләр үткәрүгә, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте өлкәсендә дә туган телләр мәсьәләсенә зур игътибар бирәм. Урам, бина исемнәренең татарча дөрес язылышы да читтә калырга тиеш түгел. Киңәшмәләрдә татар телендә сөйләргә тырышам. Татар кешеләреннән дә шуны таләп итәм.

– Әхсән Фәтхетдинов музеена рус телендә генә язылган…

– Әйе, төзәтәсе җитешсезлекләр күп. Аларның вакыт узу белән хәл ителәсенә ышанам. Кайбер урам исемнәренең тәрҗемәсе бәхәс тудыра. Бу өлкәдә безгә белгечләр ярдәме кирәк. Һәр

урам һәм дәүләт оешмасының исеме дөрес итеп, ике телдә язылырга тиеш. Бу – якын киләчәктә гамәлгә ашырылачак төп эшләрнең берсе.

– Сез бит әле шәһәр мэры да. Бу исә икеләтә җаваплылык: шәһәр проблемаларын да, авылныкын да тигез дәрәҗәдә хәл итәргә кирәк. Эшләр бермә-бер арткандыр?..

– Әлбәттә, хәл итәсе мәсьәләләр артты. Кыш көне кар чистартуны гына алыйк. Түбән Камада аның билгеле бер тәртибе юк иде. Гомумән, Мөслимдә күп мәсьәләләрне җайга салырга тырыштым. Мөслимдә авыл хуҗалыгы өстенлекле юнәлеш булса, Түбән Кама районында авыллар шәһәргә якын булганлыктан, кешеләр авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнми диярлек. Мал тотып, хуҗалык алып баруга караганда, аңа, шәһәргә барып, сәнәгать тармагында эшләү күпкә отышлырак. Президентыбыз: «Авыл тормышында хилафлыклар күп», – дип кисәтү ясады. Әлбәттә, күп. Арча, Әтнә, Актаныш, Мөслим кебек чиста авыл хуҗалыгы районнарыннан аермалы буларак, Түбән Камада тормыш рәвеше башкачарак. Биредә рус, керәшен авыллары бар, бер авыл эчендә төрле милләт вәкилләре яши – төрле холык, төрле яшәү рәвеше, эшкә, җиргә караш бөтенләй башка. Авыл хуҗалыгына кешеләрне җәлеп итү мөмкин түгел диярлек. Шәһәр якын булгач, кече фермерлыкны үстерергә, шәһәр халкына кирәкле ризыкны җитештерергә мөмкин.

Шәһәрдәге чисталык, яшеллек, биналарны төзекләндерү буенча хәл итәсе күп кенә эшләр бар. «Түбән Кама-60» дигән махсус программа булдырдык. Аны 2026 елга төгәлләргә ниятлибез. Илләр имин булса, шушы берничә ел эчендә районыбызда төзекләндерелмәгән бер генә мәктәп тә, мәдәният һәм спорт оешмасы да калырга тиеш түгел. Бинаның төзек булуы бер хәл, аның эчен, эчтәлеген дә кайгыртырга кирәк. Тәрбия, сәнгать ягыннан да башкарасы эшләр бихисап. Мәсәлән, ни өчен җирлегебездә мәктәп театрлары булдырмаска?! Бу бит – телне камил өйрәнү өчен менә дигән мөмкинлек. Беренчедән, баланың сөйләме, икенчедән, сәхнәдә үзүзен тотышы, өченчедән, актерлык, рольгә керү сәләте шунда чарлана. Киләчәктә балаларны, зур сәхнәләргә алып чыгып, әти-әниләр белән бергә спектакль карарга өйрәтергә кирәк. Әлеге мөһим эш баланың рухи дөньясын үстерергә бер этәргеч булачак, чөнки бүгенге көндә аерым игътибар таләп итә торган иң зәгыйфь ягыбыз – әхлакый тормышыбыз. Ватанпәрвәрлек, рухи-әхлакый мәсьәләдә шактый гына артка тәгәрәдек. БДИларга артык мөкиббән китеп, тәрбияне икенче планга күчердек. Ә максат – тәрбияле, акыллы, тормышта үз юлын, юнәлешен булдырган, милләтен, тарихи мирасын белгән һәм аны хөрмәт иткән балалар тәрбияләү.

«Түбән Кама-60» проекты ике өлештән тора: беренчесе – төзелеш һәм төзекләндерү эшләре; икенчесе – әхлакый үзаң булдыру. Без Түбән Каманы киләсе биш, ун-егерме елдан соң ничек күз алдына китерәбез? Районда мәдәният, мәгариф, сәламәтлек тармаклары кайсы юнәлештә үсеш алырга тиеш? Бу сорауларга җавап табар өчен, халык белән очрашулар үткәрәбез. Биредә яшәүчеләргә нинди шәһәр кирәк? Аларныниләр борчый? Барысын да уртага салып сөйләшәбез. Уртак фикерләр туплап, бергәләп гамәлгә ашырсак, киләчәгебез тагын да матуррак булыр, иншәАллаһ.

– Балаларны тәрбияләү мәсьәләсендә курчак театрлары да бар. Хәзер сәхнәдә курчак та, артист үзе дә уйный. Ни өчен курчакларга гына әйләнеп кайтмаска?! Югыйсә, курчак театры булгач, анда курчак кына уйнарга тиеш! Курчакны балалар үзләре дә матур итеп ясый ала. Мин Түбән Камада моның матур үрнәкләрен күргән идем. Сезнең районда бу җәһәттән курчак театрлары да җанланып китмәсме?

– Юнәлешләр бик күп, әмма аларны гамәлгә ашыра алырдай хыялый һәм шул ук вакытта эшлекле дә булган кешеләр кирәк. Талантсыз бала юк! Бары тик аны күрә һәм тәрбияли белергә, баланың иҗади мөмкинлекләрен ачар өчен, иренмичә, көч куеп эшләргә генә кирәк. Әйтик, ни өчен һәр мәктәпнең үзендә «Йолдызлык» фестивале оештырмаска?! Түбән Кама яшь тамашачылар театрында өч мәйданчык булдыру планлаштырыла. Дөрестән дә, бер мәйданчыкны – курчак театрына, кече яшьтәгеләргә бирергә кирәктер. Икенчесен – яшүсмерләргә, өченчесен – яшьләргә. Сәхнә осталарын үзебездә тәрбияли алсак, бик яхшы булыр иде.

Бүген авыл тормышы белән шәһәр тормышы арасында аерма югала бара. Әмма авылның да, шәһәрнең дә һәркайсының үз нигъмәте һәм шулай ук үз борчу-мәшәкатьләре бар. Мәсәлән, авыл урамнарында автобус йөрү ихтыяҗы юк, ә шәһәрдә бу – көнүзәк мәсьәлә. Авылда вакытның нигъмәтен аңлыйсың, шәһәрдә көне буе чабып йөрсәң дә, вакытны куып тота алмыйсың. Миңа һәр кеше үз тәкъдиме белән килсен иде. Түбән Камада фикерләр мәйданчыгы булдырырга телибез. Дөрес, фикерле кешеләр бар, хәтта алар күп дияр идем. Әмма фикер генә җитми! Беркөнне миңа берәү яза: «Җитәкче булсам, кар чистартып күрсәтер идем мин Сезгә!» – ди. Аңа: «Әйдә, кил әле, синең кебек дәрте-көче ташып торган, фикерле кешеләр безгә бик кирәк!» – дигән идем – җавабы юк. Мондый «фикерле» кешеләрдән файдалы гамәл көтеп булмый. Нидер үзгәртергә, нәрсәдер булдырырга телибез икән, иң әүвәл үзебездән башларга һәм үзебез гамәл кылырга тиешбез. Өстәвенә, бу гамәлләрне халыкның хуплавы да мөһим. Минем максатым – урындагы халыкны, яшьләрне уятып, җанландырып җибәрү. Безнең өчен читтән килеп, беркем дә берни дә эшләмәячәк! Нинди генә «алтын» җитәкче, аның «көмеш» урынбасарлары булмасын, гамәлләрен халык хупламый икән, бернинди эш тә барып чыкмаячак. Җитәкчеләрне җыеп, аларга: «Якын киләчәктә шәһәрне ни рәвешле күз алдына китерәсез? Халыкны борчыган мәсьәләләрне ничек хәл итәргә мөмкин?» – дигән сораулар куйдым. Парк ясаргамы? Мәктәпне төзекләндерергәме?.. Барын да уртага салып, киңәшеп эшләргә кирәк. Бер баш – яхшы, ике баш аннан да яхшырак, диләр бит. Әгәр халык үзе дә җирлегебез үсешендә актив катнаша һәм безнең гамәлләрне хуплый икән, иң шәп шәһәр һәм иң матур урам аныкы булачак! Шул очракта гына яшәгән җиребезгә бәрәкәт һәм иминлек иңәр дип уйлыйм.

– Заманында Түбән Камадагы «Җидегән чишмә» әдәби-музыкаль берләшмәсе үсешенә мәшһүр шәхесләребез Сара Садыйкова, Мостай Кәрим, Нажар Нәҗми, Сибгат Хәким һәм Илһам Шакировлар зур йогынты ясаган. Түбән Камага Мөслим, Актаныш, Минзәлә халкы күпләп күчеп килгән. Алар биредәге халыкның рухи-мәдәни, әхлакый үсешендә зур роль уйнаган. Галим һәм җитәкче Азат Зыятдинов «Җидегән чишмә» өчен янып-көеп яшәүче кешеләрнең берсе иде. Түбән Кама тумасы Рафаэль Сәхәбиевне белмәгән кеше сирәк. Әлеге шәхесләрнең исемнәрен мәңгеләштерү буенча ниләр эшләргә уйлыйсыз? Мөслимдә әдәбият-сәнгать көннәре матур гына уза иде. Бу эш Түбән Камада да дәвам итәр дип уйлыйм...

– Без балаларны чит ил шәхесләре үрнәгендә тәрбияли башладык. Футболчы, җырчы, миллионермы – барысы да чит илнеке, ә арабыздагы, янәшәбездәге төрле күренекле әһелләребезне оныттык. Үз тарихын һәм шәхесләрен белмәгән халыкның киләчәге юк. Әгәр без киләчәгебезне нык, тотрыклы итеп корырга, үзебезнең телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калырга телибез икән, төп игътибарны танылган шәхесләребезгә юнәлтергә, алар белән горурланырга, яшь буынны алар үрнәгендә тәрбияләргә тиешбез. Безнең илне эченнән җимереп, гадәти гаиләләрне таркатырга тырышып карадылар. Классик җәмгыятебезнең ныклыгын, тотрыклылыгын тәэмин итәсебез килсә, бай рухи мирасыбыз нигезендә тәрбияләү мөһим. Читкә тайпылсак, татар үз-үзен батырачак! Иң зур максат – тарихи шәхесләребезне барлау, аларның тормышын, иҗатын өйрәнү. «Әдәбиятта һәм мәдәнияттә мөслимлеләр» дигән матур гына музей оештырып, барлык талантларыбызның мирасын бер урынга җыйган идек. Түбән Камада да бүген шундый ук эчтәлектәге музей кирәк. Татарстанның атказанган спорт остасы, татар халкының атаклы көрәшчесе Данил Галиев хәзерге яшүсмерләргә үрнәк булырлык шәхес түгелмени?! Техник фәннәр докторы Азат абый Зыятдинов эшчәнлеге фән белән кызыксынучы яшьләргә өлге була алмыймы? Ул бер үк вакытта галим дә, талантлы җитәкче дә, милли җанлы шәхес тә булган, мәгълүм булганча, «Җидегән чишмә»гә үзенең күпме көчен, хезмәтен, тырышлыгын биргән! Бүген безгә җитәкчеләребезне дә уятырга кирәк! Әлегә алар күпкырлы эшчәнлек алып баралар дип әйтеп булмый. Вакытлар үтәр, үзебез дә лаеклы ялга чыгарбыз, бездән соң да эз калыр. Шул чакта безнең хакта уйларлармы, безне искә алырлармы?!

Элеккегеләр белән бергә, хәзерге көндә бар күңелен биреп, җаны-тәне белән тырышып эшләүче якташларыбызны да онытырга ярамый. Мисалга, шәһәребездә Наил Шәкүр улы Мо-

сифуллин 600 баланы биергә өйрәтә. Бу бит – Түбән Кама өчен зур хәзинә! Кадерен белергә кирәклеген яхшы аңлыйбыз, әмма аның бүгенге көндә хореография өчен махсус бинасы да юк. Мин әлегә бу бинаның кайда урнашасын да әйтә алмыйм. Әмма ул, һичшиксез, булырга тиеш! Сәләтле кешеләр бар икән, аларга игътибарны кызганмыйк! Түбән Кама – шәхесләргә бик бай төбәк, шуларны бергә туплап, аерым мәйданчыклар эшли алсак, уңай нәтиҗәсен бирми калмас дип уйлыйм.

– Түбән Кама дигәч, экологик проблемалар да күз уңында тора. Элек шәһәрдә экологик хәл бик тә кискен иде. Хәзер ни хәлдә?

– Ләбиб абый, саф һавада яшәргә, чишмәдән чиста су эчәргә телисез икән, рәхим итеп, Түрештә гомер итегез*. Әле анда да чишмә юлында сыер исе килеп торачак.

Түбән Кама химия белән бергә сәнәгать үзәге буларак та төзелә башлаган. Төзүчеләр, бирегә килгәч: «Ничек инде без, шәһәр төземичә, завод кына төзик?» – дигән сорау куйганнар. Узган ел шәһәребезгә 55 ел тулды, ә быел исә «Түбән Кама Нефтехим»га – 55. Алар – яшьтәшләр, шәһәр һәм нефть химиясе бертуганнар кебек бергә үскән. Химия булганга, шәһәр дә бар. Химия – безнең горурлыгыбыз! Ул – зур байлык һәм бик куәтле мөмкинлекләр чыганагы да. Хәзерге көндә сәнәгать тармагында 40 меңгә якын кеше хезмәт куя. Гаилә әһелләрен дә исәпкә алсаң, тулы бер шәһәр дигән сүз. Нефть химиясе, нефть эшкәртү комплексларының бер урында болай күп тупланы Россиянең бер генә төбәгендә дә юк диярлек.

Ә байлыкның үз мәшәкатьләре дә бар. 40-50 ел элек төзелгән заводлар, мөгаен, бүгенге таләпләргә туры килеп тә бетми торгандыр, ләкин соңгы елларда салынган «ТАНЭКО» кебек сәнәгать комплекслары дөньякүләм экологик стандартларга туры килә. «Этилен-600» заводы төзелеп ята. Әле яңа гына аның проектын Россия табигать күзәтчелеге җитәкчесе Светлана Радионовага тәкъдим иттек. Россия күләмендә һавага чыга торган зарарлы матдәләр күрсәткече – 1 процент, Европада 0,5 процент булса, әлеге заводта исә ул 0,1-0,2 процент кына булачак. Биредә өр-яңа технология кулланыла. Узган ел «ТАНЭКО» табигатьне саклау өчен – 27 миллиард, «Түбән Кама Нефтехим» 13 миллиард сумлык чыгымнар тоткан. Алдагы елда предприятие табигатьне саклау чараларына 12 миллиард сум тотарга планлаштыра. Әле дә хәтерлим, биредә элек эшләгән елларымда Түбән Кама шин заводы диварлары кап-кара иде. Хәзер ул соры төскә кергән, киләчәктә, «Татнефть» яңартып кору үткәргәннән соң, аның стенасы ап-ак булачак. «СИБУР» белән дә экология темасына сөйләшүләр алып барабыз. Әйләнә-тирә мохитне саклау таләпләренә туры килмәгән заводлар киләчәктә әкренләп ябылып бетәчәк яки үзгәртеп корылачак. Углерод калдыклары элек һавага очса, хәзер аларны чыгарылган нефть ятмалары урынына, җир астына урнаштыралар.

Табигатьне мөмкин булганча сакларга кирәклеген һәркем яхшы аңлый, һичшиксез, табигый мирасыбыз игътибарга лаек. Киләсе 3-5 ел эчендә бу мәсьәләләр тулысынча хәл ителер дип өметләнәм. Түбән Камада Россия табигать күзәтчелегенең филиалы, заманча лаборатория ачылды, Экология министрлыгы тарафыннан да күзәтү бик көчле. Һәр заводта лабораторияләр эшли, фильтрлар үз вакытында алмаштырыла. Болар бернинди хилафлыкларга да юл куймаячак. Түбән Камадагы һәр җитәкче: «Безнең оешма экологик иминлекне тәэмин итә ала!» – дип әйтергә хаклы. Урманнар утыртуны, шәһәрне яшелләндерүне дәвам итәбез. Үрнәк алырлык мисаллар байтак, мәсәлән, Сингапурның үзәгендә зур завод тора – бернинди проблема юк. Түбән Кама шәһәрендә дә курыкмыйча яшәргә була. Шәһәрнең киләчәге матур булыр дип уйлыйм.

– Рәхмәт! Мөслим кебек авылда амфитеатрлар ачканны, Түбән Камада зур мәдәни мәйданнар булдыра алырсыз дип өметләнәм. Теләк-хыялларыгыз чынга ашсын!

Әңгәмәне журналга ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

---

* Ләбиб Лерон Мөслим районының Түреш авылында туган. – *Ред.*

Безнең мирас №4 апрель 2022

«КАМА ТАҢНАРЫ» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕНӘ 55 ЕЛ

Түбән Кама – гүзәл кала

(«Кама таңнары» әдәби берләшмәсе әгъзаларының иҗаты)

Әхлак берлә әдәбият бергә булырлар.
Бер кавемнең әдәбияты нинди рәвештә булса,
әхлагы да шул рәвештә булыр.
Ризаэддин Фәхреддин

«Кама таңнары» әдәби берләшмәсе әгъзалары (сулдан уңга): Фәтхулла Абдуллин, Рахмай Хисмәтуллин, Камил Гыйльмуллин, Минвәгыйз Зәйнетдинов, Әхмәт Гадел, Мизхәт Хәбибуллин (шигырь укыган мәле) һәм Айдар Хәлим 44 нче училище укучылары белән очрашу вакытында. 1969 ел

1965 елны Түбән Кама районы оеша һәм рус телендә – «Ленинская правда», татарча «Ленин нурлары» газеталары чыга башлый. Шул ук елны «Ленин нурлары» газетасы каршында әдәби түгәрәк оеша. Аның җитәкчесе итеп үзе дә шигырьләр язган Камил Гыйльмуллин билгеләнә. Ә инде шәһәребезгә тынгысыз җанлы, ярсу йөрәкле Рахмай Хисмәтуллин, Айдар Хәлимнәр килгәч, күңелләрендә иҗат оеткысы булган яшь каләм тибрәтүчеләр, әдәбият сөючеләрнең саны бермә-бер арта, әдәби мохит түгәрәк кысаларына гына сыймый башлый.

1968 елның сентябреннән ул әдәби берләшмәгә әйләнде һәм аңа «Кама таңнары» исеме» бирелде. Җитәкчесе итеп Рәшит Юнысов сайланды, җаваплы сәркатип вазыйфасы Айдар Хәлимгә йөкләнде. Беркетмәләр алып баручы сәркатип итеп Фәннур Сафин билгеләнде. (Гаделлек өчен әйтеп үтәргә кирәк, бер ел чамасы эшләгәннән соң, Р.Юнысовны «Нефтехимик» газетасы редакторы булып эшләүче Минвәгыйз Зәйнетдинов алыштырды. 1970 елның 10 октябреннән 1987 елга кадәр бу мәшәкатьле вазыйфаны Рахмай Хисмәтуллин тартып барды.) Берләшмә әгъзаларының күбесе шәһәр төзелешендә, химкомбинат цехларында

эшләүче гап-гади хезмәт кешеләре иде: Мизхәт Хәбибуллин, Мөхәммәт Шәйхи – тимерләрне эретеп беркетүче; Фәннур Сафин, Рифкать Имаев – «Нефтехим» берләшмәсендә слесарь, аппаратчы; Мөслих Тажи, Фәтхулла Абдуллин – прораб; Фәния Хуҗиәхмәтова кранчы булып эшләде.

Ул чорда берләшмә утырышларына җырчылар, музыкантлар, рәссамнар да йөрде. Әйтик, нефть химиясе өлкәсендә булачак галим Азат Зыятдинов, режиссер Наил Нуретдинов, инженер-конструктор Нил Садыйков, киләчәктә Г.Тукай премиясе лауреаты булачак рәссам Әхсән Фәтхетдинов кебек егетләр берләшмә әгъзалары белән бер казанда кайнады.

Бүгенге көндә «Кама таңнары» әдәби берләшмәсендә утыздан артык язучы каләм чарлый. Шулар арасында Фәтхулла Абдуллин, Рифкать Имаев (быелның март аенда вафат булды), Илдар Хәйруллин, Марс Хафизов, Хөсәен Җәгъфәр, Фәрит Имамов, Илзирә Вәлиуллина, Нурзия Мирхазова Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары булып тора. Хәзерге вакытта берләшмәне шагыйрә Рәсимә Нәбиуллина җитәкли.

Фәтхулла Абдуллин,
2003-2017 нче еллардагы «Кама таңнары»
әдәби берләшмәсенең җитәкчесе,
Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Рахмай Хисмәтуллин
(1934-2004)

Барыбер яфрак ярачак

Ничек аккан дөнья – шулай агачак,
Дулкын шулай һаман ярны кагачак,
Баш игәнне басу җаен табачак...
Әмма кыса-кыса арачак,
Тәкәбберләр яман хәлгә тарачак.
Ялкау җанны пәрәвезләр сарачак,
Вөҗдансызлар, шиксез, хөкемен алачак.
Җир җитмәгән – өч аршынга сыячак,
Оран салып яңа сафлар туачак.
Астагылар өскә менә барачак,
Шытып килгән барыбер яфрак ярачак!

Рәшит Гәрәй
(1931-1999)

Кыр казлары киткәндә

Кыр казлары оча җылы якка,
Күз күрмәгән ерак җирләргә.
Тын һавада моңсу тавышлары
Сәлам булып җилдә тибрәлә.

Саубуллашу җиңел, дигән сүзне
Ишетмәдем әле беркемнән.
Бер кыр казы калган аерылып
Үзе очып килгән төркемнән.

Иптәшләрен куып җитәлмәсә,
Ялгыз башы кая сыеныр?!
Аңа карап тирән уйга чумдым:
Туган җирсез яшәү кыендыр.

Яшьлек урамында (Түбән Кама) Тукай һәйкәле. Авторлары – Ф.Ханов, Б.Урманче. 1991 ел

Мөхәммәт Шәйхи
(1949-1996)

Моң

Сандугач булсаң иде дә,
Гел сайрап торсаң иде,
Сайравыңны тыңлап, җиһан
Моңнарга чумса иде...

Сандугач булсаң иде лә
Илеңдә, төбәгеңдә –
Идел-Кама тирәгендә –
Халкыңның йөрәгендә.

Мизхәт Хәбибуллин
(1940-1995)

Күңел һаман эзләр

Алмагачның алмаларын
Өзәргә килгән көзләр.
Алмаларын өзәр көзләр,
Алмагач ничек түзәр?..

Күрешүләр көткән кебек,
Еракка карый күзләр...
Без белмәгән кешеләргә
Бар күк әйтәсе сүзләр...

Чәчәкләрне өшетердәй
Сулышын өрер көзләр.
Күңел һаман көлеп торган
Җәйге чәчәген эзләр.

Фәнзаман Баттал (1939-2015)

Түбән Камада Тукай урамы

Кыска гына урам, читтә генә...
Йортлары да моңсу, юлы да.
Шушы урам бик тә лаек икән
Халкыбызның бөек улына.

Кыскалыгы – аның гомере кебек,
Моңсулыгы – аның карашы.
Бу моңсулык әле күп гасырлар
Булыр безгә йөрәк ярасы.

Ник читтәме? Сабый чагыннан ул
Ятим булган, читкә кагылган.
Ыспай байгуралар кимсетүе
Кала читләрендә чагылган.

Дошманнары һаман урталыкта
Ат уйнаткан, өскә үрелгән...
Ялтыр түрәләргә мыскыл белән
Карый Тукай тарих түреннән.

Рифкать Имаев (1948-2022)

Җитми туган якларга

Узды явып җылы яңгыр –
Аңлады, көттермәде.
Артыннан ук килеп чыкты
Салават күперләре.
Аңлашканнар җир белән күк,
Гамәлләре изгедән.
Ялтырый су, аз гына да
Ким түгелдер көзгедән.
Тау битендә җиләк пешкән,
Болыннары – шау чәчәк.
Минем кебек хыялыйлар
Исереп йөриячәк.

Тирәкләрдә – сандугачлар,
Чәчәкләрдә – бал корты.
Ял итәргә телим, дисәң,
Бу бит – әзер ял йорты.
Карап торам таңнар калып,
Таңнар ата алланып.
Уза рәхәт җәйге көннәр –
Бер-берсенә ялганып.
Бу илаһи гүзәллекне
Ничек бозмый сакларга?
Тотасыз да, чит ил, дисез,
Җитми туган якларга!

Мирзанур Шәймурзин

Туган тел

Туган тел ул – зур байлыгы,
Хәзинәсе халкымның.
Туган телгә тиңләшалмый
Таулары да алтынның.
Туган тел ул – йөзек кашы,
Аң-белеме халкымның.

Ана телен саклап калу –
Бурычыдыр һәркемнең.
Телдән башка, милләт бит ул –
Тамырын кискән агач.
Җир дә әле, без булганда,
Татар телен югалтмас!

«Кама таңнары» әдәби берләшмәсе утырышыннан соң

Фәнүзә Сабирова

Туган калам

Чулман ярларында ак нур булып
Балкыйсың син, гүзәл шәһәрем.
Горурланып синең уңышларга:
«Туган калам!» – диеп дәшәмен.

Чулман өсләрендә акчарлаклар
Дулкыннарга кага канатын.
Гүзәл калам, сине, Түбән Камам,
Туган ягым итеп яраттым.

Рәфыйк Әхмәдиев

Ныклык

Адәмнәргә бу дөньяда
Иман ныклыгы кирәк.
Иманы нык булган гына
Булыр милләткә терәк!

Рәсимә Нәбиуллина

Адәм баласы

Сикертә тормыш арбасы
Ничек төшми каласы?!.
Кайларда гына йөрсә дә,
Түзә адәм баласы.
Түзә сагыну-сагышларга,
Кул бирер соң кайсысы?
Гомер җебен кисә гүя
Ачы язмыш кайчысы.

Аямый ачы сынаулар,
Исә җилнең ачысы.
Һәр кешенең казан тулы,
Һәркемнең үз кайгысы.
Моңсуланып уйлап куям,
Һай, бу гомер агышы.
Йөрәкләрне телеп үтте
Киек казлар тавышы.

Түбән Камадагы Г.Тукай исемендәге үзәк китапханәдә (2014 елның 1 октябреннән Гөлназ Рәмзил кызы Арсланова җитәкли) бөек шагыйрьгә нисбәтле китаплар

Гөләндәм Галиева

Мин – татар

Туган телем минем – татар теле,
Гасырлардан килгән шаны бар.
Үз тарихы, шөкер, үз кыйбласы,
Мәртәбәсе, төрки даны бар.
Нигә мескен булсын минем телем?
Нигә аны үги итәргә?
Кемнең ни хакы бар шушы телне,
Түбәнсетеп, мыскыл итәргә?

Туган телем өчен җаным фида,
Бары туган телдә сөйләшәм.
Әнкәм телен саклап калу өчен
Җаным-тәнем белән көрәшәм!
Бөек Атиллалар оныгы мин,
Дәвамчысы Тукай, Җәлилнең.
«Мин – татар!» – дип, горурланып әйтәм. –
Киләчәге олуг кавемнең!

Марс Хафизов

Түбән Камам

Алсуланып кына таң ата,
Түбән Камам, синең күгеңдә.
Иң беренче салган ташлар да
Һаман әле минем күңелдә.
Татарстан, синең җиреңдә
Тату яши адәм баласы.
Горур булып Кама буенда
Үсә Түбән Кама каласы.

Түбән Камам, синең урамнар
Гүзәл яшеллеккә күмелгән.
Яшәү көче алып яшим мин
Халкым белән синең җиреңнән.
Түбән Камам, синең җиреңдә
Мин дә таптым сөйгән ярымны.
Ак бәхетләр теләп халкыма,
Җырлыйм әле шушы җырымны.

*Басмага **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2022

Ләис Зөлкарнәй шигырьләре

Шагыйрь Ләис Зөлкарнәй. 1988 ел.
Н.Седов фотосы

1891. Казан. Пасха. Пәйгамбәрнең иңүе

Чаң авазы, тәгәрмәчтәй
сикереп, урам ташларыннан
тәгәрәде, тәгәрәде
тарантаслар арасыннан,
тәгәрәде,
Җантимергә карамыйча
тәгәрәде,
таптый-таптый кешеләрне,
мәтәлде ул,
бер сабыйга бәрелеп!

Урамнарга ташып чыкты
карадан киенгән гавам.
Агылдылар
тарантаслар арасыннан,
агылдылар,
Җантимергә карамыйча
агылдылар,
таптый-таптый берсен-берсе,
егылдылар,
бер сабыйга бәрелеп!

Җил өрсә дә ава торган,
җил өрсә дә ава торган,
уйный гына ала торган
бер сабый ул...
Йөргән иде
Ташаяк базарында,
йөргән иде,
уенчык атка кызыга-кызыга
йөргән иде,
көне буе кызыга-кызыга,
ыгы-зыгыда
адашты шул.

Сузылды аңа гавамның
ачлыктан кипкән куллары:
– Иисус! – диде
урыс хатыннары.
– Гайсә! – диде
керәшен агайлары.
– Бала булып иңгән! – диде
чуаш карчыклары.

– Коткар! – диде
суырылган җаннары.

Ә сабый елады бары.
Икона күк тын күзләрен
яшь бөртеге чыкты ярып.
Иисус түгел,
Мөхәммәтвәли малае ул,
Гайсә түгел,
исеме Апуш аның.
Иңмәде ул,
уенчык карарга килде!
Кайтарыгыз,
кайтарыгыз аны өенә!

Ә гавам ышанмады...

1985

Каләмдәшләр-яшьтиләр Уфада очрашты. Алгы рәттә (сулдан уңга): Ркаил Зәйдулла, Фәнис Фәтхи. Арткы рәттә: Ләис Зөлкарнәй, Ләбиб Лерон, Зиннур Хөснияр, Газинур Морат, Мөнир Вафин. 2004 ел

Бәбәкләрем белән янәшә

Тукай тукталышында төшеп калдым.
Бу тәүге һәм соңгы тукталыш.
Тукайдан соң монда язлар сирәк,
Тукайдан соң монда кыш та кыш.

Ак сырынты башы – әләм монда.
Агачларда монда ак зынҗыр.
Бөре эчендәге яшел яфрак –
Иреннәрдә кысылып тынган җыр.

Иреннәрдә кысылып сүрелгән ут...
Дөрләп янар язлар кайда соң?
Көн адашкан,
Бураннарга кереп
Югалткандыр якты кыйбласын.

Кар астыннан күмелеп калган өнме,
Туңып ауган көнме,
Кем дәшә:
«Хакыйкатьтәй йомылып калды бөре
Бәбәкләрем белән янәшә!..»

Тукай тукталышында төшеп калдым.
Һай, сузылды кышлар озакка!
...Кар сулары ага тәнем аша,
Җаным кучә яшел яфракка.

1980

Безнең мирас №4 апрель 2022

Ләис Зөлкарнәй

Җир асты юлы

Татар зиратына тукталыш куярга
Оныттылар бугай...
Курыктылар бугай:
Фатих Әмирханны арба белән этеп,
Юлга кузгалыр, дип,
Яуга кузгалыр, дип,
Телсез калмас Тукай...
Илсез калмас Тукай...

4 апрель, 2015 ел

Мичтәге ут

Япан кырда
янган чаклар
үтте күптән.
Очкынланмыйм.
Очкын алмый инде күптән...
Мичтәге ут
хәлендә мин
инде күптән.
Мичтәге ут хәлендә мин инде күптән!
Үкенимме?
Ялкынымны күрә хәзер якыннарым.
Читтәгеләр – төтенемне...төтенемне...

5 гыйнвар, 2015 ел

Ике дусның студент чагы: Ләис Зөлкарнәй (уңда), Ләбиб Лерон. 1981 ел

«Ләис Зөлкарнәй – өйрәнчек иҗат чорын читләтеп үтеп, туп-туры Олуг Әдәбият мәйданына килеп кергән остазлары Зөлфәт һәм Мөдәррис Әгъләмнәр, яшьтиләре Газинур Морат, Ркаил Зәйдуллалар кавеменнән: ул – яшьтән үк сүз тәмен белеп, беренче карашка гади генә тоелган сүзләрне энҗе-мәрҗәннәр шикелле бер җепкә тезеп, аларга мәгънәви фикер һәм гамь иңдергән, һәр язганын, ашыкмый-каударланмый гына энә күзеннән үткәреп, үзенә генә хас өслүб белән чын шигырь дәрәҗәсенә күтәргән әдип».

Ләбиб Лерон ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, әдипләр, журналистлар һәм сәнгать әһелләре апрель аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

2 апрель – шагыйрь, Башкортстанның Бакалы районындагы Саскүл авылы тумасы **Ләис Мәүлит улы Зөлкарнәй**гә (Харрасовка) 60 яшь (1962);

10 апрель – рәссам, график, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2012), Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исемендәге премиясе лауреаты (2012), Башкортстанның Мәчетле районындагы Яңа Мөслим авылы тумасы **Риат Заһретдин улы Мөхәммәтдинов**ка 70 яшь (1952);

10 апрель – шагыйрә, журналист, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты (2004), Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2012), Татарстанның Буа районындагы Яңа Тинчәле авылы тумасы **Йолдыз Шәрәпова**га (Йолдыз Әдип кызы Шәрәпова-Җамалетдиновага) 60 яшь (1962);

14 апрель – библиография белгече, укытучы, педагогия фәннәре докторы (1994), профессор, Казан шәһәре тумасы **Зөлфия Габдулла кызы Сафиуллина**га 70 яшь (1952);

20 апрель – шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (2012), С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия иясе (2020), Татарстанның Арча районындагы Курса Почмак авылы тумасы **Сания Юныс кызы Әхмәтҗанова**га 60 яшь (1962);

26 апрель – шагыйрь һәм прозаик, Г.-Х.Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы диплом иясе (2006), Ш.Маннур һәм Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Татарстанның атказанган укытучысы (1994), Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (2007), Татарстанның Мамадыш районындагы Кече Кирмән авылы тумасы **Рафаил Шәкүр улы Газизов**ка 75 яшь (1947).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Габдулла Тукай һәм Джей Дагыстанлы

Ләлә Мортазина

Татар-мөселман дөньясының иң абруйлы, затлы һәм кадерле шагыйрьләренең берсе Габдулла Тукай, әдәбият сөючеләрнең генә түгел, тел, дин, милләт төшенчәләре белән бәйле һәркемнең йөрәк түрендә урын алды. Аның тормыш юлы – милләт язмышы, ә иҗаты халык күңеленең көзгесе, бик сизгер кыңгыравы булды. Тукайның вафаты беркемне дә битараф калдырмады, милли фаҗигагә әверелеп, күңелләрне тетрәндерде, йөрәкләрне сыкратты. Шундый зур шагыйрьнең бу дөньядан вакытсыз китеп баруын татар-мөселман дөньясы бик авыр кичерде. Татар вакытлы матбугатында гына түгел, Россиядәге башка бик күп газета һәм журналларда Тукай турындагы истәлекләр басылды. Төрки халыкларның күбесе аны үзенең милли шагыйре дип санады, аның бу дөньядан иртә китүенә чын йөрәктән кайгырды.

Тукайның үлеме бар мөселман дөньясын кузгатты, күпләрне ничек яшәүләре һәм ничек яшәргә кирәклеге турында уйланырга мәҗбүр итте, кешенең, чын иҗатчының

кадерен белергә өйрәтте. Димәк, шагыйрь, тормышы һәм иҗаты белән генә түгел, үзенең үлеме белән дә милләттәшләренә хезмәт итте... Нәкъ үзе теләгәнчә, үзе уйлаганча булды:

«И күк! Ал җанымны, тик, зинһар, алма шөһрәтемне;
Минемчә, онытылу, тибәрелү – үлемнән яманрак.

Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, –
Шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем».

Оригиналда исә тагын да тәэсирлерәк:

«И фәләк! Ал җаными, тик алма, зинһар, шаными;
Бәнчә, үлмәкдин әшәд мәнса вә мәшгулиятем.

Бер заман яд әйләсә бильилтифат милләт бәни, –
Эштә булыр максадым, мәэмүл вә мәсгудиятем».

Тукай вафатыннан соң вакытлы матбугатта дөнья күргән язмалар арасында күренекле җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм тәрҗемәче Джей Дагыстанлының (Гаджибәйленең) Габдулла Тукайның үлеме мөнәсәбәте белән язган мәкаләсе үткенлеге һәм бер үк вакытта җылылыгы белән аерылып тора. Автор Тукайны «йөрәкләрдә ут кабызган» факел белән тиңли. Төрле җирләрдән агылган кайгынамәләрнең, Тукайның үлеменә борчылган кешеләрнең күплеген күреп, бу вакыйганы: *«Беренче тапкыр мөселманнарның үз араларыннан чыккан сәнгать әһелен югалтуга шулай чиксез илтифат күрсәтүләре»,* – дип саный. Шул ук вакытта ул Кавказ мөселманнарының үз уллары вафатына карата шундый ук җылы, шундый ук самими мөнәсәбәт күрсәтә алмауларына сызлана.

Джей Дагыстанлы телләре, диннәре, уй-теләкләре бер булган Идел буе һәм Кавказ мөселманнарын бер кавем итеп күрә, шуңа да аның өчен Тукай – милли шагыйрь, яңа туып килгән, чын зыялылар сыйныфын үстерүгә зур этәргеч биргән олуг шәхесләрнең берсе.

Игътибарыгызга «Каспий» газетасының 1913 елгы 20 апрель санында «Мөселман язмалары» («Заметки мусульманина») сәхифәсендә басылып чыккан мәкаләнең рус теленнән тәрҗемәсен тәкъдим итәбез.

Бер үлем тирәсендә

Джей Дагыстанлы

Идел буе мөселманнарының талантлы шагыйре Габдулла Тукаевның вафатыннан соң ике атнадан артык вакыт үтте. Әмма җирле мөселман газеталарында әле һаман да кайгы белдергән мәкаләләр, Тукайга багышланган искиткеч тәэсирле шигырьләр, илнең төрле өлкәләреннән килгән кайгынамәләр басылып тора. Бу телеграммалар үз милли шагыйрен олылаган, милләтен хөрмәт иткән мөселман кешеләренең йөрәге типкән һәр почмактан – зур үзәк шәһәрләрдән һәм ерак төбәкләрдән, төрле кешеләрдән – зыялылардан, гади кешеләрдән, эшчеләрдән килә.

Милләте өчен җан аткан, милләте өчен үзәге өзелгән, «йөрәкләрдә ут кабызган» шагыйрьнең рухы, аның турындагы хатирә һәркемгә якын-кадерле.

«

Бик югары дәрәҗәдә без Гасан бәк Меликовны соңгы юлга озаттык. Аны чын мәгънәсендә «зиннәтләп» күмдек. Шуның белән мәрхүмнең ядкяре алдындагы бурычыбызны үтәдек дип санадык. Тик безнең җаныбыз авыртмады. Шулай булмаса, без үзебезгә бик күп яхшылыклар кылган мәрхүмне ничек булса да күтәрү, хатирәсен саклау турында уйлар идек.

Гасан бәк Зардаби

Бу югалту мөселман җәмгыяте тарафыннан шулкадәр тирән, киң һәм кайнар кабул ителә ки, аның ихлас күңелдән, чын йөрәктән булуы, чын югалту икәнлеге һич шик тудырмый.

Халыкның үз кайгысын шулай тирән кабул итүе безне, мөселманнарны, күп нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр итә. Без, мөселманнар, үз милли талантыбызны шулай бәялибез икән, мәдәният баскычларына якынаябыз дигән сүз. Җәмгыять тормышына бәйле сигезьеллык эшчәнлегемдә мин беренче тапкыр мөселманнарның үз араларыннан чыккан сәнгать әһелен югалтуга шулай чиксез илтифат күрсәтүләрен күзәтәм. Кавказ мөселманнарының төрле өлкәләрдә үзләренең олпат затларын югалтуларына шаһит булдым, тик аларның бу вакыйгаларга карашлары һич кенә дә бу дәрәҗәдә югары, иң мөһиме – самими булганын күрмәдем. Мондый кайгылы хәбәрләргә рәсми рәвештә, тиеш булганча мөнәсәбәтеңне белдерү бер эш, ә чын йөрәктән кайгыру, аның ни дәрәҗәдә тирәнлеген аңлау, җаның сыкрау – монысы бөтенләй башка хәл. Соңгысын минем күргәнем юк.

Бик югары дәрәҗәдә без Гасан бәк Меликовны[1] соңгы юлга озаттык. Аны чын мәгънәсендә «зиннәтләп» күмдек. Шуның белән мәрхүмнең ядкяре алдындагы бурычыбызны үтәдек дип санадык. Тик безнең җаныбыз авыртмады. Шулай булмаса, без үзебезгә бик күп яхшылыклар кылган мәрхүмне ничек булса да күтәрү, хатирәсен саклау турында уйлар идек. Тере яңгыраш, бәя бирүләр булмады. Аның каберенә таш куярга да жәлләдек...

Үзебезнең мәрхүм шагыйребез, күренекле милли язучы-сатиригыбыз Сабирның[2] әсәрләрен бастырып чыгарыр өчен тиенләп акча җыярга туры килде. Шундый бөек шәхесебезнең үлеме дә бездә әллә ни кызгану тудырмады. Ә бит ул моңа лаек иде...

Халыкның күзаллавын кискен үзгәрткән, гомерләренең иң матур елларын халкына һәм җәмгыятькә багышлаган иң бөек җәмәгать эшлекләләре безне калдырып

[1] Гасан бәк Зардаби (Меликов) (1837-1907) – азәрбайҗан халкының күренекле җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, журналист, азәрбайҗан телендәге беренче газета – «Игенче»не оештыручы.

[2] Сабир (Мирза Алекпер Зейналабдин оглы Таирзадә) (1862-1911) – XX гасыр башының иң күренекле азәрбайҗан шагыйрьләреннән берсе.

Мирза Алекпер
Зейналабдин оглы Таирзадә

> «Идел буе мөселманнары безне, Кавказ мөселманнарын, уздырып киттеләр яки Россия мөселманнары миллилекнең чын мәгънәсен аңлый башладылар, шуңа да аның кадерен белә башладылар.

киттеләр, ә без аларны, рухларын үз яныбызда калдырырга (үз мәнфәгатьләребез өчен!) бернинди гамәл дә кылмадык.

Идел буе мөселманнарына шулкадәр көчле, моңарчы күрелмәгәнчә тәэсир иткән бу кайгы ике нәрсә турында сөйли: Идел буе мөселманнары безне, Кавказ мөселманнарын, уздырып киттеләр яки Россия мөселманнары миллилекнең чын мәгънәсен аңлый башладылар, шуңа да аның кадерен белә башладылар. Бу өлкәдәге югалту аларны бик тирән тетрәндерде.

Мин әлеге күренешкә беренче мәгънәсе ягыннан карамыйм. Бер үк кавемнән һәм диннән булып, уртак уй-фикерләргә, уртак телгә ия булып, бер үк илдә яшәп, без бер-беребезгә төрле халыкларга караган кебек карый алмыйбыз. Шуңа күрә безнең иҗтимагый-сәяси тормышыбыз да уртак булырга тиеш. Бу мәсьәләгә мин гомуми ислам күзлегеннән чыгып карыйм, чөнки Идел буе мөселманнарының тормышында моңа охшаш хәлнең әле күзәтелгәне юк.

> «Ә бездә, ничектер, киресенчә килеп чыга: «зыялы» дигән исемне моңа бернинди дә хакы һәм нигезе булмаганнар ала. Башкачарак әйткәндә, безнең зыялыларыбыз халыкның милли үзаңын үстерү өчен тырышмый, киресенчә, үзенең миллилеккә карата булган мөнәсәбәте белән халыкның кызыксынуы кимүгә сәбәп була.

Шулай итеп, без, Россия мөселманнары, «туган», «милли» төшенчәләренең мәгънәләрен аңлый, нәтиҗәдә, үзебезнең талантларыбызның кадерен белә, аларны тиешенчә бәяли башладык. Бу фикерне киң җәмәгатьчелеккә, халыкка ирештерер вакыт җитте.

Зыялыларыбызның төп максаты – үзләренең белемнәрен, тәҗрибәләрен, аңнарын һәм, ниһаять, «зыялылыкларын» халыкка кертү, аларга да үтеп керүләре өчен тырышу, шулай итеп халыкта «үз», «милли» дигән төшенчәләрне булдыруыбыздан һәм аларга ышынычны арттыру, үз халкына караган һәрбер нәрсә – үткәне һәм хәзергесе белән кызыксыну тудырудан гыйбарәт. Һәр милләтнең зыялылары шуңа омтыла. Ә бездә, ничектер, киресенчә килеп чыга: «зыялы» дигән исемне моңа бернинди дә хакы һәм нигезе булмаганнар ала. Башкачарак әйткәндә, безнең зыялыларыбыз халыкның милли үзаңын үстерү өчен тырышмый, киресенчә, үзенең миллилеккә карата булган мөнәсәбәте белән халыкның кызыксынуы кимүгә сәбәп була.

Моның төп сәбәбе шунда – без үзебезнең туган телебездә тәрбия һәм башлангыч белемне алмаган, үз тарихыбыз, шәригатебез, гореф-гадәтләребез, рухыбыз белән танышмаган хәлдә, «европача» белем алуга омтылабыз. Милли җирлектә әзерлегебез булмау сәбәпле, мәдәниятнең тик тышкы сыйфатларын гына алабыз, «европача» яшәргә тырышып, үзебезнең милли үзенчәлекләребезне, табигатебезне, тышкы кыяфәтебезне югалтабыз.

> **«Без үзебезнең туган телебездә тәрбия һәм башлангыч белемне алмаган, үз тарихыбыз, шәригатебез, гореф-гадәтләребез, рухыбыз белән танышмаган хәлдә, «европача» белем алуга омтылабыз. Милли җирлектә әзерлегебез булмау сәбәпле, мәдәниятнең тик тышкы сыйфатларын гына алабыз, «европача» яшәргә тырышып, үзебезнең милли үзенчәлекләребезне, табигатебезне, тышкы кыяфәтебезне югалтабыз.**

Алыгыз безнең гадәти «зыялы»бызны. Ул туган телен белми, миллилектә бары тик «гадәттән тыш ахмаклык» кына күрә, үз милләтенә өстән карый, аның наданлыгыннан көлә, аңа туган әдәбияты ошамый, чөнки ул аны белми, ул туган телен дә яратмый, чөнки ул тел аны «европалылар» алдында түбәнәйтә; аңа милли көйләре дә ошамый – ул аларны белми, ләкин шулай да, түбән дәрәҗәдә, кыргый, дип бәя бирә; бер үк вакытта ул үзен Европа белән бәйле һәрнәрсәдә белгеч итеп күрсәтергә тели.

Әмма халык, гади халык «үзенеке»н, «миллилек»не күбрәк аңлый, европалылар алдында начар булып күренүдән куркып, миллилегеннән качмый.

Шуңа да Сабир яисә Тукаев кебек милли талант ияләрен югалту, зыялыларга караганда, бигрәк тә халыкны борчый, дулкынландыра. Әле хәзер дә Казан газеталары редакцияләренә килгән телеграммалар, кайгынамәләрне язучылар европача белемле «зыялы»лар түгел, ә халык вәкилләре, чын мәгънәсендә милли зыялылар. Мондый хатларның укучы яшьләрдән күпләп килүе киләчәктә үзебезнең милли зыялыларыбыз тәрбияләнәчәге һәм аларның төп максатлары милләт һәм аның кызыксынулары булачагы турында сөйли.

Саф су агымы торгын суны еракка чәчеп-чәчрәтеп узган кебек, безнең киләчәк зыялыларыбыз да милләтен, телен хөрмәт итмәгән хәзерге «зыялы»ларыбыз дулкынын үзенең көчле агымы белән алып китәр.

«Каспий». – 1913. – 20 апрель. ■

«Манас» – халык ядкяре

Фоат Галимуллин, филология фәннәре докторы



Бер зыялылар мәҗлесендә халык күңелендә саклаган әдәби җәүһәрләр турында сүз барганда, Рабит Батулла кыргызларның «Манас» әсәрен искә алды: аны тугандаш халыкның тарихы да, теле дә, образлы фикерләү байлыгы да тупланган бөек әсәр буларак кадерләвен әйтте. Моның шулай икәнлегеннән биредә утырган Миркасыйм Госманов бик яхшы хәбәрдар дип беләм, дип тә өстәде.

Сөйләшүебезнең төп темасы башка иде. Шуңа күрә Миркасыйм Габделәхәт улы бу турыда сүзне кыска тотты: «Манас» – бик зур әсәр. Аның турында сөйли башласаң, ахырына чыгу кыен булыр. Шунысын гына әйтәм: татар фидакярләре булмаса, «Манас» турында зурдан кубып сөйләшеп утырып булыр идеме икән?! Без әлеге уңайдан татар халкының тугандаш кавемнәргә никадәр ярдәм итеп яшәвен тагын бер тапкыр бөтен тулылыгында күрәбез. Бу турыда махсус сөйләшү таләп ителә».

Шуннан соң мин кыргызларның әлеге атаклы эпосы белән кызыксынып яши башладым. «Манас»ка кагылышлы нинди мәкалә, китап күзгә чалынса да, аны җентекләп карау гадәтемә әверелде. Шул рәвешле шактый мәгълүматлы булдым. Очрашкан

вакытларда бу хакта Миркасыйм Госманов белән дә мәслихәтләшеп алгаларга туры килгәләде. Ниһаять, көннәрдән беркөнне Миркасыйм ага шалтыратты: «Бишкәктә «Манас»ның меңьеллыгын уздыралар икән, чакыру җибәргәннәр. Мин әле күптән түгел генә Кыргызстан башкаласында конференциядә катнашып кайттым, шуңа күрә бара алмыйм. Бәлки, син барырсың?»

Чыннан да, Миркасыйм Госманов, анда барып, «Манас»ның меңьеллыгына багышланган бер конференциядә доклад сөйләргә өлгергән икән (Кара: Манас. – Бишкәк: Кыргыз авыл хуҗалыгы институты нәшрияты, 1995. – Б. 8-13).

Шундый ук чакыру Язучылар союзына да килгән булып чыкты. Ул вакыттагы рәис Ринат Мөхәммәдиев тә миңа анда барырга тәкъдим итте. Мондый җайны күпме эзләсәң дә таба алмас идең. Шагыйрь Ренат Харис белән без бу тантаналарда катнашып, төрки дөнья галимнәре белән аралашып, Кытайдан килгән манасчыларны (әсәрне яттан белүчеләр) күреп, аларның хәтер көченә һәм осталыкларына хәйран калып кайткан идек. Ни өчен Кытайдан, чөнки Кыргызстанның үзендә андый кешеләр калмаган, аларны утызынчы еллардан бирле эзәрлекләү дәвам иткән. Менә хәзер, ягъни халыкның чын тарихын яктырткан әсәрләргә карата караш үзгәргәннән соң, мондый бәйрәмнәр оештыру мөмкинлеге барлыкка килгән. Кыргыз филармониясенең зур залында узган җыенда төп докладны ясаган Чыңгыз Айтматов эпосның кыргыз халкы өчен генә түгел, барлык төрки халыклар өчен дә зур әһәмияте булуын аеруча басым ясап әйтте.

Бу халык эпосы турында сүз барганда, тагын шуны да әйтәсе килә: аны туплауга, өйрәнүгә татарларның гаять зур хезмәте кергән. «Манас» – дөньяда әлегә билгеле булган иң зур күләмле халык авыз иҗаты эпосы. Ун томлык тексты басылып та, әле тулысынча нәшер ителеп бетмәгәнлеген әйтсәк тә, моның шулай икәнлеге аңлашылып тора.

Тикшерүчеләр башта бу әсәрнең кайсы халыкка – кыргызларгамы, казакъларгамы мөнәсәбәтле икәнен өздереп кенә әйтә алмыйлар. Казакъның танылган мәгърифәтчесе Чокан Вәлиханов аның бер өлешен, халыктан язып алып, 1863 елда Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте Хөсәен Фәезхановка җибәрә. Х.Фәезханов бу текстның кыргыз телендә икәнлеген исбат итә. Әсәрнең теле, анда очрый торган сурәтләү чаралары, күп кенә гыйбарәләр ярдәмендә ул шундый нәтиҗәгә килә. Татар галименең дәлилләре шулкадәр көчле була ки, аның белән бәхәскә керә алмыйлар. Шуннан соң бу хакта икеләнүләр бетә. Ул бары тик кыргыз халык иҗаты әсәре булып санала, шулай өйрәнелә башлый. Аны кыргыз халкыннан язып алуда, текстын туплауда, фәнни өйрәнүдә Каюм Мифтахов, Кәлим Рәхмәтулин, Мәдинә Богданова кебек татар галимнәре зур тырышлык куя. Мәдинә Искәндәр кызы соңыннан М.Ломоносов исемендәге Мәскәү университеты профессоры булган галимә. Ул – безнең күренекле әдәбият профессорыбыз Резеда Кадыйр кызы Ганиеваның диссертация язгандагы фәнни җитәкчесе дә булган зат.

Билгеле булганча, 1944 елның 9 август карары белән, КПСС Үзәк Комитеты татарларның тарихи «Идегәй» эпосын, зыянлы әсәр дип табып, кулланылышта йөртүдән тыйды. Бу елларда «Манас» эпосына да шундый ук куркыныч янады. Әмма М.И.Богданова, әлеге әсәрдә фирка идеологиясенә каршы килә торган нәрсәләр юк, дип чыгыш ясады. Гаҗәп хәл, татар галимәсенең бу чыгышын ишеттеләр, игътибарга алдылар, эпосны тыюга кадәр барып җитмәделәр. Әмма аны күңелләрендә йөрткән затларга ул елларның хәтәр җилләре кагылмый калмады. Шулай да «Манас»ның рухы халык күңелендә яшәвен дәвам итте. Татарның бу фидакярләренең исемнәре бүген дә Кыргызстанда менә ни өчен хөрмәт белән искә алына. ■

Безнең мирас №4 апрель 2022

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Йиван Шикай

Кытай дипломатларының берсе һәм иң танылганы – Йиван Шикай исемле бер шәхес – мәмләкәтнең бөтен идарәсен ул елларда үз кулына алырга тора иде. Хәрбиләр дә бу кешене бик яраталар икән. Әгәр Йиван Шикай хөкүмәт идарәсенә кергән булса, Япония белән берләшүне тормышка ашырган да булыр иде. Тик 1908 елда аны вазыйфасын калдырып китәргә мәҗбүр иттеләр. Бу шәхес, хезмәтендә тагын берничә ел гына калган булса да, бик әһәмиятле эшләр башкарган, кытай армиясен үзгәртеп корган булыр иде, дип сөйлиләр.

Ни генә булса да, әлеге шәхеснең әһәмияте кытайлар тарафыннан танылган, сүзенең үтүе бәхәссез иде. Тик бу шәхеснең тоткан юлы һәм сәясәте Аурупа мәнфәгатьләренә каршы төшкәнгә күрә, мәдәни һәм алдан күрүчән аурупалылар, аның исемен оныттырыр өчен, кулларыннан килгәннең барын да эшләделәр.

Тургут оештырган мәҗлес

Тургут дигән такма исемле Балта Тора җәнаплары Пекинда иде. Мин аның хакында 347 биттә[1] язып үткән идем инде. Бу юлы әлеге мөхтәрәм шәхес мин гаҗизнең хөрмәтенә Пекинда бер мәҗлес оештырды. Мәҗлескә дәүләт җитәкчеләреннән һәм мәмләкәтнең алдынгы кешеләреннән кайбер шәхесләр чакырылган иде, бик матур сөйләшү булды.

Ашап-эчкәннән соң, чыгыш ясаулар башланды. Нәтиҗәдә, бу очрашу шактый уңышлы булды. Биредә сүзем тагын шул Кытай мөселманнарының дингә үтә бирелгәнлекләре турында барачак.

Тургутның мәҗлесе турында 19 июль газеталарында язылган иде. Берзаман мөселман кытайлар миңа: «Син ничек алай мәҗүси йортына кунакка барасың?» – дип, ачуларын белдерделәр. «Аларның ризыклары нәҗес», – диделәр.

Тик Тургут җәнаплары мәсьәләнең ул ягын да безнең мөселманнардан алдарак уйлап хәл иткән. Мәҗлес өчен ризык пешерергә Пекинда иң мәшһүр мөселман ашханәсеннән кеше чакырган икән. Бәрәкәт бирсен, иртәгесе көнне – 21 июль – газеталар мәҗлес турындагы язмаларда махсус мөселман ашчы китерелүе турында да яздылар. Шул рәвешле котылып калдык, югыйсә кыямәт кубарган булырлар иде.

Кытайлар

Кытайлар, һичшиксез, гаять изелгән һәм бичара милләт, киләчәкләре-фәләннәре бар, дип күпме генә сөйләнсәк тә, бүгенге көндә болар дөньяда, һиндлардан кала, иң изелгән халык. Пекинда кытайлар хакимлек итә, ханнары – кытай, кытай хөкүмәте бар. Бар, булсыннар да, тик әлегә бары исемнәре генә.

[1] Бу – әсәрнең госманлы-төрек телендә басылган асыл нөсхәсендәге бит саны *(тәрж.иск.)*.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Пекинда аурупалылар өчен махсус мәхәллә барлыгын әйтеп үткән идем инде. Ул мәхәлләнең урам башларында кытай полиция кешеләре тора, җирле халыкка ул урамнардан үтеп йөрергә рөхсәт итмиләр. «Тыелган!» – дип кычкырып кына торалар. Аз гына каршы килеп сүз әйтүче, санламаучы булса, полиция кешесе шунда ук таягын эшкә җигә, теләгәнчә суга-кыйный. Ул урам чит ил кешеләренә бирелгән урам кебек. Сирәк кенә, полиция кешесенең дусы-танышы туры килсә, үтеп китә ала, ләкин, әйткәнемчә, бу – бик сирәк хәл.

Болар бар да үзем күргән нәрсәләр. Элегрәк әле тагын да мескенрәк хәлдә булганнар.

Аурупалы берәр офицер, кытай солдатын күргәндә, тотып аның чәчен, ә кайчак хәтта башын да кискән, аннары үзе шаркылдап көлгән очраклар да булган. Кытайларда чәч киселү белән баш киселү арасында әллә ни аерма юк. Бичара кытайлар бу дәрәҗәдәге мыскыл итүләргә түзеп тора алмаганнар, һәм, нәтиҗәдә, 1900 елгы сугыш чыккан. Әлеге хәлләр сугышның төп сәбәбе булганын күп тапкырлар кытайларның үз авызларыннан, һәр шәһәрдә, хәтта авылларда да ишеттем.

Болар гына түгел, башка бик ачык һәм яшертен хәлләр бар, мин монда кайберләре турында әйтеп үтәргә телим.

[Берәр гаебе булган кешегә] бердәнбер чара итеп миссионерларга мөрәҗәгать итәргә киңәш итәләр. Миссионерлар бу кешене христианлыкка кабул итәргә риза булсалар: «Хәл итәрбез», – диләр, яки: «Карарбыз», – дигән булып, җирле түрәләргә аны тагын да ныграк кысарга кушалар. Аннары икенче, өченче тапкыр мөрәҗәгать иткәндә, бу кешегә ярдәмче кыяфәтендә пәйда булалар да: «Җирле хөкүмәтнең золымыннан, фәлән кешене фәлән җәзадан инглизләрнең гаделлеге коткарып калды», – дип, бу хакта кытай газеталарына яздыралар. Шуңа охшаш чараларның очы-кырые юк.

Мондый нәтиҗәләр инглизләрнең теләк-максатларына хезмәт итәме икәнни соң? Әйе, бу бер сорау гына һәм аның җавабын без Пекинда таба алмаячакбыз. Шулай булуга да карамастан, мин, кара акыл белән дә, инглизләр уңышка ирешәчәк көн бик ерак, дип әйтә алмыйм. Чөнки яхшы уйланылган чараның кылычтан үткенрәк булуын дөнья йөзендәге соңгы тарихи вакыйгалар бик ачык күрсәтеп тора. Моннан соң, Аурупада кылыч явы түгел, сәясәт явы дәвере башланачак, дип әйтергә мөмкин. Бер генә кешегә дә тимиләр, хәтта борынын да канатмыйлар, ә мәмләкәтләрне яулап алалар. (Бернинди сугышсыз гына Болгария мәмләкәте барлыкка килде, кан коюларсыз гына, Герцек-Босна җирләрен Австрия басып алды.)

Бернинди каршылык юк, инглизләр бөтен Кытай хөкүмәтен эчтән басып алачаклар. Аурупалыларга исә хәбәр бәгъдә хараби-л басра [басра җимерелгәннән соң гына] барып ирешәчәк. Моның бик күп дәлилләре бар, шуңа күрә бу рәвешле күзаллый алам. Әйткәннәрем – бер фикер, әлбәттә. Бу яктан японнар да бик тырыша, аларның да форсатны качырасылары килми. Үз мәнфәгатьләре хакына, инглизләр белән хәлләреннән килгәнчә ярышудан һич кенә дә кире тормыйлар.

Ара сүз.

Бераз читкә китү булса да, биредә шуны да әйтеп китәсем килә: җир йөзендә борынгы заманнардан бирле Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында килешмәүчәнлек яшәп килә. Бу яктан караганда, әлеге хәлләрдән шундый нәтиҗә килеп чыга: бөтен Көнчыгыш халыклары Көнбатышка, кылычтан да бигрәк, фикердән җиңелә бара. Бу соңгы елларның сугышлары тулысы белән берәр фикергә багышланган кебек күренә. Бүгенге көндә Көнбатышның сугыш кораллары да, чынбарлыкта, сугыш өчен түгел, бәлки, үз фикерләрен куәтләү һәм каршы төшкән фикерләргә дәхшәт бирү чарасы гына булып тора.

Көнбатыш сәясәтен күзәтеп баручылар һәм Көнчыгыш халыкларының җиңелү сәбәпләрен тикшерүчеләр, тагын да киңрәк уй йөрткәндә, минем бу фикерләремне игътибарга алырлар дип өметләнәм. Әлеге фикерләремне хәтта бераз тирәнәйтәсем дә килә: әгәр, берәр могҗиза сәбәпле яки өйрәнү-тикшеренү нәтиҗәсендә, Көнчыгыштагы Япон мәдәнилеге Көнбатышка көндәшлек күрсәтә алмаса, бик тиздән, Ерак Көнчыгыш та, Якын Көнчыгыш та Көнбатыш мәдәнилеге алдында коточкыч җиңелүгә дучар булачак. Бәлки, Аллаһ кушып, Көнчыгыш берләшә дә алыр, тик әле тиз генә булмас. Шулай итеп, бүгенге Көнчыгышның фикри артта калганлыгы Көнбатышның татлы хыялларын бик нык арттыра.

Шул рәвешле инглизләр Кытайга юнәлдерелгән максатларын бермә-бер арттырачаклар, бу һич тә шик тудырмый. Ләкин шул ук вакытта, әгәр безнең мөселманнар, мөселманлык фикереннән чыгып, үз кемлекләре турында мәгълүматларын арттырсалар, ислам фәлсәфәсен хуплап, яшәү мәгънәсен дә тиешенчә аңлап, бөтен Көнчыгыш өчен юл күрсәтүче була алсалар, ул вакыт, һичшиксез, Көнбатышның бөтен бу гамәлләре төбе-тамыры белән юкка чыгачак һәм чын мәдәнилек бар җиһанны яктыртачак.

Бу исә, минем гаҗиз фикеремә күрә, шул ике юл белән чынга ашарга мөмкин: берсе һәм беренчесе – ислам галәмәсенең фикерләрен дин белгече кыяфәте чыгарып йөрүче кайберәүләрнең әсирлегеннән коткару; икенчесе – фикһ дип укытыла торган бөтен китапларга шәригать белгечләренең сүзе итеп караудан үзебезне коткару.

Ихтимал, әйтергә теләгәннәремне әйтеп тә бетерә алмыймдыр. Үзем дә шуны уйлыйм. Башкача әйтсәк, уем шәригать белгечләрен шелтәләү түгел, киресенчә, шәригатьчеләребез тоткан юлны төзекләндерү, ныгыту.

Шуңа күрә кабатлап әйтәм: фикеремне төгәл итеп җиткерерлек сүзләр таба алмаганга, биредә шулай, булдыра алган кадәр, аңлатып карарга мәҗбүрмен. Мин әйткән сүзләр бик хаталы булып тоелмас дип уйлыйм. Бигрәк тә бүгенге көндә безнең голәмәбездәге карарсызлык игътибарга алынса, бу хәл минем ул сүзләремне тагын бер кат куәтләр.

Безнең заманның голәмәсе – дөньяның, белмим кайсы төше булып күренгән Җамалетдиннар, Абдуһлар, Нәдимнәр – һичшиксез, шул әсирлекнең корбаннары һәм болар тайпылырга мәҗбүр булдылар. Тагын да ачыграк итеп әйтсәк, бүгенге чалмалыларның – күбесенең – Көнбатыш фәлсәфәсе алдында җиңелеп, чигенергә мәҗбүр булулары, тагын да шул ук фикерләргә әсир төшүләре, ислам фәлсәфәсеннән мәхрүм калган булулары аркасында килеп чыкты. Бүген без голәмә итеп кабул иткән Аллаһ колларының һичбере ислам бөекләренең тәрҗемәи хәлләрен дә хәтта тәртибе белән белми. Кайдан килеп фәлсәфәләреннән хәбәрдар булсыннар ди инде?!

Бүген Көнбатыш философларының бөекләре – безнең иң вак, иң гади мотасауыйфларыбызның[2] гашыйклары.

Бу бичаралар суфыйларыбызның бөекләреннән бөтенләй хәбәрдар түгел. Аһ, йа Рабби, пәйгамбәрләрнең хәдисләрендәге фәлсәфәне тиешенчә шәрехләп аңлатсак, безнең каршыбызга кем чыга алсын?!

Аһ, шул ике төрле әсирлек! Мәүла безнең еракларны күрер күзләребезне ачсын!

---

[2] Мотасауыйфлар – тасауыф әһелләре, суфыйлар; Хак Тәгалә өчен бөтен мәшәкать һәм богаулардан азат булып, ихлас күңел белән Хакка гыйбадәт кылучылар *(тәрҗ.иск.)*.

Кытайларның чәчләре

Кытайларның чәчләрен озын итеп үстереп йөртүләре алай бик борынгы заманнардан килгән гадәт түгел икән. Маньчжурия хакимлегенә буйсыну галәмәте буларак, моннан 200 еллар элек хөкүмәт бу хакта рәсми тәкъдим белән чыккан да, озын чәч тора-бара гадәт булып киткән. Соңга таба инануга ук әйләнгән. Бүгенге көндә кытайларда чәчен пәке белән кырдырып, уртадан бер тотам чәчне хатыннар кебек үреп салып йөртү фарыз дәрәҗәсенә куелган. Бөтен Кытай илендә чәч мәсьәләсе үтә мөһим мәсьәлә булып тора. Хәзер хөкүмәт бу гадәтне бетерергә тели, ләкин милләт мөмкинлек бирми. Кытай хөкүмәте гаскәриләрнең чәчен кистерү турында катгый карар чыгарса да, гаскәриләр һич кенә дә кабул итмиләр. Бөтен Кытайда чәч – изге нәрсә, чәч кисү хәтта баш кисүгә тиңләштерелә. Кайчакларда, бик авыр җәза итеп, гаепленең чәчен кисәләр икән. Кытай кешесе өчен, чәче киселү үлем белән бер.

Алманнар, ягъни немецлар, Вай-Хай-Вайны бүлеп алгач, үз боерыклары астына кергән кытайларны, башка кытайлардан аерырга мөмкин булсын өчен, чәчләрен кисәргә мәҗбүр иткәннәр. Шунда, чәчләре киселгәндә, болар үксеп-үксеп елыйлар икән.

Тонкин якларында французлар да нәкъ шулай үзләренә буйсынганнарның чәчләрен кистергәннәр. Алар да елаган. Чәч дини фарызлары дәрәҗәсенә җитә язгач, бичара кытайлар нишләсеннәр инде?!.

Пекинда яшәгәндә, голәмәдән олы яшьтәге бер кеше белән күрешкән идем һәм шулвакыт, очраклы рәвештә, чәч турында сүз чыккан иде. Мин бик күп хәдисләр һәм исламның данлыклы әхлагы турында сөйләгәннән соң: «Мөселманнарга һәм бигрәк тә сезнең кебек гомеренең соңгы чорындагыларга үзен сөннәт-и сәнийәгә[3] туры килә торганча тотарга кирәк», – дигән сүзләр әйтеп, чәчен бөтенләй кырдырырга киңәш иттем, хәтта: «Үзем кырыйм, әйдә», – дип тәкъдим иттем.

Картның яше, иң аз дигәндә, 70ләр тирәсендә бардыр, чәче дә тычкан койрыгы кадәр генә калган иде. Миннән ул сүзләрне ишетүе булды, йөзе агарынды, минем янымда утыра алмады, ниндидер бер сылтау табып чыгып качты. Аның белән башка күрешергә насыйп булмады.

Чәчкә кагылышлы моның кебек бик күп хәлләр булды. Барысы турында да язып булмый, бераз уңайсыз, шуңа күрә болар белән генә чикләнәм.

Пекинда яшәгәндә Токио белән хәбәрләшү

Пекинда яшәгәндә Мөхәммәт Бәрәкәтуллаһ әфәндедән бер хат алдым. Шуның эчтәлеген китереп үтәм. Аллаһыга мактау һәм безгә ихтирам сүзләреннән соң, ул болай дигән:

«Сезнең Сеулдан язган хатыгызны алдым, тугры юл хакына тырышуыгызга бик шатландым. Мондый хатларыгызга һәрдаим мохтаҗмын. Мәчет хакында әлегә катгый карар кабул ителмәде. Кардәшебез Хонҗи Истанбулга бару фикерендә, сездән хәбәр көтә...»

Һәм башка шундыйлар...

Аз сүзле, бай эчтәлекле хат иде ул, тик асыл нөсхәсе ничектер югалган.

Мин Пекиннан, җавап итеп, менә шундый хат яздым:

---

[3] Сөннәт-и сәнийә – Хәзрәте Пәйгамбәрнең (с.г.в.) сүзләре, әмерләре һәм үз-үзен тотышы белән бәйле хәлләр *(тәрҗ.иск.)*.

«Әлхәмдүлилләһи раббил галәмин.

Кадерле кардәшем Мөхәммәт Бәрәкәтуллаһ Сахиб (Аллаһ сәламәтлек бирсен һәм сакласын)!

Үткән айның 15ендә җибәргән хатыгызны зур дәрәҗә санап алдым һәм бик сөендем. Инандым ки, Сез – бөек зат, бөтен гайрәтегез белән хезмәт куясыз һәм мине шатландырасыз. Йөрәкләргә шифалы, ләкин четерекле эшләргә тулы җаваплар биреп, бераз вакыт узганнан соң булса да, аларны җиренә җиткереп үти аласыз. Игелегегез бәрәкәте белән Аллаһы безләргә илаһи мәгърифәтләр һәм Мөхәммәди мәдәнилеге насыйп итсен.

Хатыгыз килгәннән берничә көн элек, мин дустыбыз Охарага хат язып салган идем. Сез дә Баманы хәбәрдар иткәнсез, ахры. Мин аңа кайбер эшләрне тизләтергә кушып хат язган идем. Аллаһы Тәгаләнең яшерен серләрендә билгеле кылган нәрсәләренә безләрне ирештерүен өмет итәм.

Өметем шул: Сез – бөек зат, теләкләребез күгендәге кайгы болытларын таратып, алдан күрүчәнлегегез белән чит-ятларның пәрдәләрен телгәләрсез. Кыйммәтле дустым! Сиңа бөтен самимилегем белән эндәшәм: син, үзеңдәге хәерхаһлык белән, без сүз куешкан шәхесләрнең йөрәкләрен сафландырырсың, күңелләрен шик-шөбһәдән арындырырсың һәм син анданиләр барлыгын яхшырак беләсең.

Мин гаҗизгә килсәк, Пекинда яшәп ятам. Кайбер мәшһүр шәһәрләрен гизеп күрдем. Дәүләт эшләрен һәм җәмгыятьнең рухын яхшы белүче бик күп кеше белән күрешеп сөйләштем. Кытайларның хәлләрен көчем җиткән һәм мөмкинлегем булган кадәр күзәтүемне дәвам итәм.

Алар, мәсьәләләрен чишәргә тырышу, ялыктыргыч хезмәтләр башкару, уңышка илтә торган юллар эзләү белән шөгыльләнсәләр дә, әлегә тиешле дәрәҗәгә ирешүдән бик ерак торалар. Ник дигәндә, чит милләтләр аларга бөтен көчләре белән ябышканнар. Гаскәри көчләре җитәрлек түгел, 250-300 меңнән артмас. Яхшылап коралланыр өчен, акча бүленү тәртибен төзәтергә кирәк. Хөкүмәт казнасы бик начар хәлдә. Шул сәбәпле, үзләрен америкалылар белән килешү төзү һәм чит ил кешеләренә өстенлекләр бирү кебек төпсез чокырларга аталар. Әле һаман борчу, азап һәм чарасызлык эчендә кайныйлар.

Икенче яктан, Лакнау мөселманнары белән дә күрештек. Алман илчелегендә әһәмиятле урыннар биләүче бу кардәшләребез – Кытай белән бәйле киң мәгълүматка ия кешеләр һәм алар безгә кытайларның кайбер серләрен дә ачарга әзер. Мин тиздән Ханкавга китәм. Истанбулдан хатлар, газеталар алдым. Ул якларның хәбәрләре бик сөендерә. Бигрәк тә әфәндебез солтан Мәхмәт Vнең хәлләре бик яхшы. Ил эчендә күп йөри, базарларга бара, кайбер кешеләр белән күрешеп сөйләшә, имтиханнар вакытында мәктәпләрне барып күрә икән.

Сез, бөек зат та, иншәАллаһ, бик саклык белән, йомшак сүзләр һәм төгәл чаралар кулланып, бөтен гайрәтегез белән хезмәт итәсездер.

Исәнлек һәм уңышларыгызның дәвамлы булуын телим.

Габдерәшит Ибраһим.
Пекин»[4]

[4] Әсәрнең Истанбулда госманлы-төрек телендә басылган төп басмасында әлеге хат гарәп телендә бирелгән. Хатны татарчага тәрҗемә итү өчен, без Әртугрул Өзалпның әсәрне бүгенге төрек теленә якынайтып бастырган китабындагы тәрҗемәдән файдаландык. Биредә хатның гарәп телендәге язмасының рәсемен дә бирәбез *(тәрҗ.иск.)*.

Мин шул рәвешле, хатлар аша булса да, японнар белән бәйләнештә тордым. Бөтен уем анда корылган нигезне ныгытуга юнәлгән һәм бу минем иң изге вазыйфам иде. Бәрәкәтуллаһ әфәнде белән генә түгел, Охара, Накано, Накайама белән дә хат язышa идем. Минем Кытайдагы тормышым, японнарның яхшы мөгамәләсен казанып, сәясәтемне ул яклап тәэмин итү һәм японнарны мөмкин булган кадәр кулдан ычкындырмауга багышланган иде. Менә шул максатка нигезләнеп, Мөхәммәт Бәрәкәтуллаһ әфәндегә мондый хатлар язып, үгет-нәсихәтләр бирә идем. ■



الحمدلله وحده .

الی جناب الاخ المکرم محمد برکت‌الله صاحب سلمه‌الله وصانه .

قد تشرفت باستلام کتابکم المؤرخ بالخامسة عشرة من الشهر الغائت وصرت ، مسرورا فی غاية السرور . وايقنت ان حضرتکم تجهدون بکل جد واجتهاد وتسرونی بعد حين باجوبة شافية للصدور وکافية فی الامور ، واورثنا الله تعالی من برکت فضلکم المعارف الالهية والمدنية المحمدية .

ثم انی قد کتبت الی صديقنا اوحارا قبل وصول کتابکم الی بايام ولابدان حضرتکم اطلعتم باما کتبت له من تعجيل بعض الامور عسی الله ان يوفقنا بما قدر فی مکنون غيبه.

فالمأمول ان حضرتکم ستکشفون عن سماء المطلب سحب الاکدار وتمزقون عن بصيرة حجب الاغيار واخلصت الوجهة اليك يا اخی وانت تنزه قلوب من کنا نعدهم من الاحرار بحکم فضلك وتهذب صدورهم عن ريب المنون وانت ادری لما هنالك .

واما العاجز مقيم فی پکين ودرت بعض البلدان المعروفة عندهم واجتمعت مع کثير من الذين لهم حظ وافر فی امور الدولة وروح الملة ولا زلت اترصد عن احوال الصينين بقدر الوسع والامکان .

ولو انهم بحل المشکلات والمتاعب قائمين وعلی سبيل النجاح سالکين ولکنهم بمعزل عن الوصول الی درجة المطلوب لان الاجانب تسلطت عليهم بکل السلطة وقواهم العسکرية ليست بکاف لايزيد عن مأتين وخمسين الف اوثلاثمأته الاف. واصلاح الاسلحة والاساطيل يحتاج الی اصلاح المالية وهی فی سؤ حال وبذلك يرمون انفسهم الی هوت المهالك من قبول الوفاق مع الامريقانيين واعطاء الامتيازات الی الاجانب ولا يزالون يترددون فی قلق واضطراب .

ثم انی اجتمعت مع اخواننا المسلمين من اهل لکنو وهم يشيغلون مقاما مهما فی سفارة جرمان وهؤلاء اخواننا مستعدين لکشف النقاب علينا عن بعض الاسرار ومختبرين من احوال الصنيين بکل اختبار .

وعما قريب اسافر من ههنا الی خانکاو . واستلمت من الاستانة العليه المکاتب والجرائد واخبار تلك لديار مسرة جدا وبالخاصة حال مولانا السلطان محمد خامس وهو سيوح فی داخل مملکته ويمشی فی الاسواق ويجتمع مع افراد الناس ويحضر وقت الامتحان فی المدارس .

وحضرتکم انشاءالله تعالی تبذلون الجهد بکل احتياط واقوال لينة وتدابير صائبة ،

دمتم سالمين غانمين عبدالرشيد ابراهيم

پکين

Габдерәшит Ибраһимовның Пекиннан Токиога гарәп телендә язган хаты. Хат сәяхәтнамәнең госманлы-төрек телендә Истанбулда чыккан басмасыннан алынды.

Ислам. Дини сүзлек

Азан

Мәзин азан әйткән вакыт

Азан, азан әйтү (гарәпчә – игълан итү, чакыру) – мөселманнар өчен фарыз саналган биш вакыт намазның һәркайсының башлану вакытын һәм намазга чакыруны белдерә. Азанны мәзин (гар. – азан әйтүче) әйтә. Дүрт мәртәбә «Аллааһу әкбәр» дип кабатларга кирәк. Тәрҗемәсе шуннан гыйбарәт: «Аллаһ бөек» яки «Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәдән олуграктыр».

Ике мәртәбә: «Әшһәду әлЛә иләһә илләллаһ» – «Бер Аллаһы Тәгаләдән башка һич илаһ юктыр» яки «Аллаһтан башка илаһ юк, дип шаһитлык кылам».

Ике мәртәбә: «Әшһәду әннә Мөхәммәдүр рәсүлуллааһ» – «Мөхәммәд Аллаһның рәсүле, дип шаһитлык кылам».

Ике мәртәбә: «Хәййә галәс саләәһ» – «Намазга ашыгыгыз» яки «Намазга басыгыз».

Ике мәртәбә: «Хәййә галәл-фәләәх» – «Газаптан котылырга ашыгыгыз» яки «Уңышка ирешерсез».

Ике мәртәбә: «Аллааһу әкбәр» – «Аллаһ бөек».

Ике мәртәбә: «Ләәә иләәһә илләллааһ» – «Аллаһтан башка илаһ юк».

(Иртәнге намаз алдыннан шушы сүзләрдән соң «Әс-салату хайрум минән-нәүм» – «Намаз йокыдан хәерлерәк» дигән җөмлә дә өстәлә.)

Азан – намазга беренче чакыру. Намаз укырга керешер алдыннан мәзин камәт (гар. – аякка бастыру) әйтә, монысы икенче чакыру була. Камәт азан кебек, тик камәт әйткәндә «Газаптан котылырга ашыгыгыз» дигән җөмләдән соң, «Намаз укыла башлады» дигән сүзләр өстәлә һәм камәт азанга караганда тизрәк әйтелә.

Сөнниләр камәтне – бер тапкыр, ә шигыйләр ике мәртәбә әйтә.

Өйдә яки ачык һавада ялгыз гына намаз укыганда камәт әйтелми. Намазны җәмәгать белән уку саваплырак.

Шәригать буенча азан һәм камәт әйтү фарыз түгел, ә сөннәт гамәл санала.

«Ислам. Белешмә-сүзлек» китабыннан (1993, Татарстан китап нәшрияты) алынды. ■

Безнен мирас №4 апрель 2022

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре[1]

Әхмәдвәли Рәхими

25

Әбу һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Намазында тәһарәте бозылган кешенең, тәһарәтле булганчы, намазы кабул булмас».

Укы һәм исеңдә калдыр!

26

Ибн Гомәр разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Хәрам малдан сәдака кабул булмаган кебек, пакьлектән (тәһарәттән) башка намаз да кабул булмас».

Укы һәм исеңдә калдыр!

27

Әбу һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Тәһарәт вәсвәсә белән генә тиеш булмас, мәгәр тавыш яки арттан җил чыгу булмаса».

Укы һәм исеңдә калдыр!

28

Гали разыйаллаһу ганһү риваять итә: «Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәлламнән мәзи турында сорадым». Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйтте: «Мәзи[2] бүленеп чыкса, тәһарәт алу тиешле, мәни[3] чыкса, госел алу тиешле».

Укы һәм исеңдә калдыр!

29

Гали (Аллаһ аны хөрмәтләсен), риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Кырын ятып яки сузылып ятып йоклаучы адәм тәһарәт алсын».

Укы һәм исеңдә калдыр!

30

Әбу Әюб әл-Әнсари разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Хаҗәтханәгә керсәгез, кыйблага каршы йә арка ягы белән булмагыз, бәлки, кояш чыгыш йә батыш тарафына булыгыз».

Текстны басмага ***Айсылу Вәлиева*** *әзерләде.* ■

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

[1] Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

[2] Мәзи – җенес әгъзасыннан ихтыярсыз чыга торган төссез сыеклык.

[3] Мәни – нәсел орлыгы.

Безнең мирас №4 апрель 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Унынчы дәрес

Ибраһим пәйгамбәрнең (г.с.) килүе. Мөшрикләр тарафыннан аның утка атылуы. Утның тәэсирсез калуы. Исмәгыйльне корбан кылу. Хәзрәти Ибраһимга фәрештәләр килүе

Мөгаллим: Адәм пәйгамбәрдән (г.с.) соң озак вакытлар үтеп, байтак пәйгамбәрләр килеп-китеп торган. Халык исә һаман юлдан адашкан. Бервакыт, халык шулай юлдан бик адашкан чакта, боларга Аллаһы Тәгалә Ибраһим исемле бер пәйгамбәр (г.с.) җибәргән. Бу вакытта халыклар кояш, ай, йолдызларны тәңре дип таный башлаганнар, потларга табына торган булганнар. Ибраһимның атасы да потка табынучы булган.

Аллаһы Тәгаләнең кушуы белән, Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) аларны тугры юлга өнди башлаган, тик алар аңа ышанмаганнар. Атасы да аңа каршы килгән. Ләкин Ибраһим пәйгамбәр (г.с.), аларның карышуларына карамыйча, һаман үз юлын дәвам иткән. Аларның яман юлда булуларын, әллә нинди юк-бар нәрсәләрне Аллаһ дип тануларын гаепләгән. Ахырда Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) аларның кәефләрен бик җибәрә башлагач, аны үтерергә киңәш кылганнар. Аны утка атмакчы булганнар. Ибраһим пәйгамбәр (г.с.), моңа бер дә илтифат итмичә, һаман үз юлын дәвам иткән. Ниһаять, алар аны бер җирдә ут ягып, шунда атканнар. Ләкин, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, ут салкынайган – Ибраһим пәйгамбәргә (г.с.) һичбер зарар тимәгән. Без бит әүвәл дә: «Аллаһы Тәгаләнең һәрнәрсәгә көче җитә», – дип әйткән идек. Шулай түгелме?

Шәкерт: Шулай, Аллаһы Тәгаләнең һәрнәрсәгә көче җитә.

Мөгаллим: Әлбәттә, көче җитә. Аның утны салкын итәргә дә көче җитә. Менә үзенең пәйгамбәрен Ул үзенә ышанмаган, иман китермәгән көферләрнең мәкерләреннән саклап калдырган. Аңа утның зарарын тидермәгән. Шуннан соң халык Ибраһим пәйгамбәргә (г.с.) каршы бер эш тә кыла алмаган. Ул, аннан соң тагы да иркенрәк сулыш алып, үз эшен дәвам иткән. Аннан соң инде Ибраһим пәйгамбәргә (г.с.) ияргән кешеләр дә күбәйгән.

Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) ул бик олуг пәйгамбәр булган. Аның нәселеннән дә бик күп пәйгамбәрләр килгән. Ибраһим пәйгамбәрнең (г.с.) нәселе бик мөбарәк булган. Аның атасы яхшы кеше идеме, әллә яманмы?

Шәкерт: Ул яман кеше булган, потларга гыйбадәт кылган.

Мөгаллим: Шулай булган шул. Ә Ибраһим атасының киресе – бик тә яхшы, бик тә изге, халыкка гаять дәрәҗәдә миһербанлы булган. Аның Аллаһы Тәгаләгә итагате дә иксез-чиксез. Шуның өчен дә ул бик зур мәртәбәләргә ирешкән. Ибраһим пәйгамбәрнең (г.с.) ике улы булган: Исмәгыйль һәм Исхак. Исмәгыйль – Һаҗәр исемле, ә Исхак Сара исемле хатыныннан туган.

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

Мин сезгә Ибраһим пәйгамбәребезнең (г.с.) Аллаһы Тәгаләгә итагате иксез-чиксез булган дигән идем. Бу турыда сезгә бер вакыйга сөйлим. Бервакыт Ибраһим (г.с.) бер төш күрә. Төшендә гүя ул улы Исмәгыйльне корбан кыла. Шуннан соң ул бу турыда Аллаһы Тәгаләдән үзенә әмер булганлыгын аңлый һәм улына шул хакта әйтә. Улы Исмәгыйль: «Аллаһы кушкан эшкә мин әзер, баш өсте», – дип, моны кабул итә. Шуннан соң Ибраһим (г.с.) улы Исмәгыйльне бер җиргә алып барып яткыра да, кулындагы пычагы белән корбан кылырга әзерләнә, әмма пычак кисми. Шул арада Аллаһы Тәгаләдән: «И-и, Ибраһим, тукта, синең итагатьлелегеңне белдек инде!» – дигән тавыш килә. Шуннан аңа корбан рәвешендә сарык килә. Аллаһы Тәгаләнең аңа улын корбан кылырга кушуы аны сынау өчен булган икән. Ә Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) «ләм-мим» димичә, Аның боерыгын кабул иткән. Исмәгыйль дә: «Баш өсте», – дип, моңа риза булган. Йә, белдегезме инде Ибраһим пәйгамбәрнең (г.с.) Аллаһы Тәгаләгә ни дәрәҗәдә итагатьле булганлыгын?

Шәкерт: Белдек, мөгаллим әфәнде, белдек, бик итагатьле булган.

Мөгаллим: Әлбәттә, бик итагатьле. Үзенең күз нуры булган баласын корбан кылудан да артык итагать булырмы?! Менә шуның өчен дә Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) үзе дә, улы да бик зур мәртәбәгә ирешкән: Ибраһим пәйгамбәр бик олуг пәйгамбәр булган, Исмәгыйльгә дә пәйгамбәр вазыйфасы йөкләнгән. Аның нәселеннән пәйгамбәрләрнең ахыргысы һәм иң дәрәҗәлесе булып безнең пәйгамбәребез Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вәссәлам) дөньяга килгән. Бу бит, балалар, бик зур шәрәф, бик зур дәрәҗә.

Шәкерт: Әлбәттә, зур дәрәҗә.

Мөгаллим: Ибраһим пәйгамбәребезнең тагы бер вакыйгасын сөйлим әле. Мин сезгә аның Һәҗәр исемле хатыныннан Исмәгыйль пәйгамбәрнең (г.с.) дөньяга килгәнен сөйләгән идем. Бу вакыт инде Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) карт кеше булган. Карт була торып, Һаҗәрнең үзеннән бала табуына бик зур шөкерана кылган. Аның өлкән хатыны Сара да бик карт булган. Ул да баласы булмаганга көенгән. Ләкин яше зур булганлыктан, балага өметен өзгән. Бервакыт Ибраһим пәйгамбәргә (г.с.) берничә мосафир килеп төшкән. Болар аңа бер дә таныш кешегә охшамаганнар. Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) бик кунак сыйлаучан, юмарт булган. Кунаклар таныш булмасалар да, шунда ук аларга аш әзерләткән. Тегеләр ашны ашамаганнар. Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) кыстаган. Болар һаман да ашамаганнар. Аннан соң ул болардан шикләнә башлаган: «Болар кемнәр икән, юл кешеләре була торып ашамыйлар?» – дигән. Ә алар, Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) уйлаганча, гади юлчылар түгел, фәрештәләр икән. Алар аңа юлдан язган, явызлыкка, начар эшкә бик бирелгән бер кавемне һәлак кылырга барышлый сугылганнар икән. Тик аңа кеше сурәтендә күренгәннәр. Мин сезгә: «Фәрештәләр безнең кебек гәүдәле түгелләр, ләкин бәгъзе вакыт төрле сурәткә дә керә алалар», – дип әйткән идем, шулай бит?

Шәкерт: Шулай, хәлфә, әйткән идегез.

Мөгаллим: Менә болар да кеше сурәтенә кергән фәрештәләр булган. Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) шикләнә башлагач, болар аңа серне ачканнар. Әнә шулвакыт болар, хәзрәти Сарадан бер ир бала туар, дип, аңа сөенеч биргәннәр. Хәзрәти Сара да шулвакыт аяк өсте басып тора икән. Ул бик аптыраган: «Мин бит инде бик карт карчык, ирем дә карт, ничек бездән бала булсын, бу бик гаҗәп эш?!» – дигән. Фәрештәләр: «Аллаһы Тәгаләнең эшенә бер дә гаҗәпләнергә ярамый, сезгә аның рәхмәте бик зур. Аның һәрнәрсәгә көче җитә», – дигәннәр. Шулай итеп, хәзрәти Сарадан бер ир бала туган. Моңа Исхак дип исем биргәннәр. Хәзрәти Исхактан бик изге балалар дөньяга килгән. Аның нәселеннән бик күп пәйгамбәрләр чыккан. Аның улы Ягъкуб пәйгамбәр (г.с.) булган. Аңардан да пәйгамбәр туган. Ягъкубның икенче исеме – Исраил. Шунлыктан Ягъкуб пәйгамбәрдән (г.с.) туган кешеләргә вә аның нәселенә (яһүдләргә), бәни Исраил кавеме, диләр.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

Шахмайның йөзек кашы

Илдус Диндаров

Мирхәйдәр Фәйзинең яшүсмер чагы

Атаклы драматург Мирхәйдәр Фәйзидәй Татарстанны шулкадәр өзелеп яратып та, ни өчендер монда торып эшләү мөмкинлеге таба алмаган, гомере буе чит җирләрдә аны сагынудан саргаеп яшәгән, азакта ят почмакта каңгырып вафат булган башка бүтән әдип бармы икән татар әдәбиятында?!. Соңгы тапкыр Казаннан бәхилләшеп киткәч, көндәлегенә: «Бөтен бәхетем, күңелем бу якта кала!» – дип, әнә ничекләр йөрәк каны белән, сыкранып-әрнеп язган ул. Югыйсә аның

бертуган апа-абыйларының, кан-кардәшләренең күбесенә шушы изге җирдә – татарларның тарихи Ватанында гомер кичерергә насыйп булган. Башыма сыймый: шул рәвешле бөтен җаны-каны тарткач, газиз туган-тумача янына сыенып төпләнергә, чөкердәшеп яшәргә, иҗат итәргә бер-бер җае чыкмадымы икәнни?!. Күз күрмәгән-белмәгән чит-ят төбәк түгел ләбаса! Әйтик, хәзерге Балтач районының Шода авылында олы абыйсы Сәетгәрәйнең 1902 елдан башлап мулла булып торганлыгы мәгълүм. Әнисе Зәйнәп тә тамырлары белән Казан шәһәренә мөнәсәбәтле.

Элек Чистай өязенә кергән, хәзер Яңа Чишмә районындагы Шахмай авылы бөтенләй үк төп ата-бабалар җире булган ич Мирхәйдәр өчен. Биредә аның бабасы Әхмәтҗан Фәйзулла улы 200 еллап элек нигез корган ике катлы таш йорт әле дә булса мәгъруранә тора бирә. Шунда Мирхәйдәрнең атасы Мостафа туып-үскән, нәкъ шушыннан егерменче яшендә «бәхет эзләп», данлыклы язучы туачак Орски якларына китеп барган, туган ягын онытмыйча, кайткалап торган.

Мирхәйдәр үзе дә истәлекле, җанга якын бу йортны – әтисе өен, һичшиксез, һәрвакыт күңел түрендә йөрткәндер... Әдип иҗатына гашыйк һәркем өчен дә кадерле бу һәйкәл-йорт. Менә хәзер дә әлеге бинаның шомарып беткән агач култыксаларына тотынып икенче катка күтәрелгәндә, дулкынлануыңны көчкә тыясың. Аның баскычларына хәтле әдипнең җылы аяк эзләрен үзенә сеңдереп калган бит. Сәяси гарасатларда, түнтәрелешләрдә борынгы бинаны элегрәк ничек булган – шул хәлендә диярлек саклап калган Шахмай халкына рәхмәт сүзләре дә уяна күңел түрендә. Әлбәттә, Октябрь инкыйлабыннан соң, бу йорт фәлән язучы ядкяре, дип әллә ни мөкиббән китеп карамаган авыл халкы, аны ниндидер әһәмиятле

Музей-йорт

тарихи, мәдәният, архитектура корылмасы итеп тә санамагандыр ул чакта. Шахмайлар өчен ул барыннан битәр иясе каядыр качып киткән «байлар утары» гына булган... Һәм, билгеле, тирә-юньдә тиңе юк, яңа тормыш төзү өчен кулланышка бик ярап торган таза-нык, матур бина гына була бу йорт алар өчен! Илле ел буена мәктәп укучылары белем эстәгән аның бүлмәләрендә. Соңрак ул кырык ел буе балалар бакчасы булып та торган. Беренче катын шактый еллар Авыл Советы әһелләре дә «хакимият кантурасы» буларак үз иткән. Ниһаять, туптан атып та җимерә алмаслык әлеге ташпулатта 2015 елда музей ачыла, ягъни милләтебезгә хезмәт итә торган мәдәни мирас ядкяре итеп танылa.

М.Фәйзинең әтисе Мостафа белән әнисе Зәйнәп

Үзегез дә аңлыйсыздыр, биредә Мостафа аганың һәм аның варисларының да көнкүреш кирәкярагы юкка чыккан. Авыл аксакалы, мәгариф ветераны, СССРның мәгариф отличнигы, быел көзгә 85 яшен тутырачак Әсхәт ага Шәрипов аның мансарда рәвешендәге бүлмәсендә укып йөргәнен сагынып искә алды. Димәк, аның ул өлешен соңрак сүткәннәр.

Бу бинаны музей итүдә башлап йөргән Әсхәт ага, экспонатлар тупларга керешкәч, иң әүвәл драматургның күпсанлы туганнарына мөрәҗәгать иттек, ди. Чыннан да, Фәйзуллин фамилиясен йөртүче кардәшләре бихисап. Сүз уңаеннан, шул ук Мирхәйдәрнең әти-әнисе гаиләсендә унберенче – «төпчек» бала булып тууын искә төшерик. Авылның үзендә генә дә әдипнең нәсел шәҗәрәсенә кергән байтак дәвамчылар яши. Музейны оештырганда алар да хәлкадәри үз өлешләрен керткәннәр. Мирхәйдәр яшәгән чорны күзалларлык затлы савыт-сабаны, җиһазны, төп документларны таза тормышлы якын кардәшләре Фәйзуллиннар тапшырган, әлбәттә. Менә бу шәһадәтнамә, мәсәлән, аларның морзалар нәселеннән икәнлегенә дәлил. Гомумән, Фәйзуллиннарның нәсел-нәсәбе әдәбият, сәнгать һәм фән өлкәсендә буыннан-буынга җуелмаслык тирән эз калдырган. Һәрберсенең тарихта үз урыны бар, һәркайсы – горурланып телгә алырлык шәхес! Һәм аларның фотолары хаклы рәвештә иң түрдә музейны бизәп тора. Мин, барыннан да элек, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе композитор Җәүдәт Харис улы Фәйзи, аның абыйсы – медицина фәннәре докторы Мидхәт Харис улы, Башкортстанның халык артисты Рифгать Шакирҗан улы Фәйзуллиннарны күздә тотам... Мирхәйдәрнең Шода авылына килеп утырган абыйсы – Сәетгәрәй мулланың улы Сәгыйть тә, әдип иҗатын актив пропагандалаучы, әсәрләрен нәшер итүче буларак, зур ихтирамга лаек. Россия Фәннәр Академиясенең Геофизика институты академигы Ирек Солтан улы Фәйзуллин да бар бу асыл нәселдә. Алар бүләк иткән әйберләр дә музейны тулыландырып, ямь өстәп тора.

«Ә Мирхәйдәрнең үзенең нинди әйберләре бар соң музейда?» – дигән урынлы сорау туар укучыда. Кызганыч, бу җәһәттән Шода музееннан калыша сыман ул. Аның Шахмайга ике генә тапкыр – 1901 һәм 1906 нчы елларда әти-әнисенә ияреп кайтканын хәтерлиләр. Соңгы сәяхәте 14-15 яшьләрендә булып чыга… Җөмләдән, музейның алгы бүлмәсенә килеп керүгә үк яшь, чибәр егетнең портреты күзгә ташлана. Бу – Мирхәйдәр Фәйзинең сәләтле рәссам тарафыннан эшләнгән сурәте. Без бит инде әдипне күбрәк башына ниндидер кепка кигән, ябык чырайлы, күзлекле фотосы аша гына беләбез. Ә монысы ул замандагыча зәвыклы киенгән-ясанган Мирхәйдәрнең яшүсмер чагы, бөтенләй башка кыяфәтле, зыялы. Янәшәдә – әти-әнисенең портреты. Бу күркәм ядкярләрне музейга «Яңа Чишмә – Сөтле ил» җәмгыяте директоры Гомәр Сөләйманов тапшырган икән.

Музейны оештыручыларның берсе Әсхәт Шәрипов

Болардан тыш, тирә-як авыл кешеләренең, аерым шәхесләрнең бүләкләре дә куелган. Музейның хәзерге җитәкчесе, Әсхәт абый Шәриповның лаеклы алмашы, моңа чаклы 27 ел укытучы булып эшләгән Гөлнар Сабирова Мирхәйдәрнең туганы Фирүзә Фоат кызы Фәйзуллинаның, тагын бер кардәше – Диләрә Әнәс кызы Мөхәммәдьярованың документлар эзләп табудагы тырышлыгын билгеләп үтте. Күренекле галим Миркасыйм Госманов Әсхәт абыйга кардәш туры килә икән. Ул да заманында шактый гына китаплар бүләк иткән.

Нәтиҗәдә, музей яңа төс ала, күркәмләнә бара. Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов биредә булып киткәннән соң, эшләр тагын да җанлана төшкән. Йортка капиталь төзекләндерү үткәрелгән. Хәзер аскы каттагы 1720 елда нигез салынган Шахмай тарихына багышланган залда борынгы көнкүреш әйберләре, күренекле кешеләр хакында мәгълүматлар, фоторәсемнәр туплана. Бөек Ватан сугышында катнашучылар, беренче колхозлар турындагы стендлар да кызыклы. Алар музейга яңа төсмер биреп, бирегә килүчеләр санын тагын да арттырыр дигән өмет бар. Мәктәп балалары биредә еш була, тарихи темалар буенча ачык дәресләрдә өстәмә белем ала. Шулай да Казаннан шактый читтә урнашкан ошбу музей-йорт иң ерак җирләрдән дә ашкынып килә торган изге почмакка әйләнмәгән әле. Язучылардан да биредә бик сирәге генә булгандыр. Мәһабәт музей-йорт ямь биреп торган урамга Фәйзуллиннар исемен кушу күркәм гамәл булыр иде. Музейга килүчеләрне Мирхәйдәр Фәйзи һәйкәле каршы алса да, артык булмас. ■

Безнең мирас №4 апрель 2022

Дилүс Ильясов

Әхтәм Зарипов





ТАССРның атказанган (1957) һәм ТАССРның халык артисты (1974), Әстерхан тумасы Дилүс Ильясовның (Дэлюс Гали улы Ильясов, 1922-1981) яшь һәм олпат чагы. 1957 һәм 1978 нче елларда төшерелгән фотосурәтләр

Кемне дә булса хәтерләгәндә кеше аны үзе белән бәйле вакыйгалар аша исенә төшерә. Мин дә Дилүс абый Ильясовны аның Камал театрында уйнаган рольләре буенча түгел, ә уйнамаган рольләре буенча хәтерлим…

1961 елда Мәскәүдәге укуыбызны тәмамлап Казанга кайткач, барыбызны да Камал театры штатына алдылар.

Штатка алуын алдылар, әмма беребезгә дә яшәп торыр урын бирелмәде. Театр бинасында капиталь ремонт бара иде. Миңа, яшь балам белән хатыным булгач, «завлит бүлмәсе» дигән бүлмәдә яшәп торырга куштылар. Өйләнгәннәребездән башкаларга да җимерелгән театр бинасында почмак табарга рөхсәт иттеләр.

Җитмеш сум эш хакы белән фатирга урнашу мөмкинлеге булмагач, бер яшьлек улымны Казанга алып килми торырга кушып, хатыныма телеграмма җибәрдем.

Кышкы каникулга кайткач, Ижевск телевидениесе белән сөйләшү, килешү булган иде. Аларга югары белемле режиссер кирәк икән. «Безгә килсәң, фатир да, әйбәт эш хакы да бирербез», – дигәннәр иде. Шушы сөйләшүгә ышанып, һәркөн диярлек Ижевскига хат язарга утырам. Язган һәр хатымнан мескенләнү, ялыну «исе» килгән кебек тоела да, ул хатларны ерткалап атам…

Шундый кәефсез көннәремнең берсендә, көтмәгәндә-уйламаганда, мин яшәгән «завлит бүлмәсе»нә Академия театрының мәшһүр артисты Дилүс Ильясов килеп керде. Буш кул белән түгел – кулында кәгазьгә төргән 2 пирожки һәм бер ярты кызыл «өч җиде»ле. Хәл-әхвәл сорашудан соң, Дилүс абый керүенең сәбәбен аңлата башлады:

– Приказны укыдыңмы? – диде ул. Штатка кабул ителү турындагы приказдан башканы белмәвемне әйткәч:

– Роль бирү турындагы приказны укыдыңмы? – дип өстәде.

Мин үземчә роль кайгысы юклыкны аңлатырга тырыштым. Шулвакыт Дилүс абый приказның үзендәге күчермәсен чыгарып укыды. Анда Шамил Шаһгалинең «Без аерылышмабыз» дигән әсәре буенча спектакль куелачагы, режиссеры Ширияздан Сарымсаков булачагы һәм рольләрне кемнәр башкарачагы язылып, чуаш егете Габдерүш роленә Дилүс Ильясов һәм Әхтәм Зарипов билгеләнгән иде. Мин ни дияргә дә белми аптырап утырганда, сүзне Дилүс абый ялгады:

– Кыскасы, шул: мин бу рольне сиңа тапшырам. Уртак малны эт сөймәс, диләр. Рольләрне машинистка Җәннәттән алырсың. Иртәгәдән Ленин сараенда репетицияләр башлана. Мине сорасалар, «белмим»нән башка сүз әйтмә, калганын завтруппой Мәрьям апа Чанышева белән үзем сөйләшеп җайлармын…

Шуннан соң Дилүс абый «өч җиде»ле шешәсен ачып, бүлмәдәге бердәнбер кружкага салды да, аны миңа сузып:

– Җиппәреп куй, традициясе шул, – диде.

Күпме эчкәнемне хәтерләмим… пирожки дигәне алманыкы иде, анысын яратып ашадым.

Ник икәнен белмәдем, Дилүс абый ул чакта үзе эчмәде. Бутылканы шкаф артына куйды да: «Калганын рольне кулыңа алгач», – диде. Сүзем озынга киткәнгә гафу үтенеп, шуны гына әйтү урынлы булыр: Габдерүш роле Мәскәүдән килеп караучыларның күңеленә һуш килеп, әлеге рольне уңышлы башкарган өчен миңа Ленинград шәһәренә 15 көнгә иҗади командировка юлламасы бирделәр.

Бу хәлләрдән соң мин Дилүс абыйга рәхмәт әйтеп, «биш йолдыз»лы куярга тиеш булсам да, Дилүс абый өлгеррәк булып чыкты: үзе мине ресторанга алып кереп сыйлады, ышанычын аклавымны белдерде.

Шул аклауның нәтиҗәсе буларак, ул миңа Шәриф Хөсәеновның «Әни килде» әсәре буенча куелачак спектакльдә Әлмөхәммәт карт ролен бирде. Режиссеры Празат Исәнбәт иде.

– Аның белән үзем сөйләшеп җайлармын, – диде.

– Туксан яшьлек картны мин ничек уйнармын? – дигәч, ул:

– Профессияң шул! – дип, сүзне өзде.

Төрле интригалардан соң, спектакльне Марсель Сәлимҗанов сәхнәләштереп бетерде.

Марсель Сәлимҗановның театр дөньясына аяк басуында остазы булган Празат Исәнбәт, гариза язып, театрдан китәргә мәҗбүр ителде…

«Әни килде» спектакле сәхнәдә озак еллар куелды. Мин театрдан телевидениегә күчкәч тә, ролемне уйнарга чакыралар иде.

Ике йөзенче спектакльне уйнагач, телевизор аша махсус тапшыру күрсәттек. Рольләрне алмашсыз уйнаучы артистларга театр исеменнән Рәхмәт хатлары һәм бүләкләр тапшырдылар. Күңелсез булса да, шунысын да әйтми уза алмыйм: спектакльне тарихта калсын өчен тасмага төшергәндә мин уйнаган роль Фоат Халитовка бирелеп, хәзерге вакытта фондта саклана торган вариантта Әлмөхәммәт ролендә Фоат Халитов төште. Бу хәлгә артистлар бердәм каршы булсалар да, Габдулла абый Шамуковның сүзе барыбызны да тынычландырды: «Театрда прав не тот, кто прав, а тот, у кого больше прав…»

Сүзебезнең Дилүс Ильясовтан кинәт «Әни килде»гә күчүенә гаҗәпләнәсе дә юк. Әйтеп узганымча, Әлмөхәммәт роле Дилүс абыйга бирелгән һәм ул минем әлеге рольне башкаруыма «бишле» куеп, котлау сүзләрен ирештергән иде.

Театр тормышында мондый хәлләрнең еш булачагын күздә тотып, Дилүснең әнисе Гөлсем апа Камская (Миңлегөлсем Сәйфулла кызы Шәрипова) белән әтисе Гали Ильясов (Миңнегали Әхсән улы Ильясов, артист һәм режиссер) улларын сәхнәдән ераграк торган профессия сайларга димли.

Д.Ильясовның әнисе – актриса Гөлсем апа Камская (Миңлегөлсем Сәйфулла кызы Шәрипова, 1901-1975) һәм әтисе – артист, режиссер Гали Ильясов (Миңнегали Әхсән улы Ильясов, 1900-1970)

Ата да, ана да уларының артист булуына ризалык бирмәячәкләрен ачык сиздерсәләр дә, көннәрдән беркөнне биш яшьлек Дилүскә Казан ханлыгының җимерелүе турындагы пьесада варис – сабый Үтәмешгәрәй роле бирелүен сизмичә дә калалар.

Автор һәм режиссер Гали Ильясов үзе – Сафагәрәй хан ролен, Гөлсем апа исә Сөембикә ролен башкара. Кечкенә «артист» Дилүснең уены сәхнәдәшләренең генә түгел, спектакльне караган тамашачыларның да игътибарын җәлеп итә.

Дилүскә артистлык карьерасы юрыйлар. Татарларда юрау матур йола булса да, тормышта күп нәрсә язмыштан тора. Ә язмыш бу гаиләгә инде күптән тозак корып куйган булып чыга: Гали Ильясов язган пьеса һәм спектакль һөҗүмгә дучар ителә – урыска каршы әсәр, дигән мөһер сугылып, тикшерүләр башлана. Эш, озын-озак тикшеренүләрдән соң, Гали Ильясов атлы драматург, актер һәм режиссерның, гаепләнеп, Себергә сөрелүе белән тәмамлана. Гөлсем апа Камскаяны да, гаепләп, төрмәгә утырталар.

Шушы фактлар гына да Дилүс Ильясовның нинди шартларда үсүен күрсәтә түгелме?! Дилүс абыйның ул чорлар турында сөйләгәнен хәтерләмим. Ул, ничектер, җаен табып, сүзен икенчегә борып, көтелмәгән нәтиҗәләр чыгарырга ярата иде.

Артистлык карьерамда сизелерлек ярдәме турында язып узсам да, рәхмәтләремне кат-кат белдерсәм дә, аның табигатьне яратуын, балык каптыруга мөкиббәнлеген белгәнгә, мин аңа чираттагы ялын табигате бозылмаган, чиста сулы, балыклы күлләре күп булган Әгерҗе районының Иж буе Югары Барҗы авылында уздырырга тәкъдим ясадым.

Шуны гына көткәндәй, тиз ризалашып, ул юлга әзерләнә башлады. Укучылар да, Дилүс абыйның яңа гаиләсе дә гаеп итмәсләр – бу Дилүс абый өчен аеруча бәхетле ел иде. Чөнки күптәннән хыялланган баласы туган иде аның. Менә бу истәлекле хатирәләрне язарга утыргач, хәзер инде үзе оныклар үстерүче Дилүс кызы Чулпанга мөрәҗәгать итеп, кулыма беркайда да басылмаган язма материаллар һәм фоторәсемнәр алуга ирештем. Ахырга калдырганчы, шушы урында ук әйтеп узасым килә: «Язма материаллар» дигәннән, иң көтелмәгәне һәм гаҗәпләндергәне – Дилүс абыйның авиация мәктәбендә укып, очучы профессиясенә ия булуы.

– Ни өчен очучы булып китмәдең? – дигәнгә, Дилүс абыйның җавабы мондый булды:

– Сугыш вакыты, макетлардан карап кына өйрәнәбез, практикада очып карарга самолет юк, кайчан буласы да билгеле түгел. Аптырап йөрдем-йөрдем дә, армия хезмәтенә алынсам, анда очу практикасына тизрәк ирешү мөмкин булыр дигән фикергә килеп, үз иркем белән фронтка җибәрүләрен сорап гариза бирдем. Анда исә хезмәт итү



Р.Ç.Ф.С.Р.

НАРОДНЫЙ КОМИССАРИАТ ПРОСВЕЩЕНИЯ

АТТЕСТАТ – Дубликат

НАСТОЯЩИЙ АТТЕСТАТ ВЫДАН Ильясову Деллюсу Галеевичу (фамилия, имя и отчество), РОДИВШЕмуся в 1922 ГОДУ, В ТОМ, ЧТО ОН ОБУЧАЛся В СРЕДНЕЙ ШКОЛЕ ВВС Наркомпроса РСФСР (села, города) гор. Казани Тат. АССР (района и края-области-АССР), ОКОНЧИЛ ПОЛНЫЙ КУРС ЭТОЙ ШКОЛЫ И ОБНАРУЖИЛ ПРИ отличном ПОВЕДЕНИИ СЛЕДУЮЩИЕ ЗНАНИЯ:

ПО РУССКОМУ ЯЗЫКУ	хорошие
ПО ЛИТЕРАТУРЕ	хорошие
ПО АРИФМЕТИКЕ	хорошие
ПО АЛГЕБРЕ	посредственные
ПО ГЕОМЕТРИИ	посредств.
ПО ТРИГОНОМЕТРИИ	посредств.
ПО ЕСТЕСТВОЗНАНИЮ	хорошие
ПО ИСТОРИИ	хорошие
ПО КОНСТИТУЦИИ СССР	хорошие
ПО ГЕОГРАФИИ	хорошие
ПО ФИЗИКЕ	посредственные
ПО ХИМИИ	посредственные
ПО ГЕОЛОГИИ И МИНЕРАЛОГИИ	хорошие
ПО АСТРОНОМИИ	хорошие
ПО ИНОСТРАННОМУ ЯЗЫКУ (нем.)	посредственные
ПО РИСОВАНИЮ	хорошие
ПО ЧЕРЧЕНИЮ	посредственные
ПО в/делу	хорошие
ПО физкультуре	хорошие

„1“ июня 1942 года

№ 17

ДИРЕКТОР ШКОЛЫ Начальник спецшколы ВВС /Носков/

УЧИТЕЛЯ: Начальник уч/ч. /Осипов/

Д.Ильясовның очучылыкка укыганга алган аттестаты.
1942 ел, 1 июнь

минем теләк белән түгел, ә фронт таләбе белән булды – мин пулемет взводына эләктем. Хәзер авиаучилищеда бергә укыган егетләрне очратканда йөрәк әрнеп куйгалый, әлбәттә.

Аларның кайберләре инде генерал дәрәҗәсендә ялга чыккан, орден-медальләре белән күкрәкләре тулы, ә минем менә шушы Кызыл Йолдыз орденым да, медальләрем генә.

– Аларын нигә такмадың?

– Җиңү көнендә күрерсең. Ә Кызыл Йолдыз орденын мин үземнән калдырмыйм. Шәхси батырлык өчен бирелде ул миңа – берьялгызым ике пулеметны «эшкә» җигеп, дошман ротасы калдыкларын чигенергә мәҗбүр иткән өчен. – Шушы сүзләреннән соң, Дилүс абый күккә карады да: – Әнә, күрәсеңме, «Як» очып бара, Ижевскига Калашников автоматларына баргандыр, – дип өстәде.

– Самолетка автомат нигә кирәк?

– Әфгандагы сугышка Калашников кына түгел, без белмәгән кораллар да күп кирәк. Менә бит без дә хәзер балыкны кармак белән түгел, ә ау салып тотабыз.

– Тотмыйбыз – аулыйбыз…

– Тотмагач, нигә ауларга?!.

Ул көнне безнең ауга көткәннән күпкә артык вак табан балыгы эләккән иде. Ярга тартып чыгаргач, чүпләргәме-юкмы, дип озак бәхәсләштек. Дилүс абый: «Чүпләсәк тә, күлгә ташлап барырга кирәк, киләсе елга зураеп көтәрләр», – диде. Мин исә берсен дә әрәм итми кәрҗинебезгә салып, кибетче Дөркамал апага кайтарып бирү ягында идем. «Хәмерлек», – дигән булдым. Дилүс абый моңа каршы: «Миңа андыйның тамчысы да кирәкми», – диде.

…Шулай да җыйдык. «Тавыкларга азык булыр», – дип, Дилүс абыйны да тынычландырдым. Хәер, «тынычландыру» дигән сүзне Дилүс абыйга карата әйтү дөреслеккә туры килмәс. Чөнки аның күзгә бәрелерлек холыксызлык сыйфатлары күрсәтүен хәтерләмим. Тыныч кеше иде ул. «Холык – заман җимеше», – диләр. Дилүс абыйның холкына игътибар итсәк, ул әдәпле, әхлаклы, гомумән, кешене рәнҗетерлек сүз әйтми торган иде. Һәрчак «сорау – сырхау, бирмәсә – үлем» дигәннән чыгып эш итә. Андый кешеләрне: «Зыялы шәхес», – диләр. Киенүе һәрчак пөхтә, чәче таралган, сакал-мыегы кырылган булыр. Минем уемча, аның холкындагы бу сыйфатлар аңа үсмер чагында булган тискәре караштан саклану чарасы буларак берегеп калгандыр.

Сүзебез балыкны кәрҗингә тутыргач өзелеп, башка юнәлеш алган иде. Кабат шуңа әйләнеп кайтсак, безне резина көймәне һәм җәтмәбезне (ауны) кайда калдыру проблемасы көтә. Бу күлнең балыгы вак булганлыктан, ауны Кара Күл буена яшереп, көймәне суга батырып китәргә булдык. Гадәтенчә, Дилүс абый тәкъдимнәргә риза иде. Кара Күлгә үзебез генә бармаска, тәҗрибәле авыл кешесен ияртергә булдык. Тәҗрибәле балыкчыбыз әлеге тәкъдимне бер атнадан соң гына кабул итте. Аның ярдәмендә без алтмыш килодан артыграк кара балык, сазан, чуртан тоттык. Күңелебез дә булды, тамагыбыз да туйды, ул арада кайтыр көннәр дә җитте.

Бәлки, кемнәрдәдер Дилүс Ильясовның сәхнәдәге уенын төшергән «любительский» видеокадрлар саклана дыр?

Сүземне Әсфән Ильясов телевидениегә тапшырган язманың кайбер фрагментлары белән дәвам итеп, үземне дә, укучыларымны да канәгатьләндерүгә өметләнәм: *«Утызынчы еллар ахырында әти репрессияләнгән. Соңрак абый үзе*

Дилүс Ильясов энесе Әсфән белән

теләп фронтка киткән. Ул чагында мин әле бик яшь идем, боларның барысы турында әнием сөйләве буенча гына беләм.

Абый белән мин үземне аңларлык хәлдә сугыштан соң, 1946 елда гына очраштым. Анда да әле тик бер күренеш кенә ачыграк булып хәтердә калган. Шулай көннәрдән беркөнне безнең ишегалдына, кызу-кызу атлап, аркасына солдат капчыгы аскан сөйкемле генә бер егет килеп керде. Аның абыем Дилүс икәнен күңелем, ничектер, шундук сизде.

Өйдә ул озак тормады, үзебез белән бергә актерлар тулай торагында яшәүче артистлардан Розалия Шамил, Роза Уральскаяларның ГИТИСта укучы балалары йогынтысында Мәскәүгә китеп барды һәм татар студиясенең өченче курсына кабул ителде.

Әниебез, бер гаилә өчен минем чегән тормышым да бик җиткән, дип, абыйның артист булуын һич тә теләмәгән иде. Әмма аның бик шәп җырлавын, ут чыгарып биюен һәм оста итеп гитарада уйнавын күреп көрсенә дә әкрен генә тәрәзә каршысына килеп баса, әйтерсең лә, анда үзенең яшьлеген күрергә тели иде.

Ниһаять, 1948 елны ГИТИСның татар төркеме Казанга кайтты һәм Яшь тамашачылар театры сыйфатында эшли башлады.

Татар яшь тамашачылар театрының беренче спектакльләре әле ГИТИСта ук куелган диплом спектакльләре иде. Хәтеремә бигрәк тә Г.Мусреповның «Козы Көрпеш һәм Баян Сылу» дигән драматик поэмасы һәм М.Горький әсәре буенча куелган «Васса Железнова» спектакльләре уелып калган. Аларның беренчесендә Дилүс поэма персонажларының язмыш китабын ачучы акын ролен башкарды. Бу образда Дилүснең күңелне кузгата торган моңлы тавышы, шул моңга аваздаш булырдай күз карашы тамашачыларны тәмам әсир итте.

Икенче спектакльдә абый Пятеркинны уйнады. Роле әллә ни зур булмаса да, Дилүс абый башкаруында ул үзенә күрә бер шедевр иде. Дилүс-Пятеркин барысын да аңлап эшли торган оятсыз, вөҗдансыз бер ерткыч, аның бөтен эчке дөньясы әшәкелек, әдәпсезлек, кабахәтлек белән сугарылган. Әмма ул әлеге кешелексез сыйфатларын шундый оста итеп яшерә ки, тамашачылар башта «ах» итәләр, ә

соңрак аларның күңелендә бу икейөзле затка карата нәфрәт, җирәнү хисләре уяна. Актер куйган максатына әнә шулай ирешә һәм татар тамашачылары алдында беренче имтиханны бик уңышлы тота.

Кәрим Тинчурин aклaнгач та, аның «Зәңгәр шәл» пьесасы куелган иде. Дилүс абый андагы урман аланында ярсулы чегән биюен башкарды. Бию тәмамлангач, мин сәхнә артына кердем һәм чиксез арыган, тиргә баткан, әмма йөзенә канәгатьлек, шатлык билгеләре чыккан Дилүс абыйны күрдем. Әйе, биюе әйбәт килеп чыкты, ләкин драма артисты өчен моның никадәрле рухи һәм физик көч таләп итүен актер үзе дә бер Алла гына беләдер.

Яисә менә сугыштан соңгы Германиянең язмышына кагылышлы «Тормыш яңадан башлана» дигән драмадагы нәзакәтле биюне алыйк. Дилүс абый башта саксофон булып кылана, аннары дәртле бию башлана. Дилүс абый ул чагында әле яшь, иҗат дәрте ташып торган Шаһсәнәм Әсфәндиярова белән бергәләп бии. Аларның биюенә секстеты белән кушылып уйнаган Олег Лундстрем ул чагында: «Бу искиткеч пар чит илләрдәге үтә купшы рестораннарда да һич тартынмыйча бии алачак һәм гадәттән тыш уңышка ирешәчәк», – дигән иде. Г.Камалның «Иске Казанның серләре» дигән пьесасында Дилүс абый баш өстенә самавыр куеп биеде һәм татар халкының бию байлыгын, андагы йомшак юморны, гүзәл фантазияне сокланырлык итеп гәүдәләндерде.

Кызганычка каршы, Татар яшь тамашачылар театры кыска гомерле булып чыкты, КПСС өлкә комитеты ул чагында үзенең авыр көннәрен кичергән Академия театры басымы астында Яшь тамашачылар театрын таратты, аның яшь, талантлы коллективы Г.Камал театры труппасында «эреп бетте»...

Әлбәттә инде, талант ул кайда да талант булып кала. Яшьләрдән кайберләре Академия театры сәхнәсендә үзләшеп тамыр җибәрде, алар арасында минем абыем Дилүс тә бар иде. Ә кайберләре, театр белән араны бөтенләйгә өзеп, төрлесе төрле җиргә таралышты.

Дилүс Ильясов Хәлил ролендә («Галиябану», М.Фәйзи)

Дилүс Ильясов, образларның иң яшерен күңел почмакларына үтеп керергә ярдәм итә торган юморы, ярсулы темпераменты өстенә, моңлы һәм саф тавышка да ия иде. Шулай театрда үткәрелгән бер мәҗлес вакытында ул «Корневильские колокала» опереттасыннан «Көтүче ариясе»н башкара. Мәҗлестә опера артистлары да була. Алар Дилүс абыйның җырлавын исләре китеп тыңлыйлар һәм көчле алкышларга күмәләр. Җырчы коллегаларының тануы драма артисты өчен иң зур бүләк бит ул! Әмма тавышы Дилүс абый өчен бәхет тә, бәла дә иде, чөнки ул аңа актерлык талантын бөтен куәтенә ачарга комачаулады. Комачаулады дигәнем шул – Дилүс абый җырлаучы персонажларны уйнарга мәҗбүр иде. М.Фәйзинең «Галиябану» музыкаль драмасында – Хәлил, «Ак калфак»та – Бакый, К.Тинчуринның «Казан сөлгесе»ндә шәкерт Ильяс – әнә шундый образлар.

Әниебез Гөлсем Ильясова-Камская шундый бер вакыйганы искә ала иде. Репертуар фәкыйрьләнеп киткәч, Кәрим Тинчурин бер көн эчендә «Казан сөлгесе» дигән пьесасын яза. Бу кадәресе күпмегә дөрестер – әйтә алмыйм, әмма авторның гаҗәеп зур, үзенчәлекле талантын искә алганда, моңа һич тә шикләнмәскә мөмкин. Шулай бик тиз язылуына карамастан, куючылары өчен бер дә җиңел булмый бу пьеса. Беренче карашка бик гади, җилбәзәк, драматургның шуклыгы кебек кенә күренсә дә, бүгенге көнгә кадәр ул режиссерлар өчен табышмак булып кала бирә.

Әлеге пьесаны куйганда режиссерлар, гадәттә, бик җиңел юлны сайлыйлар – аны кәмиткә әйләндерәләр һәм соңгы чиктә ул беркатлы, әдәпсез шаяруга кайтып кала. Дөрес, беренче куелышында Рәфкать Бикчәнтәев белән Дилүс Ильясов, ике шәкерт дуэтын башкарып, бу пьесаның серен ачуга шактый зур өлеш керттеләр. Алар инде икесе дә юк, ә пьеса табышмак булып кала бирә, бу үткен, фантазиягә искиткеч бай комедия тупаслыктан арындырып куя алырдай талантлы режиссерын көтә.

Дилүс Ильясов башкарган соңгы роль Туфан Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү» дигән пьесасындагы Галим образы булды. Әллә нигә бер генә күренеп ала торган эпизодик роль Дилүс абый башкаруында тамашачы күңеленнән мәңге чыкмаслык калку бер образга әверелде. Дилүс абыйдагы юмор, ирония, фикер, зәвык хисе, актер өчен бәя биреп бетермәслек мөлаемлык сыйфаты театр тарихында калырлык әнә шундый образ тудырырга ярдәм итте.

Дилүс Ильясов Галим ролендә
(«Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнуллин)

Дилүс Ильясов әнисе Гөлсем, хатыны Флера Хәмитова, кызлары Айгөл һәм Чулпан белән. 1973 ел

Мин «фикер» дигән сүзне кулландым. Чөнки Дилүс абый башкаруындагы Галим образы зур социаль көчкә ия, ул – эчтән буш, тыштан исә чиксез һавалы, кешеләргә үз фикерен тагарга яратучы гомумиләштерелгән социалистик тип.

Яшьлеген халык дошманы баласы булып үткәргән, Бөек Ватан сугышын башыннан алып ахырына чаклы узган, театр сәнгатенә бөтен барлыгын, талантын һәм саулыгын корбан иткән Татарстанның халык артисты Дилүс Ильясов татар театр сәнгате осталары арасында бик хаклы рәвештә үзенә лаеклы урынны алып тора».

***

Кечкенә булса да, «төш» кенә өстәмә: гаиләләр белән ялга барган Югары Барҗы авылы да, авыл урнашкан җирләр дә, Көтмәс елгасы, балыклы күлләре дә, авылның кунакчыл кешеләре дә инде бакыйлыкка күчкәннәр. Әмма Дилүс абыйны ашка чакырып кунак иткәннәрнең балалары әле исәннәр. Алар Ижау һәм Можга шәһәрләрендә яшиләр. Очрашканда «артист абыйның балыкчы маҗаралары»н хәтерләп, хөрмәт белән искә алалар. Түбән Кама сусаклагычы төзелгәч юкка чыккан Югары Барҗы авылы да, кунакчыл кешеләре дә, кунаклары да исән варисларның хәтерендә. Шулай хатирәләргә күчеп, күңелләрдә яшәсәң икән. Ә Дилүс абый моңа лаек иде һәм шулай яшәвен дәвам итә дә ул!.. ■

Тукайның олуг юбилее илә әдипләребезнең хатлары

Ләбиб Лерон

Г.Тукай китапларының тышлыклары

Мәгълүм ки, мәшһүребез Тукайның 100 еллыгы уңаеннан, ЮНЕСКО карары белән, 1986 ел Габдулла Тукай елы дип игълан ителә.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе (рәисе – Туфан Миңнуллин) тырышлыгы нәтиҗәсендә, 1986 елның 26 апрелендә – Казанда (әлбәттә, бөтен Татарстанда һәм СССРның төрле төбәкләрендә), шул ук елның 11-13 июнендә – Кырлай һәм Кушлавыч авылларында (шулай ук Казанда – М.Җәлил исемендәге опера һәм балет академия театры бинасында), 14 октябрьдә Мәскәүдә (Союзлар йортының Колонналы залында) бөек Тукаебызның 100 еллыгы тантаналы шартларда узды.

Әлбәттә, Тукайның 100 еллыгын шулай зурлап үткәрүдә, аерым алганда, бөек шагыйребезнең китапларын Мәскәүнең атаклы нәшриятларында бастыруда ул вакытта төзелгән юбилей комиссиясе әгъзаларының һәм аерым язучыларның, тәрҗемәчеләрнең өлеше зур булды. Төрле нәшриятларда – «Художественная литература» (11 табак), «Советский писатель» (10 табак), «Детская литература» (5 табак), «Малыш» (балалар өчен шигырьләр), «Современник» (поэмалар), «Советская Россия» («Шүрәле» поэмасы) Г.Тукай китапларын бастыру ният ителә, бу эшләргә

Евгений Винокуров, Владимир Соколов, Владимир Солоухин, Лариса Васильева, Белла Әхмәдуллина, Алла Ахундова, Владимир Леонович, Лев Озеров, Николай Старшинов, Яков Козловский, Владимир Микушевич, Юнна Мориц кебек язучы-шагыйрьләр һәм тәрҗемәчеләр җәлеп ителә.

Мәшһүр шагыйребезнең төрле нәшриятларда басылган китаплары

Күптән түгел генә кулыма Тукайның 100 еллыгына нисбәтле бер папка килеп керде. Аны миңа «Безнең мирас» журналының элекке хезмәткәре (хәзер дә журнал белән хезмәттәшлек итә), бүгенге көндә Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант вазыйфасын башкаручы Марат Закир бирде. Ул папкадагы документларга, хатларга нигезләнеп, бу юлларның авторы аерым мәкалә язды һәм аны «Казан утлары» журналына тәкъдим итте. Әлеге мәкаләдә файдаланылмаган хатларны «Безнең мирас» журналы өчен әзерләнгән ошбу язмада кулланырга булдым.

Язучы һәм тәрҗемәче Мәҗит Рәфыйков (1925-1986)

Язучы Мәҗит Рәфыйков (1925-1986) хатыннан башлыйм. Ул аны 1985 елның 5 мартында шагыйрь Разил Вәлиевкә (1984-1986 нчы елларда Татарстан Язучылар берлегенең идарә рәисе урынбасары булып эшли) атап язган:

«Хөрмәтле Разил Исмәгыйлевич!

Без Тукайның хатлар подборкасын «Лит.Россия»гә хәзер үк җибәрик, тизрәк җибәрик. Бу подборка тизрәк басылып чыксын, Тукай прозасы бастырып чыгарга әзер икәнен Мәскәү нәшриятлары белеп торсын!

Тукайның туган көненə əле 50 көн вакыт бар, ул арада редактор солидный кульъязманы редакциялəп чыга ала. Вакыт бушка узмасын, ə туган көненə яңа материал да əзерли алырбыз.

Үзегез тəрҗемəне укып, ныклы фикер туплап куясыздыр инде. Телəсə кем, телəсə кайсы нəшрият белəн сөйлəшə алырлык булсын өчен.

Əгəр дə Тукайның бүтəн мəкалəлəрен бастыру фикерегез туса, миңа хəбəр бирерсез, үзем машинкада бастыртып бирермен. Күчертеп. Бирер алдыннан укып та чыгарга тиеш бит əле.

«Советская Россия» хезмəткəре Е.И.Имбовицка (Елена Имбовиц –редактор, тəрҗемəче. – Л.Л.) хат яздым, менə Сезгə копиясе. Анда мине автор буларак та, тəрҗемəче буларак та яхшы яктан белəлəр. Тукайны чыгару – бу нəшриятның да бурычы. Ник яздым? Эшнең чын хəлен белеп торсыннар, сез хəбəр дə бирмəдегез, без бернəрсə дə белмəдек, дип тормасыннар өчен яздым. Ə хəзер əле бу тəрҗемəне ике-өч тапкыр чыгарырга була, тик андый-мондый сылтау чыгармасыннар. Төп мəсьəлə планлаштыруда, билгеле.

Аннары тагы бу хатымда мин аларга тəрҗемəнең бөтенлəй яңа хезмəт икəнен, үземнең эш принципларымны ачыклап яздым. Сыйфаты, эшлəнеше белəн тулаем яңа басма булачагын аңлатып. Моны Сезлəргə дə истə тоту яхшы инде.

Үз юбилеем əллə ни түгел, Тукай юбилее – юбилей.

Хикəялəремне туплап, Сезгə җиткерермен. Шигырьлəрне дə.

Ихтирам һəм сəлам белəн Мəҗит Рəфыйков. 5 март, 1985 ел».

Мəҗит ага Рəфыйковның (ул Тукай юбилеена нисбəтле бəйрəм тантаналарында катнаша алмый – 1986 елның 24 гыйнварында вафат була. – Л.Л.) Тукай хакындагы мəкалəсеннəн хəбəрдар булган Туфан Миңнуллин (ТАССР Язучылар берлеге рəисе) «Дружба народов» журналының баш редакторы Сергей Баруздинга (С.А.Баруздин (1926-1991) – совет язучысы, шагыйрь. – Л.Л.) мондый эчтəлектəге хат язган:

«Уважаемый Сергей Алексеевич!

В апреле 1986 года общественность Татарии и всей страны будут отмечать 100-летие со дня рождения великого татарского поэта Габдуллы Тукая. В настоящее время ведется большая подготовительная работа к этой знаменательной дате: создаются республиканская и всесоюзная юбилейные комиссии, отправлены необходимые материалы в ЮНЕСКО и т.д. К юбилею многие журналы страны включили в свои планы новые переводы Г.Тукая или солидные статьи о его творчестве.

Правление Союза писателей Татарии просит Вас, Сергей Алексеевич, уделить этой знаменательной дате достойное внимание. При случае необходимости мы готовы помочь Вам в организации материалов.

Предлагаем Вашему вниманию статью писателя Мазита Рафикова о прозе Тукая. Председатель правления Союза писателей Т.Миңнуллин».

Берочтан «Советская Россия» нəшриятының директоры В.И.Новиковка (1933 елда туган, нашир, журналист. – Л.Л.) да хат юллана:

«Уважаемый Виктор Иванович!

Как Вам уже известно, в апреле 1986 года общественность Татарии и всей страны будут отмечать 100-летие великого татарского поэта Г.Тукая. К этой знаменательной дате многие издательства страны, в том числе и Ваше, готовят выпуски книг поэта. «Советская Россия» включила в свой темплан одну из жемчужин творчества Г.Тукая – сказку-поэму «Шурале» (в подарочном варианте), иллюстрации к

которой делает художник Надир Альмеев. Работу свою завершил и скоро представит.

Госкомиздат Татарской АССР просит Вас выпустить книгу к юбилейной дате – 26 апреля 1986 года».

Ә менә бу хатның авторы – Мәскәүдә яшәп иҗат итүче шагыйрь һәм тәрҗемәче Равил Бохараев (1951-2012). ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Разил Вәлиевкә мөрәҗәгать итеп язылган ул хатка 1984 елның 14 июнь датасы куелган:

1984-1986 нчы елларда Татарстан Язучылар берлегенең идарә рәисе урынбасары, әдип Разил Вәлиев

«Дорогой Разиль!

Извини, отъездом забыл сказать тебе важную для меня вещь. Когда будут перепечатыватьь сборник для «Художественной литературы», пусть не забудут включить туда мои переводы, которые я тебе дал для «Союзмультфильма». Дело в том, что в Казанский сувенирный сборник я своих переводов почти не включал, так как я составитель, и это мне показалось неудобным. Для Москвы же это все равно, а мои переводы, мне кажется, объективно точнее прежних. Это подверждает и рецензии, и мнение Михаила Львова (Рәфкать Дәүләтша улы Габитов (1917-1988) – татар, Башкортстанның Салават районындагы Насыбаш авылы тумасы. – Л.Л.), который является общественным редактором сборника Тукая.

Успехов тебе и хорошего настроения, до встречи, Равиль Б. 14 июня 1984 года».

Шагыйрь һәм тәрҗемәче Равил Бохараев (1951-2012)

Күпмедер вакыттан соң, Р.Бохараев Р.Вәлиевкә телеграмма суга: «РАЗИЛЬ ВОПРЕКИ ОБЕЩАНИЯМ СОВЕТСКОЙ РОССИИ ЗАДЕРЖИВАЮТ ТУКАЯ ВНЕ ПЛАНА НУЖНО СРОЧНО ЗВОНИТЬ НА ЛЮБОМ УРОВНЕ ОБЯЗАТЕЛЬНО НАЙДИ МЕНЯ В МОСКВЕ УВАЖЕНИЕМ = РАВИЛЬ».

Равил Бохараев үзенең борчылуларын Сибгат Хәким белән дә уртаклаша. 23 февраль алдыннан (язылу вакыты күрсәтелмәгән, 1985 яки 1986 елдыр дип фаразларга гына кала. – Л.Л.) язылган ул хатта менә мондый юллар бар:

Татар әдәбияты классигы Сибгат Хәким (1911-1986)

«Уважаемый Сибгат ага!

Поздравляю Вас с праздником 23 февраля!

А еще пишу вот по какой причине: от Виля Ганиева (Вил Хәлим улы Ганиев (1934-2005) – Яшел Үзән районының Норлат авылы тумасы, тәрҗемәче, 1967-1991 нче елларда СССР Язучылар берлегендә эшли, шагыйрь Әхмәт Ерикәй (1902-1967) кияве. – Л.Л.) узнал, что спецредактором издания Тукая в Ленинграде опять назначен Ботвинник (Семен Вульфович Ботвинник (1922-2004) – табиб, тәрҗемәче, 1975-1995 нче елларда Ленинград Язучылар оешмасының шигърият секциясе җитәкчесе, «День Поэзии»

җыентыгының төзүчесе һәм мөхәррире. – Л.Л.). Более того, там разговор идет уже о том, что к юбилею они выпустить книгу якобы не успевают, хотя рукопись им сдана согласно их просьбе именно с расчетом на то, что успеют еще в начале октября 1984 года.

Не знаю, чем они там заняты. Боюсь, что опять мы будем иметь вариант предыдущего издания с переводом Ботвинника и более ничего.

Я очень прошу Вас, как председателя юбилейной комиссии, связаться с Ленинградом. Я, честно говоря, на грани возмущения. Если они позволят себе бесцеремонно обойтись с моим составлением, я сниму свою фамилию с составления, в котором будут переводы только Ботвинника и пр.

Нужно что-то делать!

С глубоким уважением, Р.Бухараев.

R.S. К тому же издательство в Ленинграде переехало, и я не могу дозвониться до Андреева (кемлеген ачыклап булмады. – Л.Л.) и Гейро (Людмила Семеновна Гейро (1941-1921) – 1966-1994 нче елларда Ленинградтагы «Советский писатель» нәшриятының «Библиотека поэта» редакциясендә эшләгән. – Л.Л.)».



Г.Тукайның 1986 елда «Малыш» нәшриятында (Мәскәу) басылган «Мальчик с дудочкой» китабының тышлыгы

Күргәнебезчә, Тукай китаплары, төрле авырлыклар кичә-кичә, укучылар кулына барып ирешә. Мәшһүребезнең поэмалары, шигырьләре һәм әкиятләре (тәрҗемәчеләре – А.Ахматова, В.Тушнова, В.Звягинцева, В.Державин, С.Ботвинник, В.Ганиев, Г.Пагирев, А.Чепуров һ.б.) тупланган китап («Стихотворения и поэмы») «Советский писатель» нәшриятында, ниһаять, соңарып булса да, 1988 елда «Шагыйрь китапханәсе» сериясендә басылып чыга. ■

Безнең мирас №4 апрель 2022

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

СИРИН БАТЫРШИН (1896-1970)

Татар шагыйре Мөхәммәтсәйрин Мөхәммәтхәниф улы Батыршин 1896 елның 14 декабрендә Татарстанның Баулы төбәгендәге Кәрәкәшле авылында игенче гаиләсендә туган.

1935 елның 22 августында Сирин һәм тагын берничә язучы (Ә.Айдар, Г.Ризванов, И.Кули һ.б.) кулга алына. Аларны контрреволюцион оешма төзүдә һәм советка каршы пропаганда алып баруда гаеплиләр. 1936 елның 31 гыйнварында Сирин, махсус киңәшмә карары нигезендә, биш елга Сиблагка (лагерьга) озатыла.

Сирин иреккә чыгуга, Бөек Ватан сугышы башлана һәм ул үзе теләп фронтка китә, анда берничә тапкыр каты яралана. Шул яралары ачылып, Сирин 1969 елның 23 ноябрендә туган авылы Кәрәкәшледә вафат була.

СӘЙФИ КАЗАНЛЫ ФАТИХ (1888-1938)

Татар язучысы, әдәбият тәнкыйтьчесе Фатих Сәйфи Казанлы (Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин) 1888 елның 22 мартында хәзер Татарстанның Әлки районына кергән Карамалы авылында туган.

Ф.Сәйфи Казанлы 1936 елның 16 сентябрендә (кайбер чыганакларда – 18 сентябрьдә) кулга алына 1937 елның 5 августында (кайбер чыганакларда – 3 августта) ул атып үтерелә.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

СОЛТАН ӘМӘТХАН (1920-1971)

Хәрби очучы Әмәтхан Солтан 1920 елның 20 октябрендә Кырым АССРның Алупка шәһәрендә туган. Ике тапкыр Советлар Союзы Герое.

Шушы каһарманның гаиләсен Кырымнан сөрергә карар чыгаралар, аларны хәтта «сатлык» буларак атарга да телиләр. Әмәтхан аларны яклап кала. Ләкин... мең үлемнән исән калган батыр егет тыныч вакытта, канатлы ракеталарны сынаган чакта – 1971 елның 1 февралендә серле рәвештә һәлак була.

СҮНЧӘЛӘЙ СӘГЫЙТЬ (1889-1937)

Татар шагыйре Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләй 1889 (кайбер чыганакларда – 1888) елның 14 августында (иске стиль белән – 2 августта) Саратов губернасындагы Хвалын өязенә караган (хәзерге Сембер өлкәсенең Иске Кулаткы районы) Иске Мостяк авылында туган.

Сәгыйть Сүнчәләйнең гомере, ул чордагы татар зыялыларының күбесе кебек үк, фаҗигале өзелә: ул 1927 елның 1 июнендә кулга алына һәм атып үтерелүгә хөкем ителә, бераздан бу хөкем 10 елга төрмә белән алыштырыла. Солтангалиев эше буенча хөкем ителгәннәрне 1937 елда кабат эзәрлекләү башлангач, шагыйрь яңадан хөкемгә тартыла һәм 27 октябрьдә атып үтерелә.

ТАКТАШ ҺАДИ (1901-1931)

Татар шагыйре Һади Такташ 1901 елның 1 гыйнварында Тамбов губернасының Спас өязендәге (хәзерге Мордва Республикасының Торбеево районы) Сыркыды авылында туган.

Совет хакимияте урнашкач, Такташны «кыйнау» башлана. Сәбәбе – вульгар социологлар Такташның талантын кабул итә алмый. Нәтиҗәдә, аңа хөкем оештыралар һәм Донбасска сөрәләр. Ул сәер шартларда (һөҗүм оештырыла) 1931 елның 8 декабрендә кинәт вафат була.

СУЛЬКЕВИЧ СӨЛӘЙМАН (1865-1920)

Генерал-лейтенант Сөләйман Сулькевич 1865 елның 20 июлендә Литваның Виленск губернасында татар дворяннары гаиләсендә туган. Кырым хөкүмәтенең премьер-министры һәм Кырым крае хөкүмәтенең эчке эшләр министры (1918).

Сөләйман Сулькевич 1920 елның 15 июлендә Азәрбайҗанда большевиклар тарафыннан судсыз гына атып үтерелә.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Конгресс: тәүге адымнар, изге максатлар

Ләбиб Лерон

Минем кулымда – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының боерыгы (№75-р, 18 февраль, 1992 ел). Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә юлланган ул боерыкны 1990 елның 30 августыннан 1995 елның 16 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфасын башкарган Мөхәммәт Галләм улы Сабиров (1932-1995) имзалаган. Урысча язылган текстны татарчага тәрҗемә итеп китерәм:

1990-1995 нче елларда ТР Премьер-министры, Башкортстанның Кушнаренко районындагы Яңа Кормаш авылы тумасы Мөхәммәт Галләм улы Сабиров (1932-2015)

«Татарстан Президентының Бөтендөнья татар конгрессы корылтаен 1992 елның июнендә үткәрүгә кагылышлы Указына нигезләнеп, Оештыру комитетын түбәндәге составта расларга:

***М.Г.Сабиров** (рәис, ТР Премьер-министры), **М.Х.Хәсәнов** (рәис урынбасары, ТР Премьер-министрының беренче урынбасары), **М.М.Таишев** (рәис урынбасары, ТР мәдәният министры), **К.Ш.Исхаков** (рәис урынбасары, Казан шәһәр хакимияте башлыгы); оештыру комитеты әгъзалары – **С.И.Кирилов** (ТР эчке эшләр министры), **В.Г.Гайфуллин** (ТР мәгариф министры), **Д.Н.Нагуманов** (ТР финанс министры), **А.И.Нуруллин** (ТР сәүдә министры), **И.К.Хәйруллин** (ТРның Телевидение һәм радиотапшырулар буенча дәүләт комитеты рәисе), **Ш.Ш.Хамматов** (ТР матбугат һәм мәгълүмат министры, ТР Журналистлар берлеге рәисе), **И.Н.Низамиев** (ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Җәмәгать тукланыуы идарәсе башлыгы), **Ф.И.Гайнуллина** (ТР Профсоюзлар советы рәисе), **З.З.Алимов** («Татарстантурист» оешмасының генераль директоры), **П.А.Обыденнов** (Татавтотранс» предприятиесенең генераль директоры), **Х.М.Мортазин** (ТР Дәүләт спорт комитеты рәисе), **М.А.Даутов** (ТР территориаль торак-коммуналь хуҗалыгы генераль директоры), **И.Ш.Хәбибуллин** (ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Дин эшләре буенча совет рәисе), **В.М.Нестеров** («Татарстан авиалинияләре» авиакомпаниясенең президенты), **Э.Ф.Самохин** (Горький тимер юлының Казан бүлеге җитәкчесе), **Р.Х.Әхмәров** (Берләштерелгән Идел буе елга пароходчылыгының Казан порты башлыгы), **И.В.Терентьева** (ТР Президент аппаратының Милләтара мөнәсәбәтләр һәм сәяси оешмалар белән элемтә урнаштыру бүлеге мөдире), **Р.М.Галимов** (ТР Президенты аппаратының оештыру эшләре бүлеге мөдире), **Р.З.Бәдретдинов** (ТР Министрлар Кабинеты секретариатының Мәдәният бүлеге мөдире), **Р.С.Хәкимов** (ТР Президенты киңәшчесе), **М.Г.Әһлиуллин** («Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррире, ТР халык депутаты), **Р.М.Харисов** («Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире, ТР халык депутаты), **Р.Г.Фәйзуллин** («Казан утлары» журналының баш мөхәррире, ТР халык депутаты), **М.Г.Мөлеков** (Татар иҗтимагый үзәге президенты, ТР халык депутаты), Ф.Ш.Сафиуллин (ТР Югары Советының даими комиссиясе рәисе), **Р.С.Мөхәммәтҗанов** (М.Җәлил исемендәге Та-*

тар дәүләт опера һәм балет академия театрының директоры), ***Р.Ф.Кәлимуллин*** *(ТР Композиторлар берлеге рәисе),* ***Р.С.Мөхәммәдиев*** *(ТР Язучылар берлеге рәисе),* ***Н.У.Әлмиев*** *(ТР Рәссамнар берлеге рәисе),* ***М.З.Зәкиев*** *(Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры),* ***Ф.М.Мусин*** *(Татар «Мирас» фонды советының рәисе),* ***М.И.Мәхмүтов*** *(ТР Фәннәр академиясе академигы, «Ватан» җәмгыяте президенты),* ***М.Г.Госманов*** *(ТР Фәннәр академиясе академигы, Татар телен һәм мәдәниятен саклау фонды президенты),* ***Ә.Г.Кәримуллин*** *(ТР Фәннәр академиясе академигы),* ***Габделхак Саматов*** *(Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенең Европа өлешенә караган Диния нәзарәте мөхтәсибе),* ***Р.Р.Туфитуллова*** *(«Сөембикә» журналының баш мөхәррире).*

ТР Премьер-министры (имза) ***М.Г.Сабиров****».*

ТР Язучылар берлегенең ул чактагы идарә рәисенең урынбасары **З.М.Мансуров** Бөтендөнья Татар конгрессының Оештыру комитетына аерым хат юллый. Әлеге хатның эчтәлеге моннан гыйбарәт:

«Татарстан Язучылар берлеге Г.Тукай исемендәге клубта Бөтендөнья татар конгрессына чакырылган язучы-кунаклар белән очрашу үткәрергә әзерләнә. Әңгәмә вакытында түбәндәге мәсьәләләр буенча фикер алышу күздә тотыла:

- Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенә (СНГ) кергән җөмһүриятләр, шулай ук чит илләрдәге язучылар оешмалары белән әдәби бәйләнешләр перспективасын ачыклау;

- Бөтендөнья төрки халыклары әдипләренең бүгенге милли мәнфәгатьләрен кайгыртуга юнәлтелгән уртак максатларны билгеләү;

- базар икътисады шартларында милли әдәбиятлар язмышын җиңеләйтү юллары турында тәҗрибә уртаклашу һ.б.

1990-1995 нче елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисенең урынбасары, Татарстанның Мамадыш районындагы Түбән Ушмы авылы тумасы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2009), Татарстанның халык шагыйре (2014) Зиннур Мөҗип улы Мансуров (1949)

Конгресс кунаклары белән очрашуга танылган татар язучылары, әдәбият галимнәре, наширләр, мәдәният учреждениеләре вәкилләре чакырыла. Язучылар йортында махсус китап күргәзмәсе әзерләнә. Кунакларга автографлы китаплар биреләчәк. Очрашуда катнашучылар язучыларның Конгресс көннәрендә ачыласы яңа кафесы белән таныша алачак.

Әдипләр йортында очрашу 20 июнь көнне 9дан 13 сәгатькә кадәр була.

Язучылар берлеге идарәсе әлеге чараны Бөтендөнья татар конгрессының аерым эш планына кертүегезне үтенә.

Татарстан Язучылар берлеге
идарәсе рәисенең урынбасары (имза) ***З.М.Мансуров****».*

Татарстан Язучылар берлеге Бөтендөнья татар конгрессы корылтаенда катнашырга тиешле язучыларның исемлеген тәкъдим итә: «Р.Мөхәммәдиев, Ә.Еники, А.Гыйләҗев, Г.Ахунов, Р.Фәйзуллин, Р.Батулла, М.Маликова, Л.Шакирҗанова, Ә.Кәримуллин, М.Мәһдиев, Т.Миңнуллин, З.Мансуров, Р.Хисмәтуллин, Н.Әхмәдиев, З.Фәтхетдинов, Р.Ахунов, Р.Мирхәйдәров, С.Липкин (Мәскәү), И.Салахов (Күкчәтау), Ә.Мохтар (Ташкент), Н.Нәҗми (Уфа)». ■

Без бар бит әле!

Алмаз Хәмзин



«Җидегән чишмә» җырының нотасы (көе һәм сүзләренең авторлары – композитор Сара Садыйкова, әдип Гомәр Бәширов)

Кеше үзенә торыр, яшәр өчен урын эзләгәндә һәрвакыт диңгез, елга, күл, чишмә буйларын сайлаган. Инде ныклап урнашкач, янәшәсендә күршеләре, язмышына хуш килгән әлеге җирлекне үз иткән башкалар да пәйда булган. Кечкенә урамнар зураеп киткән, авыллар, шәһәрләр калыккан. Күмәк яшәү рәвешенең байтак төрләре хасил булган. Әмма һәр кавемдә, һәр халыкта күп нәрсәне бердәмлеккә төйни торган бик тә кирәкле сыйфат ул – рухи югарылык! Аның дәрәҗәсе түбәнме яки югарымы – анысы башка мәсьәлә. Әмма шунысы мәгълүм: алда әйтелгәне зур әһәмияткә ия! Моңа хәтле булган иҗтимагый формацияләргә дә шул ук кагыйдә кагыла. Тау куышында яшәлгән чормы ул, колбиләүчелектәме, феодаль, капиталистик, социалистикмы, хәзерге вакытмы – барыбер.

Менә шуны бүгенге көннәргә күчереп дәлиллисем килә. Туган төбәгем – Түбән Кама районының Ташлык авылы – Зәй елгасының тамагында, аның Чулманга кушылган урынында. Тарихта Кол Галинең шушы табигатьнең җәннәттәй гүзәл почмагында туып, илләр гизеп, яңадан кайтып җирләнүе турында кайбер мәгълүматлар бар. Шулайдыр, ышандыра да, чөнки бу тирәләрдә калатаулар кебек байтак шәһәрләр гөрләгән. Бәрәҗ токымының шактый югары мәдәниятле булуына саллы мисалдыр бу.

Инде менә әлеге киңлектә җырларда данланып яңгыраган Түбән Кама каласы калыкты. Чулман елгасының иң зур бормалы куентыгында искиткеч куәтле, илкүләм масштаблы химия гиганты үсеп чыкты. Индустриябезне көчәйтү өчен, әлбәттә, аның кирәклеге бәхәссез. Шәһәр иңгә-буйга үсте. Монда илебезнең төрле төбәкләреннән эшче көчләр агылды. Күбесе – яшьләр. Тулай тораклар халык белән тулды. Эштән бушаган вакытта ял итү чаралары оештыру мәсьәләсе кыен хәлдә. Халык рухи бушлыкта. Андый чакта төрле җинаятьчел төркемнәр барлыкка килергә мөмкин. Ярый әле энтузиастлар бар. Шуларның иң беренчесе – Сарманнан килгән Флүр Гайнемөхәммәтов. Тулай торакларга йөреп, кичке уеннар оештырып, соңыннан мәдәният сараенда «Җидегән чишмә»ләрнең төп катнашучысы булып китүче. Аннан соң бу агымга Шәмси Закиров, Рахмай Хисмәтуллин, Наил Нуретдинов, Азат Зыятдинов, Илдус Сәлимов, Мәсгуть Сибгатов, Мөнир Галимуллин кебек фидакярләр кушыла. Агым, елгалар-

Сарман егете Флүр Гайнемөхәммәтов

га, диңгезләргә кушылып, зур дәрьяга әверелә. Бөтен административ көчләрнең дә шушы рухи дәрья дулкынында тирбәлүе халык рухына дәрт өсти.

«Җидегән чишмә»нең тирәнлеге һәм киңлеге – халкыбызның борын-борыннан килгән гореф-гадәтләренә ялганып дәвам итүендә. Әйе, авылдан килгән гади генә бер егет – Флүр Гайнемөхәммәтовның шәхси хисләре яңа төзелеп килгән Түбән Кама шәһәрендәге үзе кебек үк кешеләрнең күңеленә май булып ятмаган булса, бу «чишмә» шулай гөрләп агып китәр идеме икән?!. Гайнемөхәммәтовның нечкә күңел хисләре күпләрнең җан таләпләрендә шаулы диңгез дулкыннарын куптара. Ул хиссез генә яшәгән кала диварларын дерелдәтә, тулай торакларның кызыл почмакларына бәреп керә, мәдәният сарайларына ургый, мәйданнарны гөрләтә.

«Җидегән чишмә» халкыбыз күңелендә киләчәккә якты өмет уятты. Әдәби-музыкаль берләшмә кичәләреннән тамашачы: «Без әле бар икән, яшибез һәм яшәячәкбез икән. Безнең телебез матур, сөйләмебез ягымлы, әдәбиятыбыз борынгы һәм данлыклы, тарихыбыз шанлы икән», – дип, горурланып кайтып китәләр иде.

Бу җәһәттән сезгә «Җидегән чишмә» кичәләренә чакырылган бөек шәхесләребезнең ихлас рәхмәтләрен белдереп китүләрен ирештерү дә урынлы булыр.

Классик шагыйребез Сибгат Хәким (рәсемдә уртада) белән очрашу. Сулдан икенче – шагыйрь Разил Вәлиев. Түбән Кама. 1981 ел

«Түбән Камадагы кичә ул мәңге онытылмый, һәрвакыт сагындырып тора торган истәлек. Шундый бер кичә өчен гомереңбуе иҗат итсәң дә ярый. Мин шундый очрашулар белән яшим. Бар да чын күңелдән, ихлас. Кешеләр әйбәт, җылы атмосфера. Татар әдәбияты, татар мәдәнияте өчен янып яшәүчеләр. Бөтен җирдә дә шулай булса иде, рухым тагын ике тапкыр үсәр иде.

Сәлам белән, ***Сибгат Хәким.*** *Апрель, 1982 ел».*

«Түбән Камада үткәрелгән көннәрне, сездән күргән кадер-хөрмәтне оныткаНыбыз юк һәм онытылмаячак та! Шундый матур очрашуны күргәнем юк иде әле.

Һәммәгезгә ихтирам һәм сәлам белән,

Әмирхан Еники».

Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, язучы Әмирхан Еники (рәсемдә сулда) белән очрашу. Уртада – Азат Зыятдинов. 1986 ел

Күренекле галим Әбрар Кәримуллинны каләмдәшләре күркәм бәйрәме белән котлаган мәл

«Рәхмәт, туган!

Миңа рәхәт, җылы сүзләрнең өстән ишетелгәне булмады. Киресенчә, кыйнаулары бик мул булды. Шуңа күрә минем эшемне күреп, аны танып, мине шулай олылаганыгыз өчен, рәхмәтемне нинди сүзләр белән дә аңлатып бетерә алмыйм. Менә бу очрашудан соң, черт возьми: «Стоило трудиться, если и били тебя за каждое твое слово», – дип әйтәсе килә.

Бу кичәдә иң әһәмиятлесе – эшләгән нәрсәләремнең әһәмиятен, кадерен белүчеләр бар икәнен үз күзем белән күрдем.

***Әбрар Кәримуллин.** 2 декабрь, 1986 ел».*

«Җидегән чишмә»дә булган көннәрем матур төш кебек. Мин аларны беркайчан да онытмам. Шундый онытылмас көннәр бүләк иткәнегез өчен, Сезгә тагын бер мәртәбә зур рәхмәт, эшегездә уңышлар телим.

***Әнгам Атнабаев.** 8 декабрь, 1987 ел. Уфа».*

БАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрь һәм драматург Әнгам Атнабаев (рәсемдә сулда) белән очрашу. Уңда – Виктор Шадрин. 1987 ел

*«Нәрсә ул «Җидегән чишмә?», – дип сорагач: «Их, егетләр, аны сөйләп булмый. Аны бары тик барып күрергә кирәк!» – дип җавап биргән **Нәҗар Нәҗми.***

РСФСРның М.Горький исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Нәҗар Нәҗми (уртада – чал чәчле) белән очрашу. 1983 ел

«Җидегән чишмә» безнең уртак шатлыгыбызга әйләнде», – дигән сөекле композитор ***Сара Садыйкова.***

Сөекле композиторыбыз һәм җырчы сандугачыбыз Сара Садыйкова һәм атаклы язучыбыз Гомәр Бәширов белән очрашу. 1983 ел

«Сез, егетләр, үзегез дә белмисез әле нинди зур эш эшләгәнегезне. Киләчәктә бу турыда китаплар язачаклар, сезнең бу фидакярлек мәдәниятебез тарихына керәчәк әле», – дип әйтеп калдырган күренекле әдибебез

Мөхәммәт Мәһдиев.

Уңнан сулга: Мөхәммәт Мәһдиев, Ринат Мөхәммәдиев, Әбрар Кәримуллин, Гариф Ахунов. 1980 нче еллар ахыры

Күренекле шагыйрь, прозаик, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев (рәсемдә – беренче рәттә уңнан дүртенче) белән очрашу. Беренче рәттә сулдан беренче – рәссам Әхсән Фәтхетдинов, уңнан икенче – җырчы, композитор һәм язучы Алмаз Хәмзин. 1992 ел

«Җидегән чишмә»гә килгән теләсә нинди кеше үзенең чын татар икәнлеген тоеп, горурланып кайтып китә. Әйе, без – бөек халык! Шундый икәнлегебезне белеп яшик, яшьләребезне шул рухта тәрбиялик! «Җидегән чишмә» кичәләре һәр шәһәрдә, һәр төбәктә шаулап-гөрләп торса, башка халыклар да безгә соклануларын яшермәс. Данлыбыз артыр, дәрәҗәбез үсәр!»

Разил Вәлиев.

Күренекле сатирик язучы, җырчы һәм композитор Алмаз Хәмзин белән очрашу. 2013 ел

Төпле фикерләр, әһәмиятле киңәшләр. Безгә, кулга-кул тотышып, моңа хәтле рухи муллылыгыбызны тудырган һәм баеткан «Җидегән чишмә»безнең сихәтен кайтарып, халкыбыз яшәешенә нур, өмет, ышаныч, дәрт өстисе иде!..

Моның өчен Гайнемөхәммәтов кебекләр – без бар бит әле!

(Фотолар «Җидегән чишмә» дигән китаптан (китапның төзүче-редакторы – Алмаз Хәмзин, техник мөхәррире, дизайнеры – Айдар Хәмзин) алынды.) ■

Истә, һаман да истә!

Драматург Кәшшаф Әмировның туууына 100 ел

Драматург, 1985 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Кәшшаф Сафиулла улы Әмиров 1922 елның 7 апрелендә хәзерге Сембер өлкәсенең Иске Кулаткы районындагы Яңа Зимница авылында туган. Үсмер чагы Үзбәкстанда уза, сугыш алдыннан Бохара укытучылар институтында укый. 1940-1945 нче елларда Үзбәкстан мәктәпләрендә укытучы булып эшли.

Кәшшаф Әмиров 1960 елда Татарстанга кайта һәм, Лениногорск шәһәрендә төпләнеп, җитәкче урыннарда эшли.

Кәшшаф Әмиров – «Гаделлек җиңә», «Вөҗдан әмере», «Упкын», «Кодалар», «Туй алдыннан» кебек дистәдән артык сәхнә әсәре авторы. Аның «Зөлфия» пьесасы аеруча уңыш казана – 1983 елда Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә уйнала, илдәге иллеләп театрның репертуарына кертелә. Әфган һәм СССР халыклары арасындагы мөнәсәбәтләрне заманча яктырткан әлеге әсәр, рус теленә тәрҗемә ителеп, «Театр» журналында да басылып чыга (1983, №5).

К.Әмиров 1996 елда вафат булды.

Архитектор Мөнир Агишевның туууына 90 ел

Архитектор Мөнир Хәсән улы Агишев 1932 елның 14 апрелендә Пенза өлкәсенең Биги авылында туган.

1957 елда ул Казанга килеп төпләнә. 1960-1962 нче елларда – ТАССР Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының, 1962-1971 нче елларда – «Татгражданпроект» институтындагы проектларның, 1971-1990 нчы елларда исә Казан шәһәренең баш архитекторы була, бер үк вакытта (1966-1980) Казан төзүче-мөһәндисләр институтында архитектуралы планлаштыру кафедрасы укытучысы вазыйфасын да башкара.

М.Агишев проектлары нигезендә Юдино бистәсендәге торак квартал (1959-1962), Спорт сарае бинасы (1966), Казан шәһәр яны вокзалы бинасы (1967, В.Федоров һәм В.Логинов белән берлектә), Консерваториянең концерт залы (1967), «Татарстан» кунакханәсе бинасы (1970, Осия Берим һәм М.Хәйруллин белән берлектә), Г.Камал исемендәге ТДАТ бинасы (1981, Г.Горлышков һәм Н.Точилин белән берлектә), Кызыл Байрак авылындагы мәчет (1994, Т.Агишев белән берлектә) һәм башка объектлар төзелә.

М.Х.Агишев – М.Вахитов һәйкәленең архитектур эшләнеше авторы да (1985, архитектор В.А.Петербуржцев һәм А.В.Степанов белән берлектә).

М.Агишев 1994 елның 3 мартында Казанда вафат булды.

Язучы Фәрит Гыйльминең тууына 75 ел

Язучы, 1982 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Фәрит Гыйльметдин улы Гыйльми (Гыйльметдинов) 1947 елның 14 апрелендә ТАССРның Мөслим районындагы Уразмәт авылында туган.

1970 елда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый. 1970-1972 нче елларда ул Тарихи һәм мәдәни ядкярләрне саклау җәмгыятенең Әлмәт бүлеге җаваплы сәркатибе вазыйфасын башкара. 1972-1974 нче елларда исә Оренбург өлкәсенең Тук районында хәрби хезмәттә була. Фәрит Гыйльми 1974-1978 нче елларда Әлмәтнең 1 нче татар урта мәктәбендә тарих һәм әдәбият укыта. 1978-1983 нче елларда – Әлмәт батырма электр насослары заводында хезмәтне фәнни оештыру бюросы башлыгы, 1983-1985 нче елларда – «Оргтехстрой» трестында инженер булып эшли.

Фәрит Гыйльми 1985-1987 нче елларда – Мәскәүдә СССР Язучылар берлегенең Югары әдәби курслары тыңлаучысы, 1988-1993 нче елларда – Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә яшь һәм башлап язучылар консультанты.

Аның «Салават күпере» исемле беренче хикәясе 1967 елда «Кызыл таң« газетасында (Уфа) дөнья күрә. «Урсал тау итәгендә» повесте (1977 елда «Казан утлары» журналында басылган) һәм «Елганың борылган төшендә» әсәре (1980) белән ул 1982 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә. 1984 елда аның «Су өстендә чәчәкләр» дигән хикәяләр җыентыгы басылып чыга.

Ф.Гыйльми 1993 елның 12 октябрендә вафат булды һәм Әлмәт районының Бигәш авылы зиратында җирләнде.

Шагыйрә Зәйнәп Сәгыйдәнең тууына 125 ел

Шагыйрә һәм педагог Зәйнәп Хәлиулла кызы Сәгыйдә (Якупова-Бакирова) 1897 елның 22 апрелендә хәзерге Оренбург өлкәсенең Каргалы (элекке исеме – Сәгыйть) авылында туган.

Күренекле әдәбият галиме З.Рәмиев әйтүенчә: «Унҗиде яшьлек Сәгыйдә 1914 елда Оренбург губернасына караган Аллабирде авылының земство мәктәбендә укыта башлый. Әмма 1916 елда мәктәп ябыла һәм З.Сәгыйдә Оренбургта эшләп килгән Багъбостан ханымның кызлар мәктәбендә мөгалимә хезмәтен үти, кичләрен русча укып белемен күтәрә, Фатих Кәрими, Шәриф Камал, Шәехзадә Бабич, Борһан Шәрәф кебек күренекле татар язучылары һәм журналистлары белән аралаша. 1921 елда, Ибраһим Бакировка кияүгә чыккач, Урта Азиягә күчеп китә. Шагыйрә мәшһүребез Тукай иҗатын бик яраткан. Бер биографиясендә ул: «Мин Тукайны яттан белә идем», – дип яза. Аның 1915-1916 нчы елларда язылган барлык әсәрләре дә диярлек шул вакытта Оренбургта нәшер ителгән «Шура» журналында һәм «Вакыт» газетасында басылган.

З.Сәгыйдә революциядән соң да язган. Мәсәлән, аның «Колхозчы кыз Айсылу» исемле күләмле шигъри әсәре булганлыгы билгеле. Әмма алар, ни кызганыч, сакланмаган, бер өлеше Ташкентта җир тетрәү вакытында юкка чыккан...»

З.Сәгыйдә 1994 елда Ташкентта вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Рәссам Әхсән Фәтхетдинов музее

Татарстанның халык рәссамы Әхсән Фәтхетдиновның Түбән Кама шәһәрендәге музее

Күренекле нәкышчы, сынчы, агачны уеп бизәк-сыннар ясау остасы, ТРның халык рәссамы (2001), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1987), ТРның Г.Тукай исемендге дәүләт премиясе лауреаты (1993), Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданины (1999), Татарстанның Чирмешән районындагы Үтәмеш авылының тумасы Әхсән Сарим улы Фәтхетдиновның (1939-2012) үзенчәлекле һәм милли эшләре бүгенге көндә Түбән Кама шәһәре музеенда (2016 елда ачылды), шулай ук Татарстан, Россия калалары музейларында һәм чит илләрдәге (АКШ, Германия, Финляндия, Төркия һ.б.) шәхси коллекцияләрдә саклана.

«Бүген вөҗдан хәлләре начар тора. Мине иң борчыган нәрсә – халык язмышы. Бер эшемә мин: «Дөнья төрлелеге белән матур», – дип куйган идем. Бу Аллаһының бүләгедер инде. Ә соңгы вакытта бөтен нәрсәне берләштерә башладылар. Элитаның халыктан артык аерылуы халыкны эш атына әверелдереп бара. Байларның баюы, элитаның халыктан аерылуы борчый мине. Без революцияләр, сугышлар аша үттек. Халык кырылды, фаҗигаләр зур булды. Хәзерге заманда тагы да көчлерәк сынау – акча белән сыналу чорына кердек. Минемчә, бу адәм баласының акрынлап (ә бәлки, тиздер) эчтән таркалуы дип уйлыйм. Шуның өчендерме, минем иҗатым, башлыча, әхлакый темаларга кагыла. Ияләр саклый. Ә кешенең эчендә «багана» булырга тиеш. Булмаса, ул аны үзе куярга тиеш. Кайда укыган, кайсы чишмәнең суын эчкән – менә боларның һәммәсен дә барларга кирәк».

Әхсән Фәтхетдинов

«Көн аяза». ***Ә.Фәтхетдинов эше***



«Йорт иясе». ***Ә.Фәтхетдинов эше***

Равил Фәйзуллин, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты:

«Без бик якын дуслар идек. Әхсән әдәбият һәм поэзия ярата иде. Ул минем китапларны укыды, мин аның беренче күргәзмәләренә йөрдем. 1980 нче еллар тирәсеннән аралаша башладык. Безне иҗади намуслылык бәйләгәндер: минем поэзия дә, аның эшләре дә намуска нигезләнгән. Сафлык һәм ихласлык хас иде аңа.

Ул көннәр буе ялгызлыкта, остаханәсендә үз-үзе белән сөйләшә-сөйләшә иҗат итә иде. Ялгызлыкта яшәү бу дөньяны үзенчә аңларга ярдәм иткәндер дип уйлыйм. Караңгыда иҗат иткән кешенең күз күреме, күңел тоемы бүтән булгандыр. Нечкә хисле кеше яктылыкны да башкача күргәндер».

Рөстәм Галиев, Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры җитәкчесе, ТРның халык артисты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, М.Сәлимҗанов исемендәге республика бүләге иясе:

«Табигый, чиста күңелле кеше иде ул. Халкын да, илен дә бәхетле итәргә теләде, төссез, телсез, шаулы дөньядан игелек, әхлак, хаклык, матурлык таләп итте. Остаханәсендә Әхсән абый халык җырларын көйли-көйли эшләде. «Иямәрем бакчада «туды», – дия иде.

Гомеренең азагында җансыз «багана»ларга җан кертеп, дөньядан китеп барды ул. Рәссамның фәлсәфәсе: дөньядагы барлык «багана»ларның да үз язмышы бар. Әхсән Фәтхетдиновның үз «багана»сы – биек, чиксез, очы-кырые күренмәгән шәфәкъ.

Бу дөньядан бакыйлыкка күчергәндә, аны гүргә үзем иңдердем. Һәм, Әхсән абый рухына дога кылып, аның соңгы баганасын үз кулым белән утыртып калдырдым». ■

Җуелмас хәзинә

«Минем таныш өянкеләр» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Тәртип радиосы

Минем таныш өянкеләр

(Сибгат Хәким сүзләре, Рөстәм Яхин көе)

Сезгә эндәшми мин кемгә
Эндәшим, өянкеләр?
Җитте минем дә, сезнең күк,
Картайдым, дияр көннәр.

Кабынды, янды бер чорда
Яшьлекнең саф хисләре.
Сез – минем мәхәббәтемнең
Бердәнбер шаһитләре.

Кайда ул бергә ашкынган,
Бергә шаулаган көннәр?
Минем таныш өянкеләр,
Сезгә баш ияр кемнәр?!.

«Минем таныш өянкеләр» җырын башкаручыларның берсе – ТАССРның атказанган (1980), ТАССРның халык артисты (1987), Түбән Кама районындагы Шәңгәлче авылының тумасы **Рафаэль Сәхәбиев** (1952-2019) бу җыр турында болай дип язган иде: *«Миңа безнең бөек композиторларыбыз, язучыларыбыз, артистларыбыз белән таныш булып, бергә эшләү бәхете тиде. Алар арасында Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин да бар, яшь җырчыга Рөстәм аганың әсәрен башкару зур мәртәбә санала иде. Сибгат Хәкимне дә аерып әйтәсе килә. Ул яшь җырчыларга карата шулай ук бик игътибарлы булды.*

Көннәрдән беркөнне шулай Рөстәм ага Яхин миңа Сибгат ага Хәким сүзләренә язылган «Минем таныш өянкеләр» исемле җыр тәкъдим итте. Җыр үземә тәүдә үк бик ошады. (Рөстәм абыйның җырлары, гомумән, яхшы; бер ишетүдә истә кала торганнардан.) Репертуарыма керде, халыкның да күңеленә хуш килде. Бигрәк тә язучы Аяз Гыйләҗев

ярата иде бу җырны. Язучылар берлегендә очрашсак, туктата да: «Сәхәби, слушай, парин, бер генә куплет җырла әле», – ди. Мин җырлый башлауга үкси-үкси еларга тотына.

Бу җырны мин әлегәчә җырлыйм. Аның сүзләре хәзер үземә дә тулаем туры килә инде...»

Сибгат Хәкимнең шигыре дүрт строфадан торган. Җырчылар җырламый торган строфа болайрак яңгырый:

Күбәйде миндә дә тутлар,
Сездәге тутлар кебек,
Ул тутлар учакта сүнеп
Бетмәгән утлар кебек.

Атаклы җырчыларыбыз Вафирә Гыйззәтуллина, Зиннур Нурмөхәммәтов һәм Рафаэль Сәхәбиев башкаруындагы әлеге «Минем таныш өянкеләр» җырын тамашачылар бик яратып тыңлый иде.

«Минем таныш өянкеләр» җырының көй авторы – СССРның халык артисты (1986), ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1964), композитор Рөстәм Яхин (1921-1993)



«Минем таныш өянкеләр» текстының авторы – Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәким (1911-1986).
Владимир Зотов фотосы

«Минем таныш өянкеләр» җырын башкаручыларның берсе – ТАССРның атказанган (1980), ТАССРның халык артисты (1987), Түбән Кама районының Шаңгәлче авылы тумасы Рафаэль Сәхәбиев (1952-2019)

Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева) материалларына нигезләнеп, Ләбиб Лерон әзерләде. ■

Алмагач

Алмагач сүзе *алма* һәм *агач* сүзләреннән кушылып ясалганын, җимешенең алма икәнен барыбыз да беләбез. Алма халкыбызның төрле шивәләрендә *багалма, буалма* дип тә йөртелә.

Ул халкыбыз дастаннарында могҗизалы җимеш буларак сурәтләнә. Алма мәхәббәт җимеше һәм үрчем бирүче нигъмәт тә әле. Мәсәлән, «Кузы Көрпә һәм Баян Сылу» дастанында Ак хан һәм Кара хан, балалары булмау сәбәпле, фал ачучы картка бара, карт исә, боларга фал ачып, хатыннарына үзе биргән алмаларны ашарга куша. Тегеләр шулай эшлиләр һәм, тугыз ай дигәндә, ике ханның да хатыннары бала таба. Ак ханның улына – Кузы Көрпә, Кара ханның кызына Баян Сылу дип исем кушалар. Әсәр менә шушы вакыйга белән башланып китә.

Әкиятләргә килсәк, анда сүз күбрәк алтын алма тирәсендә бара. Хәтерләсәгез, бу сюжет берничә әкияттә бар. Әлеге әсәрләрдә бер патшаның бик шәп бакчасында алмагач үсеп утыра, ул һич кенә дә гади алмагач түгел, ә могҗизалы икән, чөнки аның алмалары алтын. Шунысы кызык: әлеге алтын алмаларны өзеп ашый алган кеше тылсымлы көчкә ия була һәм, төрле сынауларны үтеп, бәхеткә ирешә ала. «Үги кыз һәм патша улы» әкияте сюжеты тулысынча шушы алтын алма хикмәтенә корылган.

Халкыбыз алманың тәмен, матурлыгын, хуш исен һәм башка сыйфатларын табышмакларда да зурлый. Мәсәлән: *«Бакчадагы асыл кош, төшәм, диеп тилмерә».*

Халык җырларында да алмаларга игътибар бик зур:

Алмалар алып ашатам,
Яраткан былбылыма.
Ычкынмаслык бәйләдең бит
Мәхәббәт чылбырына.

Барыбызга да алманың кайнатмасын да, кагын да, киптергән телемнәрен дә, агачыннан әле генә өзеп алганын да рәхәтләнеп, тыныч күңел белән ашарга язсын, амин!

*Сәхифә «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Фәнзилә Җәүһәрова**) белән берлектә әзерләнде.* ■

Алмагач турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Алма

Иң әүвәл мәшһүребез **Каюм Насыйри**ның «Хәвасе нәбатат» («Шифалы үләннәр») китабына мөрәҗәгать итик:

«Алма (яблоко) – җиребездәге гадәти һәм күренекле җимеш. Гарәпчә – тоффах, фарсыча – сиб дип атала. Әмма алманың бик күп сортлары бар. Дәвага кулланылганы – бакча алмасы. Җиңелчә бизгәккә, ашказаны шешкәнгә һәм эчәгеләр пешеккәнгә алма файдалы. Алма бөрештергеч түгел. Алманың суын сыгып, лимон суы белән катнаштырып эчсәң, температураны төшерер. Файдалы үзлекләре күптер».

Алма төшендә йод күп. Әгәр көн дәвамында 5-6 алма төше чәйнәсәң, организмның йодка булган ихтыяҗы канәгатьләндерелә. Алма холестерин күләмен нормага сала. Моның өчен көненә ике алма ашау җитә. Алмада аскорбин кислотасы, фруктоза, магний күп. Кабыгында витаминнар 4-6 тапкыр артыграк.

Алмада 86 процент чамасы су, шактый гына күләмдә клетчатка һәм пектин матдәләр бар. Алмаларның төп состав өлеше – төрле шикәрләр, алар башлыча фруктоза формасында. Бу матдәләрнең микъдары, алманың сортына һәм үсү урынына карап, 5 проценттан алып 10 процентка кадәр була. Шикәрнең микъдары җәйге сортларда көзге сортлардагыга караганда, ә көзгеләрендә исә кышкы сортлардагыга караганда азрак. Төньяк сортларда су көньяк сортлардагы белән чагыштырганда күбрәк, ә шикәр азрак. Алмаларда алма һәм лимон кислоталары бар (алма кислотасы лимон кислотасына караганда 3 тапкыр күбрәк). Моннан тыш, аларда салицил һәм борат кислоталары да бар. Алма кабыгында шикәр һәм кислоталар йомшагындагыга караганда азрак, ә дубиль матдәләр исә күбрәк. Өлгермәгән алмаларда крахмал булса, өлгереп җиткәндә ул шикәргә күчә бара.

Минераль матдәләрдән алмаларда тимер һәм марганец тозлары, аз гына күләмдә калий, натрий һәм кальций тозлары бар. Алманың күп кенә сортлары С витаминына бай. Кайбер сорт алмаларда аз гына күләмдә В группасы витаминнары һәм каротин да бар. Алмаларны яңа өзелгән, киптерелгән, туңдырылган һәм консервланган хәлдә ашарга ярый.

Әлбәттә, көзге һәм кышкы сортларны консервлау яки киптерү яхшырак.

Антоновка алмасының сорты Татарстанга, аерым алганда, Кама Тамагы районындагы Антоновка авылына бәйле икәнлеген күпләр белмидер дә әле.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Көлке куа килә...

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Робагый

Матурлыкны тоймаганга, яңа ай тик кыерчык,
Мәчеләргә азык кына яз җырчысы – сыерчык.
Бүтәннәрдә ни эшем бар, минем өчен бик матур
Уң колагың читендәге матур гына җыерчык.



Г.Рәхим.
Ләбиб Лерон шаржы

Гәрәй Рәхим (1941-2021)

Булмый

Чәнечкеле булу белән –
Кычыткан роза булмый.
Дурактан дурак туса да,
Даһидан даһи тумый.

Мәгъсум Хуҗин (1930-2008)

Тау төшкәндә

Зур үзбушаткыч машинаның кабинасында өчәү утырып кайтабыз. Биек озын тау төшәбез. Шофер машинаны үз иркенә куеп алды – тизлек артты. Уртада утырып кайткан апа төенчеген алдыннан төшерде һәм:

– Тр-р-р, – дип, рульгә тотынды.

Аннары апа үзе дә көлеп җибәрде. Һәм аның йөзендә курку калмаган иде инде.

Машина, апа «дилбегәсеннән тоткач», чыннан да, акрынайды.

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

Урысчага өйрәнгән

Авылда кушаматсыз кеше сирәк инде ул. Мотыйгулла абзыйны «Мүкәнә» дип йөрткәннәр. Ул, Ишмөхәммәт абзый белән бергә, маклерлык эше, ягъни мал-туар сатучы белән алучы арасында арадашлык итү белән көн күргән. Танылган әдип Фатих Хөсни әсәрләренә кергән атаклы Теләче базарында кәҗә сатканнар болар.

Икенче вакыт очрашкач, Мотыйгулла Ишмөхәммәттән:

– Минем кәҗәне алган урысны күрмәдеңме? – дип сүз каткан.

– Хуҗасын очратмадым, әмма кәҗәне күрдем, – дип сүз башлаган шаян телле маклер. – Бер атна эчендә тәмам урысчага өйрәнеп беткән ул. «Му-ка-на, ка-а-ак?» – дип арттан акырып калды, – дигән.

Илдар Юзеев (1933-2004)

«Ак барие...»

Язучылар Союзында эшләгән чак. Минем бүлмәгә Шәүкәт Галиев керде. Шулвакыт телефон шылтырады. Трубканы алам. Ерактан булгандыр, тавышы әйбәт ишетелми. Шулай да Туфан икәнен шәйләдем: «Кибеттә ак барие! Сиңа кирәкме?» Шатлыгымнан үкереп җибәрдем. «Ак барие?! Кирәк! Бик кирәк!» (Ак аракыга кытлык чор иде бу.) Шәүкәт кулымнан трубканы тартып алды: «Туфан, миңа да ал! Күпме ала аласың – шулкадәр!»

Киттек Шәүкәт белән икәүләп Туфанның өенә акны алырга. Бара-бара татлы хыялларга чумабыз: «Бер яртысын өч борынга салырбыз инде...»

Звонокка бастык. Ачты Туфан ишекне. Байларча кыяфәт белән безне түргә чакырды: «Әйдәгез, җегетләр, сөендерим әле үзегезне!»

Һәм, бер кулы белән бөеренә таянып, икенче кулы белән түр бүлмәнең ишеген ачты.

– Менә! Туфанның игелеген күрегез!

Һәм без... авызыбызны ачып, катып калдык: бүлмә тулы аквариум иде...

– Ни бу?! Кайда ак?

– Нинди «ак»? Нәрсә «ак»?

– Син бит безгә: «Ак барие», – дип әйттең...

– Нинди ак? Нәрсә ак? Мин бит сезгә аквариум дип әйттем.

Өчебез дә хәлсезләнеп утырдык.

– Мин боларны кая куям инде? Алыгыз инде берәрсен булса да...

– Минем үземдә дә өй тулы аквариум...

– Миндә дә...

...Ул аквариумны соңыннан кая олактырып бетергәндер, анысын Туфан үзе генә беләдер. Бер-беребездән уңайсызланып йөреп, бу хакта беребез дә сүз башламады.

Озак еллардан соң, Туфаннан рөхсәт алып, ояла-ояла, көлә-көлә, менә шуны язарга ниятләдем.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Габдулла Тукай (1886-1913)

Бәхет

Яшәгән, ди, бер шәһәрнең читендә өч агай-эне. Бер дә яхшы бармаган, ди, боларның эшләгән эше. Барысы да зарланган-офтанган: «Без – бәхетсез кеше». Берзаман Бәхет боларга кунаккка килде һәм ярдәм кылырга сүз бирде. Шуннан аларның олысы сәүдәгәрлеккә тотынды һәм, Бәхет ярдәме белән, бу кәсебеннән бик уңды, эшләре тәгәрәп китте, ул зур бай булып җитте.

Икенче агай-эне бу вакытта писер иде, моның да эшләре уңайга җитте, һөнәре аңа күкрәк тулы медаль-дан бирде.

Өченче кардәшнең төп эше чебен тоту иде. Бәхет аңа да ярдәм итте, теге шактый чебеннең башына җитте.

Менә беркөнне кунакка гына килгән Бәхет үз юлы белән китеп тә барды. Ике карендәш бик баеп калды, өченчесенә инде чебен дә тоттырмый, ул һаман фәкыйрь һәм ярлы иде.

Зәки Нури (1921-1994)

Кошлар кайта

Ачылды ак калын юрган,
Исте апрель җилләре.
Кошлар кайта: сагындырган
Туган-үскән җирләре.

Көннәрен юлда уткәреп,
Куанышып очалар,
Канатларына күтәреп,
Яз китерә ич алар.

Ахмак бүре

(Татар халык әкияте)

Берзаман Бүре бик ачыккан. Ни туры килсә, шуны ашармын, дип, азык эзләргә киткән. Бара торгач, аңа бер Кәҗә тәкәсе очраган.

Бүре Кәҗә тәкәсенә:

– Кәҗә, мин сине ашыйм, – дигән.

Кәҗә тәкәсе аңа:

– Ашасаң ашарсың инде. Ярый, алайса менә син бу тау итәгендә авызыңны ачып тор. Мин тау башыннан сикереп төшәрмен дә авызыңа кереп китәрмен, – дигән.

Бүре риза булган.

Кәҗә тәкәсе тау башыннан йөгереп төшкән дә Бүрене сөзеп еккан, Бүренең һушы киткән.

Берзаман, аңына килеп, тирә-якка караса, Кәҗә тәкәсе әллә кайчан китеп барган, ди.

Бүре бик үкенгән үкенүен, ләкин инде соң булган.

Табышмаклар

Кат-кат тунлы, карыш
буйлы. *(Кәбестә.)*

***

Үзе шардай,
Эче кандай,
Тәме балдай. *(Карбыз.)*



***

Ике якка аерган,
Ат авызын каерган. *(Авызлык.)*

Әнәс Кари (1920-1954)



Безнең сыер

Безнең сыер өебезне яхшы белә,
Көтүдән ул мөгри-мөгри кайтып керә.
Әйтерсең лә: «Мине каршы алыгыз! – ди, –
Мул итеп сөт алып кайттым, савыгыз!» – ди.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

МАРТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 2 мартта Татарстанның халык артисты, 1964-1995 нче елларда К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры артисткасы, Мәскәү шәһәре тумасы Земфира Исхак кызы Досаева вафат булды.

● 16 мартта, Татарстаннан килгән язучылар – Вахит Имамов, Рәдиф Сәгъди, Ләбиб Лерон һәм тарихчы Ленар Гобәйдуллин катнашында, Бәрәңге (Параньга) районында (Мари Иле), аерым алганда, Портянур һәм Куян авыллары мәктәпләрендә, шулай ук Бәрәңге мәктәбендә очрашулар узды.

● 17 мартта Чаллы шәһәренең 54 нче гимназиясендә, «Илһам» бәйгесе кысаларында, Әгерҗе, Актаныш, Алабуга, Менделеевск, Тукай, Минзәлә районнарында һәм Чаллыда яшәп иҗат итүче яшь каләм әһелләренең иҗади эшләренә бәя бирү чарасы (жюри әгъзалары – Факил Сафин, Ләбиб Лерон һәм Рәдиф Сәгъди) үтте.

● 16-18 мартта Казанда X Бөтенроссия татар авыллары эшмәкәрләре форумы булып узды. 18 мартта «Корстон» күңел ачу комплексында үткән пленар утырышта ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов та катнашты һәм чыгыш ясады.

● 18 мартта Кукмара районының Мәчкәрә авылында XVIII гасыр азагында – 1791-1793 нче елларда беренче гильдия сәүдәгәре Габдулла Үтәмешев акчасына төзелгән, архитектурасы буенча Казанның Мәрҗани мәчетен хәтерләткән мәчетне төзекләндерү эшенә фатиха бирелде. Заманында аның янындагы мәдрәсәдә төрле елларда Казан, Уфа һәм Нократ губерналарының күп кенә мөселман руханилары дини белем алган.

● 19 мартта сәнгать фәннәре кандидаты, этномузыка белгече, Россия фольклор берләшмәсе әгъзасы, «Безнең мирас» журналының актив авторы, мөселман музыкасы мәдәниятенең татар җирлегендә чагылыш үзенчәлекләрен өйрәнгән, халкыбызның гөсләдә уйнау традицияләрен авыллар буйлап җыйнап, шулар нигезендә республикабызда һәм башка төбәкләрдә дистәләгән гөсләчеләр ансамбле булдыруга зур өлеш керткән фольклорчы-галимә Эльмира Ринат кызы Каюмова каты авырудан соң вафат булды. Мәрхүмәнең җәсәде туганы ягында – Кайбыч районының Салтыган авылы зиратында җирләнде.

● 19 мартта Мөслим районының Баланлы төп гомуми белем бирү мәктәбендә, районның татар теле укытучылары катнашында, китап укучылар конференциясе узды. Аңа Тойгелде авылында яшәп иҗат итүче шагыйрь, «Офык артында офык» китабының авторы Марсель Гыйльфанов чакырылган иде.

Кичәдә М.Гыйльфановның улы – Татарстанның атказанган артисты Рөстәм Гыйльфанов та катнашты һәм әтисе сүзләренә язылган җырларны башкарды.

● 19 мартта Актаныш районының Әнәк авылында Нәүрүз бәйрәме үткәрелде. Авылның Минтимер Шәймиев исемендәге урамы буйлап бизәлгән җигүле ат узды. Авыл уңганнарының сый-нигъмәтләрдән сыгылып торган өстәлләре, учакта пешкән пылау, кием-салым, китап һәм матбугат сату нокталары халыкны үзенә җәлеп итеп торды. Чарада танылган сәнгать осталары Марат Фәйрушин, Рәмзил Зиннәтуллин, Рушан Зиннәтов катнашты һәм чыгыш ясады.

● 22 мартта Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты әдип Ркаил Зәйдуллага 60 яшь тулу уңаеннан, «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь» дигән кичә узды. Әдипнең каләмдәшләре, сәнгать әһелләре катнашында үткән әлеге кичәдә җырчылар – Зәйнәп Фәрхетдинова, Азат Тимершәех, Рәсим Низамов һәм Алинә Шәрипҗанова шагыйрь сүзләренә язылган җырларны башкарды.

● 24 мартта Татарстанның халык артисты Хәлил Мәхмүтов (1939-2012) һәм Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисткасы Исламия Мәхмүтова (1943-2019) яшәгән йортка (Казан, Жуковский урамы, 9) истәлек тактасы (авторы – сынчы Рөстәм Габбасов) куелды. ■

МИРАСВОРД



Фатих Кәрим поэмасы

Актер ... Нуруллин

... Барбюс

«Җомга көн ... белән» (Аяз Гыйләҗев)

... Гыйззәт

Монархның асылташлар белән бизәлгән баш киеме

... Вәлиева (опера җырчысы)

... сарып йөрү

... Габәши

«...-Сок» бәете

К.Тинчурин драмасы

Жюль Верн капитаны

Фукс, Либкнехт

«Сүнмәс ...» (Габдрахман Әпсәләмов)

Киндер сукканда кыстырыла торган җеп

Верди операсы

XIX гасыр француз композиторы

Тоташ зур ит кисәге (диал.)

Далай-...

Аз санлы төрки халык

Кытай флейтасы

Австралиядәге иң зур шәһәр

Венециядә каюталы махсус көймә

«Идегәй» дастанындагы персонаж

Юка табаклы тимер

«... лөгатеттөрк» (Мәхмүд Кашгарый)

... Байҗиев (кыргыз әдибе)

Шагыйрь Наис ...

Әйләнә (диал.)

Сынчы ... Нигъмәтуллина

Палеозой эрасының дүртенче дәвере

Сөт анасы

... Цветаева

... Купала



... Тәрҗеманов

... Мирзаянов

Хәзерге Мьянма территориясендәге урта гасыр дәүләте

Очкыч

Реформа, янарыш (иск.)

... өчпочмагы

Жак-... Кусто

Язучы Тәүфикъ ...

«... килде» (Шәриф Хөсәенов)

3 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Әйди, ору, Шилки, «Каиб», дая, Ары, токтавыл, уч, азыклы, сәкен, мөлкәт, ир, рас, Хәсән, Индира, Әмин, Әхтәмова, илд, Лир, мотлак, ти, «Зиндан».
Өстән аска: «Ашказар», шәех, «Йолдызым», Ка, көрәгә, МАЗ, Идиятуллин, очык, Солтан, Вил, кистән, арата, фок, дә, кин, Раев, Кәрими, Луи, лира, «Болын», Санд.

Раис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»

елъязмасы / апрель



Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»

640 ел элек (1382)

Алтын Урда ханы Туктамыш Мәскәүне яулап алу сәфәренә кузгала, беркадәр камап торганнан соң, татарлар шәһәрне басып ала. Шушы вакыйгадан соң, Куликово сугышы «каһарманы» Дмитрий Донской нәкъ элеккечә Сарайга ясак түли башлый. Татарлар исә, шуңа канәгать булып, Мәскәүне янә үз иркенә калдыралар.

475 ел элек (1547)

Митрополит Макарий киңәше белән, яшь кенәз Иван (булачак Явыз Иван) өйләнә һәм аны патша дип игълан итәләр. Чиркәү әһелләре дәүләт эшләрендә әле тәҗрибәсе булмаган яшь патша аша хакимиятне үз кулларына алалар.

110 ел элек (1912)

Бакуда «Садаи хак» («Хаклык авазы») исемле көндәлек газета чыга башлый. Ул заманында төрки халыклар арасында иң күп таралган (8 меңнән артык данәдә) газеталарның берсе була.

100 ел элек (1922)

27 апрельдә башкалабыз Казанның Юнысовлар мәйданында Мулланур Вахитовка һәйкәл куела.

95 ел элек (1927)

20 апрельдә Шәриф Камалның «Таң атканда» романы китап булып басылып чыга.

75 ел элек (1947)

22 апрельдә СССР Министрлар Советы каршындагы әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Ленин премияләре комитетының карары нигезендә, «Моабит дәфтәрләре» өчен шагыйрь Муса Җәлил (1906-1944) Ленин премиясенә лаек була.

65 ел элек (1957)

12 апрельдә шагыйрә, милләтпәрвәр, җәмәгать эшлеклесе Сания Гыйффәт (1899-1957) Анкара шәһәрендә вафат була.

50 ел элек (1972)

ТАССР Дәүләт музеенда татар әдәбияты бүлеге ачыла.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Апрель 2022

И останется в мире слово моё...: Г.Тукай.

Историческое наследие: «Животноводство в Золотой Орде». Л.Губайдуллин; «Великое татаро-тюркское наследие в мировой истории». А.Чанышев; «Стамбульские письма». Ф.Карими; «Вот бы такую жену, как она!» М.Файзи; «Благородная династия Хальфиных». М.Гаитов.

Татарский мир: «Рамиль Муллин: «У Нижнекамска будет прекрасное будущее»; «Нижнекамск – славный город»; «Стихи Лаиса Зулькарная».

Литературное наследие: «Габдулла Тукай и Джей Дагестанский». Л.Муртазина.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Ислам. Религиозный словарь»; «Хадисы пророка Мухаммеда (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат.

В глубинах памяти: «Дилюс Ильясов». А.Зарипов; «Письма писателей по случаю знаменательного юбилея Тукая». Л.Лерон; «Конгресс: первые шаги, великие цели». Л.Лерон; «Мы еще живы!» А.Хамзин; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Музей художника Ахсана Фатхутдинова».

Природное наследие: «Яблоня».

Алхәбәр:

Сулдан уңга: Ренат Харис, Д.Х.Зарипова (КПСС өлкә комитетының мәдәният бүлеге мөдире), С.П.Кошечкин («Правда» газетасының мәдәният бүлеге мөдире), Раиса Горбачева, Әмирхан Еники, Тәлгат Галиуллин, Илдар Юзеев, Миркасыйм Госманов. 1986 ел *(«Мизгел». Марсель Галиев)*

Азат Зыятдинов — фотоларда

Техник фәннәр докторы, ТРның атказанган химигы, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы, озак еллар «Түбән Кама Нефтехим» АҖен җитәкләгән Азат Шәймулла улы Зыятдиновның фотоларын Себер тракты тарихы һәм Муса Җәлил музее җитәкчесе Лилия Зыятдинова тәкъдим итте.

Сулдан уңга: Бакый, Фәния, әнисе Ләмига, Азат, Сәйдәш, әтисе Шәймулла, Илгиз. 1946 ел

Азат Зыятдинов, Таузарда башлангыч мәктәп төзергә ризалык алганнан соң, Президентыбыз Рөстәм Миңнехановка шигъри юллар язылган балта бүләк иткән мизгел. 2014 ел

Бертуган Зыятдиновлар – Бакый, Илгиз, Азат һәм Фәргать Усманов

Азат Зыятдинов авылдашлары һәм яшьтәшләре белән

Туган йортка кайткач



Түбән Кама районының Ташлык авылы тумасы, Югары Ташлык авылына нигез салучыларның берсе Гыйләҗетдин Мөхетдинов (сулда)

Разил Вәлиев

Игенчеләр нәселе

Җиргә ятып сабан сөргән бабам,
Чалгы селтәп чапкан печәнне.
Аршын түгел, метр, сажин түгел –
Өмет булган җирнең үлчәме.

Гомерендә алтын күрмәгән ул,
Янчык тулы көмеш йөртмәгән.
Алтын төсен күргән игеннәрдә,
Көмеш сулар эчкән чишмәдән.

Ракеталар очмаса да ул чак,
Ай турында җырлар җырлаган.
Ачмаса да серен йолдызларның,
Күккә карап язмыш юраган.

Вакыт җитте безгә, галәм иңләп,
«Карурман»ны җырлап үтәргә...
Тик һаман да туган җирне сөю
Житеп бетми әле күпләргә.

Нәселемә мин хыянәт итмәм! –
Игенчеләр безнең ыруда.
...Буразналар ярып барсаң иде
Шигъриятнең олы кырында.

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.